Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 4 (1420) 3 февраль 2023 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

8

К.Тинчурин театрында куелган «Идегәй» спектакле, Н. Исәнбәт халыкка кайтарган әсәрне бозып күрсәтеп, милли тарихка да тап төшерә.

12

Соңгы ике дистәгә якын елда Муса Җәлилнең кызы Люция ханым янына бер татар әдибе дә килмәгән

15

Г.Кариев театрындагы җыр-моңлы спектакльләрнең уңышында артистларга вокал серләрен өйрәтүче Лилия Зәйнуллинаның өлеше бәхәссез.

Туган белән туган даулашып та Хәл кылынган халык язмышы...

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Түбән Новгород өлкәсе Сафаҗәй авылында Хөсәен Фәезхановның тууына 200 ел тулуга багышланган «Фәезханов укулары» узды.

- Татарстанның җиде дәүләт театры 2023 елда РФ Мәдәният министрлыгының «Зур гастрольләр» һәм «Без – Россия» программалары буенча гастрольләр өчен акча алачак.

- Татарстан радиосы Татарстанның халык язучысы Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» әсәре буенча радиоспектакль әзерләде.

- Казан Россиянең сәяхәт итү өчен иң яхшы биш музыкаль шәһәре арасына керде.

- «Татаркино» оешмасы актив озак яшәү стратегиясен гамәлгә ашыру һәм өлкәннәр турында кайгырту максатыннан «Киноклуб 60+» проектын тәкъдим итте.

- Азнакайның Чубар Абдул мәдәният йортында шагыйрә, популяр җырлар авторы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гөлшат Зәйнашеваны искә алу кичәсе үтте.

- Казанда Мөселман яшьләре форумының кышкы мәктәбе оештырылды.

- Бөтенроссия конкурс-фестивалендә Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең балалар студиясе коллективы Удмуртиядә узган «Италмас чакыра» II Бөтенроссия конкурс-фестивалендә барлык призлы урыннарны алган.

- Ульяновск шәһәренең «Нур» татар халык театры Димитровград шәһәре тамашачысына Данил Салихов пьесасы буенча куелган «Язмыш» спектаклен тәкъдим итте.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Ринат НАСЫЙРОВ: Бөтендөнья татар конгрессының Төмәндәге вәкиле:

«Зур шәһәрләр янында урнашкан татар авылларында яңа микрорайоннар барлыкка килү татарларның мохитен юкка чыгарды. 90 процент татар торган җирдә 25 катлы 5-6 йорт төзеп куйдылар да, татарлар өлеше 10 процентка калды. Шуның аркасында мәктәп тә, балалар бакчасы да бүтән дәрәҗәгә күчте. Без зур мәктәпләр ачылуына куанабыз, ә алар татар файдасына булмый».

СЫНАМЫШЛАР

Февраль башында җылы булса, кар эресә, уңыш уртача булыр, дип фаразлана ● Февральдә кар күп яуса, апрель суга бай була ● Февраль яңгырлы булса, яз да, җәй дә яңгырлы килә; аяз булса – җәй коры килә ● Февральдә агачларны бәс сарса – бал күп була ● Кояш бик еракта булып күренсә, көннәр суыта.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 36 минутта** чыкты, һәм ул **16 сәгать 20 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **8 сәгать 44 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **30 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **10 февральдә 9 сәгать 14 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

3 февраль – язучы, тәнкыйтьче, публицист һәм драматург, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фатих Хөснетдин улы Хөснетдиновның (Хөсни) тууына 115 ел (1908–1996);

– җырчы, Татарстанның халык артисты Галина Александровна Казанцевага 70 яшь (1953);

– дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Габтелгаяз улы Шәйхразыевка 60 яшь (1963).

5 февраль – Башкортстанның халык шагыйре, Салават Юлаев премиясе лауреаты Хәбибнаҗар Нәҗметдин улы Нәҗметдиновның (Нажар Нәҗми) тууына 105 ел (1918–1999);

– язучы Гөлчәчәк Кәрим кызы Галиеваның тууына 95 ел (1928–2014).

7 февраль – актёр, Татарстанның атказанган артисты Дусил Гаяз улы Касыймовның тууына 80 ел (1943–2008).

9 февраль – шагыйрь, язучы һәм драматург, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фәнис (Фәниз) Гатаулла улы Яруллинның тууына 85 ел (1938–2011).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Февральнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 9 февраль.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(5-13 февраль)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзенә физик йөкләмә бирү файдалы.

###ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рәҗәб аеның 12 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Илгизәр ЗӘКИЕВ

КАЗЫЙГА ХӨКЕМ ЮК

XIX гасыр башында иҗат иткән күренекле рус шагыйре Александр Грибоедовның «Акыллылык бәласе» комедиясендә төп герой Александр Чацкийның «Ә хөкемдарлар кем соң? Борын-борын заманнардан аларның хөр тормышка дошманлыгы...» дип башланган атаклы монологы белән мәктәп дәреслекләрендә үк таныштык. Әсәрнең классиклыгы андагы фикерләрнең, теманың үлемсезлеге, һәркайчан актуальлеге белән дә билгеләнә. Рус телендә фразеологизмга әверелгән «Ә хөкемдарлар кем соң?» гыйбарәсе исә теге яки бу хөкем чыгаручы, ләкин үзләре асылда хөкем ителүче затлардан һичбер ягы белән әллә ни аерылып тормаган «абруйлы» бәндәләргә карата кулланыла. Хөкемдарлар дигәндә, әлбәттә, төрле дәрәҗәдәге судьялар гына түгел, уңга-сулга боерык чыгарып утыручы прокуратура вәкилләре, җәза-штрафлар язу белән мәшгуль эреле-вaклы комиссия, комитет җитәкчеләрен дә күз уңында тотарга мөмкин. Ләкин шулай да пирамиданың иң түбәсендә судьялар утыра.

Үзенең бер чыгышында ил башлыгы, Россиядә суд системасы, кайбер илләрнекеннән аермалы буларак, «җансыз машина» түгел дип басым ясап әйтте. Аның сүзләренчә, теләсә кайсы дәүләттә суд системасы «бик зур механизм» булып тора. «Ләкин Россиядә ул җансыз машина түгел, һәм менә Югары Суд рәисе белдергәнчә, хәзерге вакытта Югары Суд җитәкчелеге, урыннардагы судьялар, аларның советлары һәрдаим эшне алга таба ничек камилләштерү турында уйлый», – диде Россия Президенты. Ләкин асылда бу камилләштерү асыл гаеплене табу, гөнаһлыларга лаеклы җәза бирү түгел, хакимият кушканнарны тагын да тырышыбрак башкаруга кайтып кала.

Мисал эзләп ерак китәсе юк. Коронавируска бәйле тыюлар чорында (авыру котырган чорда түгел, ул зәхмәт бетмәде һәм бетмәячәк тә), Чаллы шәһәр судының хөкемдары чып-чын рекорд куйды. 2 ай эчендә ул 1800 гә якын карар чыгарган, мае аеның бер көнендә 252 эшне хәл иткән. Шуларның 100 дән артыгын ярты сәгать эчендә «этмәлләп» куйган. Бер карар чыгару өчен җәмгысы 16 секунд сарыф ителгән! Менә ни икән ул эшне камилләштерү! Югыйсә, һәр очракны аерым өйрәнү, хокук бозуның нинди шартларда булганын тәфсилләп сорашу таләп ителә. Ләкин алай гамәл кылганда, Татарстанны маскасыз йөргән өчен штраф чәпәүдә алдынгы төбәк рәтенә кертеп булмый иде бит. Ә бернинди файдасы булмаган масканы борынга кутәреп куймаганга гына да өч-биш мең сум штраф түләтү очраклары билгеле. Димәк, Чаллы судьясы бер көндә генә дә казнаны якынча 750 меңгә баеткан. 16 секунд саен бер эшне хәл иткән хөкемдар, әлбәттә, җансыз машина түгел, киресенчә, тере машина!

Хөкемдарлык эше гаеплене эзләү белән мәшгуль прокуратура, тикшерү комитеты һ.б. ларның ихтыярын үти торган органга әйләнеп бетте дияргә мөмкин. Моның объектив сәбәпләре дә бар. Җинаять эшләрен карый торган судларда элек әнә шул органнарда эшләгән затлар утыра. Аларның бөтен дуслары, хезмәттәшләре дә шунда калган. Теге яки бу судка судья билгеләү турында карарда төп сүзне президент администрациясе комиссиясе әйтә, ә бу комиссиядә нигездә – шул ук көч структуралар вәкилләре. Алар исә күңелләренә хуш килмәгән кандидатны судья кәнәфиенә уздырмый. Нәтиҗәдә, казый прокуратура, тикшерү комитеты һ.б. башкарган эшкә мөһер сугып баручыга әйләнә. Мондый вәзгыять дөньядагы күп илләрдә күзәтелә. Чөнки капиталистик дәүләт белән еш кына зур акчага ия затлар идарә итә, хөкем чыгаручыларны да алар куйдырта. Бу яктан караганда, СССРда сайлап куюга нигезләнгән суд системасы күпкә гаделрәк эш йөрткән. Сәяси мәсьәләләрдәге, сайлап алудагы житешсезлекләргә карамастан, совет чорында суд эскәмиясенә эләккән кешенең аклану мөмкинлеге хәзергегә караганда шактый зуррак булган.

РФ Югары Суды мәгълүматлары буенча, 2022 елның беренче яртысында Россиядә 607 аклау карары чыгарылган. 229170 кешенең җинаять эшләре гомуми тәртиптә каралган, шуларның 20080 гә якыны (хөкем карарын гамәлдән чыгаруга шикаять саны буенча фикер йөрткәндә), үз гаебен тулысынча кире каккан. Башка сүзләр белән әйткәндә, үзен бер гаепсез дип санаган 20 меңнән артык кешенең нибары 3 % ы гына аклануга өмет итә алган. Бу исә – Россия суд системасы тарихында иң түбән санның берсе. 2010 елда аклану форсаты гаебен кире кагучыларның 5,6 % ында, ә 2021 елда – 3,5 % ында булган.

Шул ук вакытта 2022 елның беренче яртысында присяжныйлар суды хөкем ителүчеләрнең 28 % ын, яки 591 кешенең 166 сын аклаган. 2021 елда алар суд каршына басканнарның 31% ын гаепсез дип тапкан. Гаебен кире кагучыларның 30 % ын аклауны норма дип санасаң, быелтыр беренче яртыеллыкта присяжный тарафыннан аклана алган кимендә 5254 кеше хөкем ителгән. Шуларның 1500 дән артыгы төрмәгә эләккән.

Россиядә якынча 2000 елда башланган, 2008-2012 елларда аеруча көчәйгән хакимият вертикален ныгыту сәясәте судьяларны, көч органнарын бу эшнең бер башкаручысына әйләндерде. Халык теләге белән яки актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә урыннарда хакимияткә килгән үзсүзле түрәләрнең (алар арасында министрлар, төбәк башлыклары, мэрлар һ.б. бар) бик тиз гөнаһлары табылды һәм алар рәшәткә артына озатылды. Ә шул ук вакытта миллиардлаган сум акча урлавы бер шик тә уятмаган Оборона министры исә иректә калу гына түгел, шәп кенә вазыйфага билгеләп тә куелды. Андый төр җинаятьләр өчен канунда «шартлы хөкем» каралмаса да, бу эштә анысын да рөхсәт иттеләр. Министрның мәгъшукасы исә берничә айдан иреккә чыгарылды. Ил казнасына миллионлаган гына түгел, миллиардлаган зыян салган затларның төрмәгә ябылмавы халыкны шаккатырды һәм суд системасына ышанычны тәмам какшатты. Ил башлыгы исә бу гауганы тикшергәндә, Россиядә хөкем системасының гуманлылыкка баруы турында сүз кузгатты. Шулай да булсын, ди. Тик соңгы елларда илебезнең әле бер, әле икенче төбәгеннән алынган хәбәрләр судьяларның кешелексезлеккә йөз тотуын күрсәтә. Шөрепләрне тыгызрак боруны, Мәскәү кулын ныгытуны, илдәге милли төрлелекне кулдан килгәнчә юкка чыгаруны максат иткән хакимияткә нәкъ шундый казыйлар кирәк тә.

Һәм алар үзләренә йөкләнгән вазыйфаны берсүзсез үти дә. Милләтпәрвәрләрне кысрыклау, аларны һәр сүз өчен җәзага тарту, штрафлар белән күмеп ташлау татар халкының милли хәрәкәтен судьялар кулы белән таркатуның бер ысулы булды. Ул гына да түгел, 90 нчы елларда, милли хәрәкәт көчәйгән чакта әйткән сүзләрне, басылган китапларны да казып чыгарып, кырыс хөкемгә тарттылар. Ислам диненә кагылышлы бик күп басмаларның тыелуы да – шул шаукым бәласе. Судьялар хәтта Коръәнне дә экстремистик әдәбият исемлегенә кертергә маташты, ләкин бу барып чыкмагач, андагы мәгълүм аятьләр (алар нәсара һәм яһүд динендәгеләргә мөнәсәбәт турында) кергән бөтен китапларны, ниндидер карагруһ белгечләрнең копия рәвешендә эшләнгән экспертизаларын нигез итеп алып, экстремистлыкта гаепли һәм тыелган әдәбият исемлегенә кертә башлады. Фәлән секунд саен карар чыгарып торган судьялар ул китапларның асылын, әһәмиятен тикшереп тә азапланмый. Тагын да аянычрагы шул: өйләрендә ниндидер китап табылган өчен генә дә, тыелган дини оешмалар белән бәйләнештә гаепләнеп, күпме мөселман нахакка иректән мәхрүм ителде, төрмәләргә ябылды.

Судларның шөрепләрне боруда ак-караны күрми башлавына, тикшерү органнары биргән мәгълүматларга сукырларча ышануына кына эш итүенә өр-яңа мисал. Кызганыч та, бераз көлке дә хәл.

Красноярск краендагы хәрби суд Канск шәһәрендә өч укучыга карата хөкем карары чыгарды, аларны Федераль куркынычсызлык хезмәте һәм полиция биналарын шартлатырга әзерләнүдә гаепләп. Бу яшүсмерләр билгеле бер компьютер уенында (!) виртуаль бинаны шартлату турында хат алышкан икән. Суд карары буенча, 16 яшьлек Н.У. биш елга хөкем ителгән – аны суд залында кулга алганнар. Яшүсмергә шулай ук 30 мең сум штраф салынган. Тикшерүдә ярдәмнәрен исәпкә алып, калган ике яшүсмер терактлар әзерләүдә гаепләү буенча җинаять җаваплылыгыннан азат ителгән, әмма шартлаткыч матдәләр белән эш йөрткән өчен дип, алар өч һәм дүрт елга шартлы рәвештә иректән мәхрүм ителгән. Хөкүмәткә каршы гамәл уйда да, уенда да булырга тиеш түгел икән!

Ә түбәндәге хәлләр – бөтенләй башка тараф. Махачкалада элекке хатынын кыйнап һәм буып үтергән полиция хезмәткәрен исә хәтта зинданга да япмыйлар, судья аның иреген билгеле бер дәрәҗәдә чикләргә генә карар чыгара. Янәсе, ир котырып китеп, үзенең ни кылганын белмәс хәлдә булган икән. Санкт-Петербургта башка бер погонлы зат үзенең эш бүлмәсендә тезләнеп торган кешене атып үтерә. Моны ул ялгышлык белән эшләнгән гамәл дип аңлата, янәсе, пистолетны бер кобурадан икенчесенә күчергәндә, үзе дә сизмәстән тәтегә баскан.

(Дәвамы 4 нче биттә).

МҖ Җидегән вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

Сафсаталы сәясәт

26 гыйнвар Татарстан тарихына, мөгаен, иң хурлыклы көннәрнең берсе булып кереп калыр. Дәүләт Советы бу көнне Татарстан Конституциясенә «суверенитет» төшенчәсенең эзе дә калмаслык итеп үзгәртә торган төзәтмәләр кертте. Мәгълүм булганча, Татарстанның яңа чордагы Төп Законы, 1992 елның 21 мартында республиканың хокукый вә сәяси статусын билгеләү буенча халыкара нормаларга туры китереп үткәрелгән референдум нәтиҗәләре нигезендә, 1992 елның 6 ноябрендә – РФ Конституциясеннән алдарак та кабул ителгән иде. Республика җитәкчелеге ул чорда Дәүләт суверенлыгы турында декларацияне реаль эчтәлек белән баету хакында күп сөйләде һәм башта бу юнәлештә хәтта кайбер адымнар да ясалды. Тик хокукый статусны халыкара дәрәҗәдә таныту буенча бернинди дә алга китеш булмады. Төп игътибар илдә федерализмны ныгытуга, федераль үзәк белән мөнәсәбәтләрне ике арада вәкаләтләрне бүлешү юлы белән җайга салуга бирелде. Вәләкин Россия шартларында болар һәммәсе дә сафсата булып чыкты. Ә яуланган үрләрдән чигенүләр Татарстанда 1994 елның февралендә Россия белән ике арада вәкаләтләрне чикләү буенча килешү төзүдән башланды. Хакимият вертикале корылып, төбәкләр белән вәкаләтләрне демократик нигездә бүлешүгә ихтыяҗ беткәч, Мәскәү андый килешүдән баш тартты. Ә соңгы елларда җитди деградация кичергән әлеге мөнәсәбәтләр узган атнада инде Татарстанда дәүләтчелек төшенчәсенең нульгә чыгарылуына да китерде, гәрчә бу кәлимә үзе Төп Законда әлегә саклапса да.

Газетабызның быелгы беренче санында (МҖ.№1, 13.01.2023) бүгенге сәер хәлләргә кагылышлы сүз инде булган иде. Шуңа, кабатланмас өчен, 26 гыйнварда көтелмәстән урын алган үзгәрешләргә генә тукталырбыз. Әлбәттә, игътибарны иң элек әле күптән түгел генә «президент» атамасын «глава – рәис» дип үзгәрткән законга янә төзәтмә кертелүе җәлеп итә. Нәтиҗәдә, гамәлдәге президент инде хәзер үк «рәис» дип атала. Дөрес, күпләр өчен бу – кысыр кайгы. Ә төп игътибарны ТР Конституциясенең референдум аша гына (123 нче маддә буенча) үзгәртелә ала торган 1 нче маддәсенә кертелгән төзәтмә җәлеп итә. «Суверенитет» төшенчәсе анда Дәүләт Советы тарафыннан бернинди референдумсыз гына бетерелгән. Ә бар идеме соң аның моңа вәкаләтләре? Бу көнне Төп Законга төзәтмәләр 60 маддәгә кертелгән һәм, нәтиҗәдә, 25 юридик норма үз көчен югалткан. Иң гаҗәпләндергәне – ул төзәтмәләр, фикер алышу вә сорауларсыз гына, бер көндә өч укылышта да кабул ителгән. Парламент рәисе исә ашыгуны прокуратура кушуы белән аңлаткан. Формаль яктан ул, бәлки, шулайдыр да. Тик, миңа калса, Татарстан президентына төп күрсәтмә 23 гыйнварда Кремльдә очрашканда бирелде кебек. Сорау туа: тышкы хәле үтә дә катлаулы Россиядә, эчке вәзгыятьне дә кыздыру бүген кемгә кирәк?

Соңгы вакытта татар дөньясында кызу бәхәсләр 2021 елда үткән җанисәп нәтиҗәләре тирәсендә дә бара. Аның рәсми булмаган мәгълүматлары буенча, Россиядә татарлар саны – 600 мең кешегә (11 процентка), туган телдә сөйләшүчеләр исә бер миллионнан артык кешегә кимегән булып чыга. Бу – иң начар күрсәткеч. Җәмәгатьчелектә һәм галимнәр (демографлар, этнографлар һ.б.) арасында сүз нәтиҗәләрнең дөреслеккә туры килмәве, җанисәп институты үзен дискредитацияләве һәм хәтта аны яңадан үткәрү кирәклеге хакында да бара. Чарада урын алган хәрәмләшү юнәлешләре исә аның сәяси максатлы булуын күрсәтә һәм сүз бу очракта татар белән башкортны чәкештерү турында гына бармый. Мәгәр, рәсми булмаган мәгълүматның болай синхрон «тишелүе» дә күп нәрсә турында сөйли. Шулай итеп, татар бүген телсез, мәгарифсез, җирсез, милексез һәм хокуксыз да кала булып чыга. Дәүләтчелеге дә «бармы – бар» өчен генә калдырыла, ассимиляция исә кызу (11%) темпта бара. Нәрсә бу? Геосәясәттә бүген бер зур халык «сәясәт коралы» итеп кулланылган кебек, кемнәрдер илдә сан ягыннан икенче урында торган халыкка да эчке сәясәттә охшаш роль әзерли түгелме? Юкса, «очкын» гына җитми. Ә социаль челтәрләрдә инде алары да (төрле вариациядә читтә әзерләнгән, татар турында дөреслекне ярып салган видеолар) күренгәли башлады. Янә сорау: гамәли синхронлык Көнбатыш һәм Россиянең зур сәясәттә, капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда эш итүенә тагын бер дәлил була түгелме?

Әлбәттә, коткыга бирелү – татар юлы түгел. Чөнки ватандашлар сугышы аның үзен дә, башка халыкларны да фаҗигага гына китерер иде. Татар юлы бүген рухи яңарыш һәм илаһият кануннары (киң мәгънәдә) буенча яшәүгә күчүдә үрнәк вә әйдәп баручы көч булуда. Ә ул – кешене мәнсезлек вә рухи деградация упкынынан йолып калуның бердәнбер юлы.

Фоат УРАЗАЙ.

Хәзинә китап

«Безнең мирас» журналы редакциясендә Йосыф Баласагунинең якынча 1069-1070 елларда иҗат ителгән «Котадгу белек» әсәре китап булып басылып чыкты. Төрки халыкларның күләмле тәүге язма шигъри әсәре татар телендә бу рәвешле беренче тапкыр дөнья күрде.

Әсәрне борынгы төркичәдән хәзерге татар теленә филология фәннәре докторы, профессор Рифкать Әхмәтьянов моннан 15 ел элек тәрҗемә итә. Галим аны Зәки Вәлиди тапкан тулы нөсхә нигезендә шигъри телдә эшләгән, моңарчы башка телләрдә басылган тәрҗемәләрне дә өйрәнгән. Шунысы да гыйбрәтле: «Котадгу белек» «Знание, дающее счастье» исеме белән рус телендә Мәскәүдә 1983 елда басылып чыккан. Бу әсәрне XIX гасыр ахырында хәтта атаклы тюрколог В. Радлов та шактый тәфсилле өйрәнгән.

Китап басылу уңаеннан уздырылган матбугат очрашуында «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон басманың тәүге нөсхәләрен Р.Әхмәтьяновның улы Хәйдәр һәм кызы Сәриягә бүләк итте, Йосыф Баласагунинең беренче тапкыр портретын ясаган рәссам Булат Гыйльвановка, китапны чыгаруда күп тырышлык куйган редакция хезмәткәрләренә рәхмәтләрен җиткерде.

Казан университеты профессоры, әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов «Котадгу белек» әсәрен бәһаләп бетергесез җәүһәр дип атады, андагы фикер тирәнлегенә басым ясады. «Башка халыклар булса, андый хәзинәне бөтен дөньяга күрсәтер иде. Китапны чыгару гына түгел, аны тарату, пропагандалау да мөһим», – диде галим.

«Котадгу белек» Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән басылган. Конгрессның Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров милли горурлык чыганагы булган китап һәр татарның өстәлендә, киштәсендә торсын иде дигән теләген белдерде. «Котадгу белек»тәге афоризмнар, мәкаль-әйтемнәр радио-телевидениедән яңгырарга, күрсәтелергә тиеш дип саный ул. Д. Шакиров «Безнең мирас» журналының Й.Баласагуни әсәрендәге канатлы сүзләрне китапчык итеп чыгару тәкъдимен дә хуплады.

Каз ризыклары остаханәсе

Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев «Каз өмәсе»н үткәрү татарларда борынгыдан ук килгәнлеген һәм аны халкыбызның брендына әверелдерү кирәклеген, монтан тыш милләтебездә казларга бәйле күп кенә гореф-гадәтләр (туй казлары, килен мендәрләре һ.б.) саклануын әйтеп, каз кулланып пешерелә торган милли ризыкларыбыз, ашларыбыз өчен дә аерым номинация булдырырга кирәк икәнлеген әйткән иде.

Шул ук вакытта Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре җыены кысаларында татар халык ашлары буенча аерым координацион совет та оештырылды. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров бу уңайдан ризык әзерләү, аны тәкъдим итү татар кунакчыллыгының бер юнәлеше һәм өлеше булуын искәртеп, үзебезнең азык-төлек, һөнәрчелек һәм башка өлкәләрне бренд буларак күтәрәчәкләрен белдерде.

«Ак Калфак» татар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы, Татар эшмәкәрләренә ярдәм итү ассоциациясе инде ике ел рәттән Бөтенроссия «Каз өмәсе» фестивален үткәрде. Анда Милли Шура рәисе искәрткәнчә, каз кулланып пешерелә торган милли ризыкларыбыз, ашларыбыз өчен дә аерым номинация булдырылган иде. 2021 елны каз бәлеше пешерү буенча Оренбург өлкәсе Переволоцкий районы Чесноковка авылыннан аш-су остасы Минзәлә Гайнуллина II Бөтенроссия «Каз өмәсе» фестивалендә Гран-при иясе булды. Шушы ук Россия буенча үткәрелгән фестивальдә Саба районы Иләбәр авылыннан мәдәният йорты директоры Рамил Хафизов каз муены тутыру буенча 1 урын яулаган иде.

Фестивальдә җиңүчеләр Казанның «Туган авылым» ресторанында казның эч-башыннан ризыклар әзерләү буенча осталык дәресләре үткәрде.

Гран-при иясе Минзәлә Гайнуллина камыр басып, казның эч-башын туралган

бәрәңге белән болгатып, тәмләткечләр кушып бик тәмле бәлеш пешерде.

«Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары оешмасы рәисе, татар халык ашлары советы җитәкчесе Кадрия Идрисова милләтебезгә хас булган яңа төрле ризыклар да булырга тиеш, дип белдергән иде. Бу уңайдан аш-су остасы Рамил Хафизов менә шундый яңа төр ризык әзерләү ысулын тәкъдим итте. Ул бүтәкә, йөрәк, эч маен, суган, сарымсакны иттарткычтан чыгарып, шуңа бөрттерелгән дөге, тоз, борыч кушты һәм болгатып бер башы тегелгән муенга тутырды. Аннары аны фольгага төреп мичкә тыкты. Аның тутырган муены да һәркемнең күңеленә хуш килде. Ресторанның оста ашчысы Әхәт Дәүләтов кунакларга казның эч-башын чүлмәктә пешереп күрсәтте һәм каз бавырыннан әзерләнгән торт белән сыйлады.

Сөембикә КАШАПОВА.

Автор фотолары.

1 нче биттә – К. Тинчурин театрының «Идегәй» спектакле премьерасыннан бер күренеш. Салават Камалетдинов фотосы, «Татар-информ».

Еллык эшкә нәтиҗә

●Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова.

●Татарстан Президенты Р.Миңнеханов коллегия утырышы кысаларында шагыйрь Ләис Зөлкарнәй, җырчылар Алинә Шәрипҗанова белән Филүс Каһиров (фотода) һ.б.га дәүләт бүләкләре тапшырды.

Татарстан Мәдәният министрлыгының коллегия утырышында үткән елга нәтиҗә ясалды. Эшлекле сөйләшүдә республиканың илбашы Р.Миңнеханов та катнашты.

Мәдәният министры Ирада Әюпованың сүзләренә караганда, быелтыр мәдәният чараларына йөрү планы 14,5 процентка арттырып үтәлгән. Бюджеттан тыш керем күләме өч тапкырга арткан. Акча эшләүдә аеруча Казан циркы, «Әкият» курчак театры алга киткән. Алдынгылар рәтендә Татарстан сынлы сәнгать музее, Милли китапханә, Чаллы татар дәүләт драма театры да бар. Түбән Кама театры исә бу мәсьәләдә бераз калыша.

Пушкин картасының гамәлгә керүе тамашачыларның концерт, театр, кинотеатрларга йөрүен активлаштыруга да карамастан, 68,3 процент халыкның карталарында акча тотылмыйча кала икән. Бу хәл бигрәк тә авылларда яшәүчеләрдә күзәтелә. Министр Ютазы, Тәтеш, Спас районнары башлыкларын Пушкин картасы белән активрак эшләргә өндәде.

Тамашаларга билетларның туксан проценты интернет аша сатылуы – үткән ел нәтиҗәләре арасында уңай күрсәткечләрнең берсе.

Авыл клублары мәсьәләсе бик борчуга сала. 2012 елда Азнакай районында, мәсәлән, өч клуб начар хәлдә булса, хәзер бу сан сигезгә җиткән. Районда махсус программа буенча 14 яңа клуб сафка баскан югыйсә. Югары Ослан районында да 7 яңа мәдәният йорты төзелүгә, тагын бишесендә сипләү эшләре үткәрелүгә карамастан, хәрабә хәлендәге клублар саны 6 дан 14 кә җиткән. Зәй, Сарман һәм республикабызның тагын берничә районында клуб биналарының җимереклеге, ремонт таләп итүе көн үзәгендә кала.

Министр президент грантында актив катнашу җәһәтеннән канәгатьлеген белдерде. Чыннан да, грант сорап мөрәҗәгать итүчеләр саны ягыннан Татарстан икенче урында. Әмма яуланган грантлар саны нибары 7,8 процент тәшкил итә. Бу хәл грантларга мөрәҗәгатьләрне дөрес оештыра белмәвебезне күрсәтә. Бу җәһәттән Ирада ханым аеруча муниципаль районнарны уяулыкка чакырды.

Коллегия утырышында Әтнә татар дәүләт драма театры директоры Ленур Зәйнуллинның театрның казанышлары турында саф татарча яңгыраган чыгышы бик уңай тәэсир калдырды. Былтыр алар классикларыбыз Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Галимҗан Ибраһимов әсәрләре буенча куелган спектакльләре белән тулы заллар җыйды, театры оештыручыларның берсе Гомәр Мәрданов истәлегенә фестиваль оештырды, Грозныйга фестивальгә, Кыргызстанга гастрольгә барды. Чаралар саны – 20 процентка, тамашачылар саны – 36, матди керем – 17, онлайн сатылган билетлар саны 10 процентка арткан. Пушкин картасы белән 3 мең билет сатып алынган. Быел исә ГИТИСны тәмамлаучыларның диплом спектакльләрен кую, балалар һәм яшүсмерләр арасында республика күләмендә драматургия бәйгесе үткәрү, мартта – Мәскәүгә, майда Дагстанның Дербент шәһәренә бару каралган.

«Инвожо» удмурт фольклор ансамбленең хормейстеры Владимир Әхмәтов балаларның Уен-фестта гран-при алып Сочига барулары турында горурланып сөйләде һәм 17 июньдә Кукмара районы Нырья авылында үтәчәк Гырон быдтон милли бәйрәмнәренә чакырып калды.

Бүген мәдәниятка һөҗүм барган, Коръән китаплары яндырылган заманда бу өлкәгә аеруча зур игътибар кирәклеге чыгыш саен искәртелде.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

КАЗЫЙГА ХӨКЕМ ЮК

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Полиция хезмәткәре 1 ел да 9 айга колониягә озатыла, тикшерү изоляторында утырган вакытын исәпкә алып, 3 айдан өенә кайта. Кеше гомерен өзгән бу бәндәләр бөтенләй җәза күрми диярлек.

Ә хәзер милләттәшебез, өметле математик Азат Мифтаховны искә алыйк. Хөр фикерле Азатны «Бердәм Россия» партиясе офисына һөҗүмдә гаеплиләр. Күп шаһитләр аның бу эшкә катнашы юклыгын әйтеп торса да, суд гаепләү тарафын гына тыңлый һәм алар таләп иткән хөкемне чыгарып, галим егетне 6 елга гомуми режимдагы колониягә озата.

Менә шушы мисаллар гына да илебездә судьяларның никадәр җансыз машина булуын, хакимияткә «ләббәйкә» дип торган система шөребенә әверелүен күрсәтә. Ләкин дәүләт хөкемдарларны искиткеч яклый һәм аларның кагылсызлыгын закон белән саклый. Судья башкалардан берни белән дә аерылмаган зат булса да, юлда кагыйдә бозган өчен, хәтта аны туктатырга да ярамый. Хәтта күрәләтә җинаять гамәл кылса да, судьяны кулга алу тыела. Моның өчен әүвәл аның хөкем чыгару вәкаләтләрен туктату таләп ителә. Илдә андый очраклар булыштыра, әйтик, 2015-2019 ел мәгълүматларыннан күренгәнчә, бу 5 елда 125 судьяның вәкаләтләре вакытыннан алда бетерелгән. Бик мөмкин ки, әлеге 125 хөкемдарның күбесе чынлыкта гадел, ләкин хакимият күңеленә хуш килмәгән хөкем чыгарган булгандыр.

Судьяларны канун башка яктан да яклый. Судьяга гаделсез, дөрес булмаган карар кабул иткән өчен җәза бирергә ярамый, ягъни законга каршы килгән карар чыгарган булса да, судьяны барыбер җәзага тартмаячаклар.

Әгәр судья законсыз хөкем карарын кабул итүен белә торып эшли икән, РФ Җинаять кодексының 305 нче маддәсе нигезендә җаваплылыкка тартырга мөмкиннәр анысы. Моның өчен 300 мең сумга кадәр (хөкемдарларның хезмәт хакын исәпкә алганда, бу чәйлек кенә акча) штраф каралган. Анысында да штраф зыян күрүчегә түгел, ә дәүләткә түләнә. Судьяга җинаять эше кузгату – гаҗәеп сирәк очрак, бу хакта карарны Тикшерү комитеты рәисе һәм махсус орган – судьяларның квалификация коллегиясе кабул итә. Мондый җәза инде тәмам чикләрне тибәргән хөкемдарларга карата гына кулланыла. Әйтик, 2018 елда Волгоград өлкәсендә судья, суд утырышын үткәрмичә генә, хөкем карары чыгарып куя. Гаепләнүчене, аның адвокатын, прокурорны судка чакырып тормый, ялган беркетмә төзеп, анда утырыш үткәнлеген һәм барлык тиешле затларның катнашуын теркәп куя. Судьяга 200 мең сум (!) штраф салына. Дөрес, Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгы хөрмәтенә амнистия сылтавы белән, ул бу җәзадан да азат ителә. Судларның кемгә карата кешелеклерәк булуы шуннан аңлашыла булыр.

Мәсьәләнең башка ягын да уйлап карыйк. Судьяларга хөрмәт күрсәтелә дә, ник башкаларны тәрлечә кимсетүгә юл куела? Әйтик, укытучылар халыкка, илгә казыйларга караганда мең тапкыр күбрәк файда китерә – киләчәк буынны тәрбияли. Ләкин алар хәзер җәмгыятьнең иң яклаучысыз вәкилләренең берсенә әйләнеп бара. Балаларга тавыш күтәрергә ярамый, коену киеменнән фотога төшерергә ярамый – мондый хәлләр турында хәтта ил дәрәҗәсендә гауга куптаралар, ә мөгаллимнең үзен исә тибеп узсаң да була – балалар да, аларның ата-аналары да җәзасыз кала. Асылда кагылсызлык дигән нәрсә судьяга түгел, халык белән эшли торган башка һөнәр ияләренә – укытучыларга, табибларга кирәк, алар моңа күпкә лаек.

●Кытайда дөньяда беренче космик кояш электр станциясе төзергә һәм аны Җир өстеннән 36 мең километр биеклектә урнаштырырга җыеналар.

●Согыд Гарәбстанында биеклеге 2 километрлы күктерәр йорт төзергә ниятлиләр, бу 5 миллиард долларга төшәчәк. Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәге хәзерге вакытта җиһанда иң биек саналган Бурж-Хәлифә манарасының биеклеге исә 828 метр тәшкил итә.

●Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәге Dubai Miracle Garden паркы дөньяда иң зур табигый бакча санала, анда 72 мең квадрат метр мәйданда 250 миллион үсемлек һәм 50 миллион чәчәк үсә, аларга һәр төн саен 757 мең литр су сибелә. Гаҗәеп бакча эчендәге тыюлыкта 26 төрдән булган 15 мең күбәләк яши.

ДРАМАТУРГ КАПИТАН

Эксперт-криминалист, полиция капитаны Артур Ибраһимов «Яңа татар пьесасы-2022» бәйгесендә берьюлы ике җиңү яулады. «Бабайның бабасы» фантастик комедиясе 2 нче урынга, «Күрше авыл догалары» пьесасы 3 нче урынга лаек табылды.

Филология, журналистика кебек юнәлештән шактый читтә торган кешенең әдәбият мәйданына чыгуы әлмәтлеләр өчен сенсация булды. «Татнефть» берләшмәсенең генераль директоры урынбасары булып эшләгән Үзбәк Саттаровтан соң, әдәбиятта бу – икенче күренеш. Шуңа да без әлеге «уникаль табыш»ны редакциягә кунакка чакырдык.

Артур Ибраһимов бүлмәгә үзе белән бер кочак яктылык, җиңеллек, уңай эмоция алып керде.

– Артур, бу эш ничек башланып китте?

– Туфан Миңнуллин әйтмешли, «Татар халкы пьесаларны укырга ярата». Мин дә шулар рәтенә керәм. Биш ел чамасы элегрәк пьеса язып карарга булдым. 2019 елда үземә ышанып бетмичә генә конкурста катнаштым. 2022 елда инде күңелдә өмет ныгыды. Конкурс ябык иде бит. Аның ябык булуы яңа исемнәрне ачарга мөмкинлек бирәдер дә. 2019 елда Алабуга егете Артур Шәйдулла лауреат исемен алды һәм миңа этәргеч ясады. Ул да белеме буенча юрист. Шуны күреп, мин дә үземне сынап карарга булдым.

– Сине драматургия кай ягы белән җәлеп итте?

– Татар әдәбиятына мәхәббәтне мәктәп елларында ук сеңдерделәр. Укытучыларыма рәхмәт. Башта мин чәчмә әсәр язып карарга булдым, килеп чыкмады. Дөресе, сүз байлыгы, аннары вакыт та җитмәде. Чәчмә әсәр фикерләрне чуалдырмыйча, туктаусыз утырып язуны таләп итә бит ул. Шуңа мин пьесага күчеп карарга булдым. Драма үзе бер дөнья, анда икенче төрле фикерләргә кирәк. Караламаларны ертып ата-ата, байтак интегәсең. Аннан инде тынычланып төрле интевьюларны, татар, рус, чит ил драматургларының әсәрләрен укулар... Драматургия теориясен укып өйрәнгәнче, әсәрләрне укып тәҗрибә туплау миңа кулайрак булды.

– Бу бәйгедә бит әле тамашачыны җәлеп итәрлек яңа фикер дә яңгырарга тиеш...

–Минем яратып укыган икенче жанр – фантастика. Яшьтән үк табигать фәннәре белән кызыксына идем. Рус, чит ил фантастларының әсәрләрен яратып укыйм. Соңгы елларда үзем өчен татарлардан Адлер Тимергалинны ачтым. Ул математик, астроном, күбрәк фәнни-фантастика әсәрләре иҗат иткән. Фантастика белән драматургияне бергә берләштерү үзеннән-үзе килеп чыкты. «Бабайның бабасы» комедиясен бик яратып яздым. Үземне канәгатьләндергән беренче әсәрем. Аны язганда, материаллар туплаганда да үзенә күрә ләззәт кичердем.

– Үзеңнең театрга йөрергә вакытың каламы соң?

– Декабрь аенда Әлмәткә килүемә 10 ел булды. Әлмәткә килгәч тә, беренче эш итеп, театрга бардым. Гадәттә хатыным белән йөрибез. Бик еш түгел, ләкин бер премьераны да калдырмаска тырышабыз.

– Бүгенге драматургиягә нәрсә җитми дип уйлыйсың?

– Хәзерге драматургларның әсәрләрен күзәтеп барырга тырышам. Һәрберсенең ниндидер аерылып торган ягы бар. З.Хәкимнең театраль романнары, И.Зәйниев инде үзе театр кешесе, ул театр таләп иткән дәрәҗәдә яза. Бу бәйгедә С.Юзеев белән таныштым. Артур Шәйдуллада яшьләрне кызыксындыручы темалар бар. Аның «Сагынырсызмы?» дигән пьесасы Камалда куелды. Шул ук Артур Шәйдуллага килгәндә, аның антиутопия, киберпанк фикерләре миңа ошый. Миңа калса, татар театрларына бүген яшьләрне тартуы, кызыктыручы шул темалар кирәктер.

– Әлмәт театры директоры Фәридә Исмәгыйлева бүген театрларга комедия җитми, ди. Килешәсеңме?

– Бүген, чыннан да, халыкка комедия кирәктер. Чөнки атмосфера шундый, кешенең кәефен күтәрергә кирәк. Ләкин тиешле фикерне, кирәкле сүзне драма житкерә икән, бүген аларга да урын бар, дип уйлыйм.

– Т.Миңнуллинның атаклы «Әлмәндәр»е кебек әсәр тагын булырмы, әллә андыйларны кабатлап куяргамы?

– Миңа калса, андый классик әсәрләрне яңартып сәхнәләштерү режиссердан тора. Камалда Ә.Еникинең «Рәшә» премьерасында булып кайттым. Әсәр әллә кайчан язылган, ә яшь режиссер Айдар Җаббаров аны бүгенге тамашачыны кызыксындырырлык итеп куйган. Талантлы режиссерлар күптән язылган классик әсәрләрне дә заманчалаштырып куя ала бит.

– Драма әсәре язу өчен вакыт каян табыла, иҗат ничек бара?

– Бер интервьюда Равил Сабыр: «Үз персонажларың артыннан язарга җитешергә генә кирәк», – дигән фикер әйткән иде. Мин аның белән тулысынча килешәм. Пьеса күләме ягыннан зур булмый. Эскизын бер-ике көндә язарга мөмкин. Ә инде чын буяулар өстәү өчен вакыт күп таләп ителә. Фикерләр еллар буе тупланырга мөмкин, аларны язып өлгерергә кирәк. «Күрше авыл догалары»н ике ел чамасы яздым. 3-4 тапкыр үзгәртергә туры килде.

– Артур, син Казанга барганда, призлы урын алганыңны белдеңме?

– Юк, конвертларны спектакль башланырга ярты сәгать калгач кына ачтылар. Мин 8 финалист арасында ике әсәрем булганын гына белдем.

– Бу хәбәрне иң элек кемгә әйттең?

– Хатын шунда иде, ул күреп белде, ә үзем шалтыратып әбиемә әйттем. Әбиемә минем мавыгуым аеруча ошый. Ул Иске Комазан авылында яши. Үзе дә шигырьләр язгалый.

– Дингә мөнәсәбәтең ничек?

– Мөселман дине традицияләре булган гаиләдә үстем. Әбиләрем өйрәткән догаларны һәрберсен хәтерлим. Дарвин теориясен бер семестр өйрәнсәм дә, сорауларым күп, шуңа күрә дингә ышанам.

Әлмәт татар дәүләт драма театры 17 гыйнварда үзенең яңа арт-мәйданында (музейда) Артур Ибраһимовның «Бабайның бабасы» исемле фантастик комедиясен укуны да оештырды.

Рәфкать ШАҺИЕВ.

Нәсел җепләрен барлап...

Хәзер телгә булган һәркем үзенең шәҗәрәсен төзү, нәселен барлау белән шөгыльләнә ала. Моның өчен теләк, вакыт һәм матди мөмкинлек кенә кирәк. Ә арабызда вакытны юкка-барга сарыф итмичә, милләте, авылдашлары һәм киләчәк буын өчен тырышучылар да шактый.

«Татшуган. Тарихи истәлекләр» дигән китапның авторы – менә шундыйлардан. Азнакай районы Татар Шуганы авылы мәктәбендә балаларга белем һәм тәрбия бирүче мөгаллимә Рузилә Шәйхулова туган авылы, аның тарихы һәм бүгенгесе турында китап язган. Ул – әдәби әсәр дә, фәнни хезмәт тә түгел, ә Татар Шуганы авылы турында җыелган мәгълүмат, тарихи сәхифәләр.

Бу авыл кызы булмасам да, китапны мин сөенеп кулыма алдым. Фотосурәтләрдән таныш йөзләрне, язулардан таныш исем-фамилияләрне эзләдем. Бар икән бит! Авыл китабына ир яклап туганнар да, күрше-тирә дә кергән.

Авыл турында гомуми мәгълүмат һәм топонимнар белән башланып киткән хезмәт Татар Шуганы авылының чишмәләренә, басуларына һәм Рузилә апаның истәлекләренә алып керә. Әйтерсең, автор белән кулга-кул тотынышып шунда йөрибез. Китапның беренче бүлегендә – авыл халкы, авыл урамнары һәм гореф-гадәтләребез. Авылыбызга килеп урнашкан, монда яшәп калган нәселләр турында архив материаллары.

Бер генә кешенең тормыш юлын тасвирласаң да, шушы авыл турында тулы картина барлыкка килә. Чөнки, авылда яшәеш, тормыш итү рәвеше барыбызныкы да бер төрле. Китапның иҗади бүлегендә автор үз нәселенең дә тарихи сәхифәләре, нәсел-нәсәбе белән таныштыра. Шулай итеп, бер нәсел үрнәгендә авылның тарихын ачып бирә.

«Кульязмалар янмый», диләр. Татар Шуганы авылы, аның халкы, аерым бер шәхесе турында газета-журналларда басылып чыккан мәкаләләрне туплап, аерым бер бүлек төзегән авторыбыз. Димәк, китап чыгару хыялы күптән туган булган.

Авылның тарихын ачу өчен, Р.Шәйхулова архив «тузаннарын» иснәгән, иске славян, гарәп, латин хәрефләре белән язылган язмаларны «сөреп» чыккан. Әле шулкадәр өйрәнгәннән соң да, авыл тарихында ачылып бетмәгән сер кала. Ревизия документларын, архив материалларын, истәлекләрләрне барлагач, авылга Тәмәй нәселе килеп урнашканлыгы ачыклана. Ләкин Тәмәй нәселе турында мәгълүматлар әле өйрәнеп бетелмәгән. Димәк, алга таба да эзләнергә, авыл тарихы турында күбрәк материал тупларга җирлек бар.

Гүзәлия ХӘЕРТДИНОВА.
Азнакай районы,
Татар Шуганы авылы.

АРЧА ТӨБӘГЕ САНДУГАЧЫ

Арча якларына барган саен, Казан арты төбәгенең йөзек кашы булган җырчы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Расих Галимҗанов башкаруындагы көй-моңнарны тыңлап, рухланып, хәтта горурланып кайтам. Теләсә кем сокланырлык, күңелне әллә кайларда йөртә торган саф, иркен, матур тавышлы җырчы авылдашым, лабаса. Ул да күренекле язучы Мөхәммәт Мәһдиев «Торналар төшкән җирдә»дигән повестендә яратып язган Саба районының Керәнне авылында туып-үсте.

Әтисе Әнгам абзыйның да «Юкә»не болыннарны яңгыратып җырлаганы хәтеремдә. Башлангыч классларукытучысы Маһирә апа Әхтәмова да, шуны истә тотып, Расихны I сыйныфка укырга кергәч, җырлатып карый. Малай Габдулла Тукай шигыренә язылган «Карлыгач» җырын өйрәнеп, беренче тапкыр сәхнәгә чыга, авыл клубларында куела торган концертларда катнаша башлый.

Маһирә апа, укучыларыннан ансамбль дә оештырып, аларны сәнгатькә тарта. Әмма V сыйныфка күчкәч, Расих өчен көй-моңнар онытылып тора, тавышына зыян килмәсен дигәннәрме, ул мәктәпне тәмамлаганчы, башка сәхнәгә чыкмый, җырламый. Шулай да тракторчы әтисе Әнгамның хромкада уйнавы, аннары җыр сузып җибәрүе, аңа Расихның да әкрен генә кушылуы, әнисе, укытучы Гөлфирә апаның аны яратып тыңлавы күңеленә рәхәт бер хатирә булып кереп кала.

Оясында ни күрсә, очканында шул, ди халкыбыз. Расих та баянда уйнарга өйрәнә, бу елларда, үзе өчен генә булса да, җырлый ул.

Галимҗановлар гаиләсе, Расих VIII сыйныфта укыганда, Арчага күченеп яши башлый. Егет биредә урта мәктәпне тәмамлый, армиягә китә. Аңа солдат хезмәтен Чехословакиядә үтәргә туры килә. Анда да җыр туган якларны, якыннарын сагынуны басарга булыша. Өч татар егете буш вакытларында бергәләп гармун сузып, милли көйләребезне яңгыратырга гадәтләнә.

Армиядән хезмәт итеп кайткан егетнең тормышына тагын җыр килеп керә. Расих Арча аяк киемнәре фабрикасына тегүче булып эшкә урнаша. Ә инде әти-әнисенең ир-егетнең төпле һөнәре булырга тиеш, дип һәрдаим искәртеп торуы аны Әтнә авыл хуҗалыгы техникумына алып килә, Расих читтән торып укырга керә. Чираттагы имтиханнарын тапшырып йөргән көннәрдә актлар залында яңгыраган җыр-музыкага игътибар итә. Моң яраткан егетнең күңеле түзми, залга кереп утыра. Ә анда концертка әзерлек бара икән. Егетне уку йортының музыка укытучысы күрә дә: «Бар, дәресеңдә бул», – дип, куып чыгара. Әмма егетнең уе дәрестә булмый инде, ул, укытучыны чыгып китте дип уйлап, кабат залга керә, җаен туры китереп, баянчыдан үзен дә җырлатып каравын сорый. Көйне сузып җибәрүе була, барысы да тынып кала. Музыка укытучысы да шунда булган икән, ул «Син безгә бик кирәк», – дип Расихны сессиягә килгән саен концертларда, мәдәни кичәләрдә катнаштыра башлый. Расих җыр дөньясына әкренләп кереп китә, үзе эшли торган фабрикада куела торган концертларда да аның җырлавын көтеп ала башлыйлар.

Сабан туе булган көнне районның зур спорт стадионында уза торган «Арча кичләре» дигән бәйрәмдә Расих та катнашырга ниятли. Егеткә шушы тәүге чыгышы ук уңыш китерә, аның җыры беренче урын белән бәяләнә. Расихка ул елларда дефицит булган бүләк – тузан суыргыч та тапшыралар. Арчалылар да бу чыгышны хәтерләренә төйнәп куя, аны барлык мәдәни чараларга чакыра башлыйлар, райондагы концерт-кичәләр дә Расихсыз үтми хәзер. Егет үзе дә җыр өлкәсендәге белемен арттырырга ниятли һәм Казан Мәдәният һәм сәнгать университетына укырга керә, аны уңышлы тәмамлый. Билгеле, югары белем алу ир-егетнең җыр иҗатын үстерү өчен зур ярдәм була. Сессия саен концертлар кую, уку йорты педагогларының киңәшләре, алган дәресләре аша Расихның җырлавы тагын да камилләшә.

Иҗат бәйгеләрдә дә ныгый һәм үсә, җырлау культурасы да арта бара. Расих Казанда үткән җыр бәйгеләрендә дә катнаша башлый. «Ватаным Татарстан» газетасы призына уздырылганында егетнең җыры икенче урынны ала. Дипломны Казан мэриясендә ул чактагы шәһәр муниципаль берәмлеге башлыгы Камил Исхаков тапшыра. Аннан соң да Расих бәйгеләрдә осталыгын чарлауны дәвам итә. Хәзер инде аның дипломнары да санап бетергесез. Хәтта авыл хуҗалыгы министрлыгы ярминкәләрендә даими чыгыш ясагач, Ратушага чакырып, рәхмәт белдерәләр. Казанда ул елларда уза торган «Уятмакчы булсаң халык күңелләрен» республика җыр фестивалендә дә өченче урын, аннан соң катнашканында икенче урынны ала. Ул, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең «Җырлыйк әле, дуслар» телевизион конкурсында үзенең яраткан җырын башкарып, бик күп күңелләрне яулый. Семинарларда, Казанның зур залларында үтә торган республика авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре бәйрәмнәрендә дә Расихның сәхнәгә чыгуын алкышлап каршы алалар.

Әлбәттә, Расихның иң яратып башкарган җырлары туган як турында. «Туган ягым бик кадерле. Су коенып үскән тугайларымны, чәчәкле болыннарны, җиләкле урманнарыбызны бик сагынам», – ди ул. Җырчының туган авылы Керәннегә кайтып концерт куюын да хәтерлиләр әле. Клуб тутырып утырган авылдашларыбыз Расих һәм аның төркеме куйган концертны өч сәгатькә якын бик яратып карады. Әмма Р.Галимҗанов өчен Арча да бик кадерле. «Шушы яклар мине җырчы итеп үстерде», – ди ул. Расихның җырларында сөю-мәхәббәт тә бар. Ул Арчада сөйгәнен табып гаилә корган, бер-берсен яраткан парның балалары үсеп җитешкән.

Арчада күптән инде Расихны «районыбыз сандугачы» дип йөртәләр. Чыннан да, тыйнак, тәрбияле, тәртипле ир-егет – бүген дә Арчаның иң матур тавышлы җырчысы. Дәрәҗәле кунаклар килсә дә, тантаналарда да, кичәләрдә дә Р.Галимҗанов – сәхнә күрке. Гомумән, Расих башкаруындагы җырлар – районда үтә торган һәр бәйрәмнең, тантананың бизәге. Р.Галимҗанов Россия өлкәләрендә уза торган Сабантуйларда да арчалылар исеменнән халкыбызның моңнарын милләттәшләребезгә җиткерә. Ленинград өлкәсенең Тосно шәһәрендә, Волгоградта, Самара өлкәсенең Гали авылында, Чуашстанның данлыклы Шыгырданында, Екатеринбургта, Пермь өлкәсендәге Барда районында, Төркиядә дә милләттәшләребезгә халкыбызның җыр-моңнарыбызны ишеттереп кайткан ул. Ә инде Арча ягында туып үскән әдәбият-сәнгать әһелләренең Казанның зур залларында үтә торган иҗат кичәләрендә ул затлы кунак. Алай гына да түгел, Расих Галимҗанов инде күп тапкырлар арчалыларны соло концертлары белән дә киндердергән.

Җырчының йөзләрчә җыры бар. Аның аеруча озын көйләрне яратып башкаруына да күп тапкырлар игътибар иткәнем булды. Расих башкаруындагы «Яшик сөенеп кенә», «Киек казлар», «Үтте дә китте яшьлегем», «Уфтанма» «Яшьлегем хисләре», «Уракчы кыз» кебек җырлар тыңлап туймаслык.

Расих Галимҗанов – инде өч дистә ел дәвамында Арча Мәдәният йорты каршында эшләп килүче автоклуб җитәкчесе. Ул үзенең иҗат коллективы белән һәрвакыт юлда. Җәйләрен районның төрле күмәк хуҗалыкларында кырда эшләүчеләр, ындыр табагында хезмәт куючылар алдында җыр-моңнарыбызны яңгыратып, аларның күңелләрен күтәреп, эшкә көч биреп китсә, кышларын районның хезмәт коллективларында, авылларның мәдәният учакларында, картлар йортларында концертлар куя. Аның сәхнәгә чыгуы теләсә нинди чараны бәйрәмгә әверелдерә.

«Сәхнә – минем өчен ял. Мин бүген инде тормышымны җырсыз күз алдына да китерә алмыйм», – ди ул.

Сөембикә КАШАПОВА.

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА

Кунак кызы булып кына Килә икән яшьлек безгә...

(Танылган шагыйрә, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Гөлшат Зәйнашеваның туууына 95 ел)

ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Сөйлә, дисәгез, сөйлимен
Үткән гомерем турында.
Үткән гомерем бер җыр, бәет –
Барсы чагыла җырымда.

Булды кагылып-сугылып,
Ятимлекләр күргән чагым.
Күгәрчен баласы кебек,
Йортсыз-җирсез йөргән чагым.

Булды ачлык тырнагында
Җан бирергә җиткән чагым.
Дусларны әҗәлдән йолып,
Кан бирергә әзер чагым.

Булды сандугачлар белән
Бергә сайрашкан көннәрем.
Җирдәге бәхеттән күккә –
Йолдызга ашкан төннәрем.

Булды эш, хезмәттә җиңеп,
Данга ирешкән чакларым.
Якын дуслар белән шатлык,
Бәхет бүлешкән чакларым.

Булды коега төшкәндәй,
Кайгыга баткан көннәрем.
Ай ярылган, йолдыз сүнгән
Шикелле кара төннәрем.

Булды ярты гәүдәм өзелеп
Калган кебек аерылулар.
Парлашып очып барганда,
Канатларым каерылулар.

Булды парымны җуйганга,
Аңымны җуйган чакларым.
Ялгызлыкка күнегалмый,
Дөньядан туйган чакларым.

Күңлемдә яшеннәр яшьни,
Бер кояштан, бер болыттан.
Шатлык һәм кайгы көрәшә,
Җырлар тумый бер дә юктан.

Тыңлыйсызмы, мин сөйлимен
Үткән гомерем турында.
Үткәннәрем бер җыр, бәет,
Барысы чагыла җырымда.

Барысы җырларга әверелеп,
Сибелеп калган эзләремдә.
Җырларыма сыеп бетми,
Моңы калган күзләремдә.

Үткәннәрем язым булган,
Бара гомерем хәзер көзгә.
Кунак кызы булып кына
Килә икән яшьлек безгә.

Үткән гомерем яшьлек булган,
Күкрәп-яшьнәп узып киткән.
И яшьлегем, синең белән
Саубуллашыр вакыт җиткән.

Хуш, яшьлегем! Очып киткән
Аккош кебек ераклаштың.
Мәңге кире кайтмас өчен,
Айга таба күккә аштың.

Үзең белән алып киттең
Мәхәббәтем хатирәсен.
Мәхәббәт яшьлек юлдашы
Дигәннәре хак, күрәсең.

Син китәсең, мин каламын,
Керфекләремдә яшь минем.
Аерылабыз, аерылабыз,
Хуш, яшьлегем, хуш, яшьлегем!..

ТУГАН ТЕЛЕМ

Рухыбызда туган тел син,
Җаныбызда туган тел.
Ясалма, килмешәк түгел,
Каныбызда туган тел.

Рухыбызда туган тел син,
Әткәм-әнкәмнең теле.
Борынгы бабабыз теле,
Болгар бабабыз теле.

Бишек җыры көйләгән тел,
Моңлы, ягымлы тел син.
Гашыйкларны таныштырган
Һәм кавыштырган тел син.

Зәңгәр күктән, кояш кебек,
Якты нур сипкән тел син.
Халкыбызны иманлы иткән,
Шәфкатьле иткән тел син.

Рухыбызда туган тел син,
Җаныбызда туган тел.
Ясалма, килмешәк түгел,
Каныбызда туган тел!

АК КҮГӘРЧЕН

(Баллада)

Бердәнберемне югалтып,
Ялгыз калгач башларым,
Ялгыз калган аккош кебек,
Мин упкынга ташландым.

Башларым ташка бәрелде,
Ләкин чыкмады җаным.
Эзләдем катырак ташлар,
Бәрелер өчен тагын.

Карыйм: упкынның төбендә
Бер ак күгәрчен яткан.
Бәргәләнгән томшыгыннан
Кып-кызыл каны аккан.

Ул да ташланган, ахры,
Ялгыз аккош шикелле.
Мөлдерәп күзенә карап,
Күгәрчен телгә килде.

Ул әйтте: «Бичара хатын,
Ник ташландың упкынга?
Ник син шулай үзең кердең
Әҗәл дигән капкынга?

Әҗәл үзе чигенгәнче,
Каршысына бар идең.
Аккош түгел, син бит Кеше,
Кеше булып кал идең!..»

Шулай диеп, ак күгәрчен
Йомды кинәт күзләрен.
Кошны кулларыма алып,
Бер үкседем, түзмәдем.

Җан өрергә теләп аңа,
Җылы сулышым өрдем.
Яраланган ак гәүдәсен
Яулыгым белән төрдем.

Кулларымда тоткач бераз,
Күзләрен ачты кошым.
Үзем суламыйм, ә аның
Тоям җылы сулышын.

Упкыннан чыгарга булдым,
Кошымны тоткан килеш.
Мин бит Кеше, мин бит кеше,
Һәм мин чыгарга тиеш!..

Яшәсен өчен күгәрчен,
Тәмам терелсен өчен,
Мендем упкынның өстенә,
Куеп мин бөтен көчем.

Хәлем бетте, тыным кыса,
Упкын калды түбәндә.
Омтылдым кояшка таба,
Күгәрчен баш түбәмдә!

Ак күгәрчен баш түбәмдә,
Очам диеп талпына.
Очма әле, ак күгәрчен,
Янымда бул аз гына!

Очма әле, ак күгәрчен,
Әйтер сүзем бар әле.
Син дә ялгыз, мин дә ялгыз,
Икебез дә яралы.

Бәлки, төзәлер яралар,
Төзәлер канатларың.
Ташлама мине, күгәрчен,
Бик газаплы чакларым...

* * *

Ялгызлыктан нишләргә, дип,
Зәңгәр күккә карадым.
«Ялгыз яшәргә өйрәт!» – дип,
Тулган айдан сорадым.

«Нигә ялгыз яшәргә?» – дип
Аптырады тулган ай.
Күктә мәңге яшәп, бик зур
Тәҗрибәсе булган ай.

«Син бит, – диде, – җир өстендә
Яшисең, син бит кеше!
Җирдә яшәгән кешенең
Бар гамәле, бар эше.

Ә гамәл, эш булган җирдә
Ялгыз калмый кешеләр.
Ник ялгыз калсын кешеләр,
Алар җирдә яшиләр!..

Чиксез галәмдә яшәп тә,
Ялгыз тоймыйм үземне.
Йолдызлардан якты алып,
Нурландырам йөземне.

Ялгызлыкка өйрәталмыйм,
Гафу ит!..» – диде аем.
Ялгызлыкка мәңгегә мин
Өйрәналмам, мөгаен.

КӨЗГЕ САГЫШ

Тагын ялгыз йөрим урманнарда,
Сагыну-сагышларга юк чама.
Чыршыларның ылыс керфегеннән
Күз яшьләре кебек чык тама.

Яфрак ява иңнәремә
Әкрен генә җилпенеп.
Пышылдап кына колакка,
Яратам, дигән кебек.

Җәйләр үтте инде, көзләр җитте,
Сагышларга салды урманны.
Үзәк өзгеч моң бар урманнарда,
Кошлар сайравыннан калганмы?

Җәй буена бер дә күрешалмадык,
Урманнарда бергә йөрмәдек.
Бергә йөрмәсәк тә, күңелләрдә
Бар безнең илаһи бергәлек.

Яфрак ява иңнәремә
Әкрен генә җилпенеп.
Пышылдап кына колакка,
Яратам, дигән кебек.

КЫШКЫ МОҢНАР

Ап-ак карлар ява, карлар ява,
Җир дә кышны сагынып көтә микән?
Сагынып көтәр кешең булса гына
Бу гомерләр матур үтә икән.

Ап-ак карлар ява, карлар ява,
Ә күңелемә минем ява моңнар.
Кардай сафлык өчен җан бирермен,
Син булмасаң, мине кем соң аңлар?

Ап-ак карлар ява, карлар ява,
Уйландыра кышкы зәңгәр кичләр.
Бер йомарлам карга әйләнерме? –
Син булмасаң, белмим, йөрәк нишләр?

Ап-ак карлар ява, карлар ява,
Карлар түгел, ап-ак энҗе коела.
Яннарында сөйгән кешең булса,
Салкын кыш та җылы, җылы тоела.

Тинчурин театры «Идегәй» дастанын сәхнәләштерергә җыена дигән хәбәрне миңа Тинчурин театрының әдәбият бүлеге мөдире Гөлназ Бәдретдин август аенда ирештергән иде. Аның белән «Тормыш стиле – мәдәни код. Халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать» фестивалендә очраштык.

Конференциядә мин Н.Исәнбәтнең халык эпосын өйрәнү өлкәсендә куйган хезмәте турында чыгыш ясадым, сүз уңае белән «Идегәй» дастанын өйрәнү тарихына тукталдым. Г.Бәдретдин «Җыен» фондында чыгарган китап белән танышкач, аның презентациясен Тинчурин театрында үткәрергә тәкъдим ясады. Китап «Татнефть» компаниясе ярдәме белән чыкты, Ф.Рафиков белән Р.Вәлиев риза булса, үткәрербез. – дигән идем. Сөйләшкәндә «Идегәй» спектакленә алынганчы, белгечләр белән очрашып, иҗат төркеменең Алтын Урда турында белемен арттырырга, дастан турында лекторий уздырырга киңәш бирдем. Әлеге дастан 90 нчы

Трагедиянең каһарманына тукталсаң, кем ул? Бу сорауга да спектакльдә ачык җавап бирелми. Сүз тарихи шәхес турында бармый, югыйсә спектакльдә дастан каһарманы турында сүз барырга тиеш!

Ни ул дастан? Күргәзмәне әзерләгәндә, бу сорауны күздә тотып, мин Н. Исәнбәтнең фәнни мәкаләсеннән бер өзек тәкъдим иткән идем. 1941 елда ясаган тәрҗемәдән файдаланып, бер өзекне русча биргән идем. Хәзер татарчасын кулланам.

– «Дастан бездә «эпос» дигән мәгънәне дә, «поэма» дигән мәгънәне дә үз эченә ала. Дастан каһармансыз булмый. Халык телендә без аларны «батыр» дип атыйбыз.

«Татарлыктан татар һич гарь итәрме»...

(Т.Имаметдиновның «Идегәй» фейк-дастанына бәяләмә)

елларда ук мәктәп программасына кертелгән иде, ләкин яшьләр бу әсәр турында бернәрсә дә белми.

Матбугатта спектакль турында хәбәрләр октябрь аенда гына тарала башлады. Мин борчылдым, чөнки «Идегәй» өч айда гына сәхнәләштерә торган әсәр түгел. Соңрак интернет челтәрендә Д.Исхаков, Г.Гыйльманов лекцияләренең өзекләре күренә башлады.

Декабрь башында Разил Вәлиев шалтыратты һәм мин театрның финанс мәсьәләләре һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча директор урынбасары Александр Далматов белән китапның презентациясен әзерли башладым. Рузилә Мөхәммәтова да бу шәп пиар булыр иде, дип безне канатландырып торды.

Премьераны шактый борчылу хисе белән көтеп алдым, чөнки «Таяну ноктасы»нда режиссер үзенең иҗади карашын ача алмады. Грантны алганда иҗат төркеме акчаны дастан куярга дип алды һәм спектакльне ислам динен кабул итү юбилеена багышлады. Кызганыч, премьерада мин сәхнәдә ни дастан каһарманнарын, ни ислам дине тематикасын күрүгә ирешмәдем. Спектакльдә Алтын Урдага бәйле сюжет кәттә фон буларак та тасвирланмый.

Алтын Урда – бөек дәүләт. «Идегәй» трагедиясе беренче чиратта режиссерга, инсценировка авторына аңлашылырлык итеп гади эчтәлеккә утыртылган. Т.Имаметдинов спектаклендә дөнья мәдәниятендә киң таралган, шул исәптән бездә дә бик борынгыдан килгән популяр мотив – атасының канын түккәннәре өчен баланың үч алуы мотивы әсәрне коручы төп эчтәлеккә әйләнгән. Финалда герой үлгәч, Алтын Урда да таркалды дип белдерәләр, ләкин катарсис кичерү өчен, спектакль эчендә бу урта гасырларда дан тоткан ил образын тудырырга кирәк иде. Нәтиҗәдә җиңел генә кабул итәргә яраклаштырылган, уртача тамаша килеп чыккан.

Зур батырларны зур вакыйгалар тудыра. Зур вакыйгаларда халык ягыннан торып көрәшкән, шул юлда гадәттән тыш эшләр күрсәткән кеше халык каршында батыр булып санала. Мондый батырлар азакта көтелмәгәнчә корбан булырга мөмкин. Менә шундый зур батырларның тууы, үсүе, гадәттән тыш батырлыклары һәм зур көрәшләрдә корбан булуы турында халык авызында төрле хәбәрләр, төрле җырлар, легендалар таралып, оста җырчылар яки әкиятчеләрдән берәрсе ул батырның тарихи вакыйгаларын өйрәнгәннән соң, җырлары һәм легендаларыннан катлаулы бер бөтен вакыйга оештырып, кирәк җирләренә үзеннән дә өстәп бер әсәр хәленә куйса, шул – дастан була», – дип Н.Исәнбәт фәнни мәкаләсендә безнең сорауга җавап бирә.

Сәхнәгә менгән спектакльдә, ни кызганыч, андый каһарманны күрмәдем. Автор инсценировкасы, эпик сюжетны җимереп, дастанның сюжетына зыян китергән. Каһарманны үстерү өчен эпик модельне сакларга кирәк иде. Тарихи чынбарлык ягыннан карасак, хата өстенә хата килеп чыккан... Инсценировка авторы нәрсә әйтергә тели? Т.Имаметдиновның бар максаты – деконструкция.

Беренче мизансценада без Идегәйне кулында кылыч тоткан хәлдә күрәбез. Каһарман күктән төшкән **бүрәнә-агач** белән көрәшә. Дастан эпик геройны халыкка хезмәт итә дип күрсәтсә, спектакльдә без аны сугышчы итеп күрәбез. Бу бүрәнә сценографиядә **агачны** яки **йортны** символаштырамы, аңлашылмый. Аяз Гыйләҗев үзенең «Йөгез, бер дога!» романында «Ибраһим» сүрәсен файдалана: *«Яхшы сүз таза агач кеби ул, тамыры нык, тирәнгә киткән, ә ботаклары күккә ашкан»*. Моннан чыгып, спектакльдәге каһарман кылычын **дин**гә – **галәм**гә каршы күтәргәнен ачабыз.

Татар фольклорына таянсаң, бу бүрәнә – йорт элементы булырга тиеш иде. Ә сценографиядә Алтын Урда – **йорт**-дәүләт итеп үстерелмәде, киресенчә, рәссам бөтен көчен хронотопны кабергә әйләндерүгә бирде. **Бура бүрәнәләре** татар кешесен тетрәндерә, чөнки төштә ул үлемне символлаштыра. Н.Исәнбәтнең XX гасырның беренче яртысында төзегән төшлеген ачсак, менә нинди мәгънәләргә тап булабыз:

Төшеңдә агач өйгә кергәнне күрсәң, үләсең ди.

Өй бурасы – кабер, кем дә булса үлә.

Өй салсаң, үлем була.

Татарның борынгы чорларда ук каберләр өстенә агачтан буралар куюы фәндә мәгълүм. Рәссам шулай итеп сәхнәдә **Алтын Урда каберлеген** төзиме?

Безнең милли эстетик идеалыбыз көчкә түгел, зирәклеккә, акыл сәләтенә, туган җиргә мәхәббәткә, халыкка хезмәткә нигезләнгән. Татар милли идеалларында гасырлар буе хәнҗәргә урын булмады. Татарстан Конституциясендә дә булмады ул моңа кадәр. Татарлар гасырлар дәвамында үз балаларына мирас итеп, үзе һәм дөнья турында белем биреп калдырырга омтылды. Алтын Урда образы спектакльдә тудырылмаган. Аның тарихы бик примитив бирелгән. **Идел-йорт** турында сүз күтәрелсә дә, бу образ ачылмаган, биредә ил төшенчәсе юк диярлек. Туфанның «Идегәй»ендә миңа рухи тирәнлек җитмәде.

Әлбәттә, «Идегәй» спектакленең уңай яклары дип, борынгы шигъриятнең татар сәхнәсеннән яңгыравын, тавыш бизәлешен, анда кулланылган төрки уен коралларын, хореографияне кабул итәргә җирлек бар.

Спектакльнең уңай ягы шунда: тавыш куелышының камиллегенә күрә, без ата-бабалар тудырган текстны тыңлап хозурлана алдык. Трагедия үзенең формасы белән аудиоспектакльне хәтерләтә. Борынгы шигъриятнең күптән татар сәхнәсенә менгәне юк иде... Спектакльнең композитор Ф.Бәхтияри тарафыннан эшләнгән музыкаль бизәлеше дә сокландырды. Борынгы заманнарда эпосның төрки уен кораллары белән бергә ничек яңгыравын тыңлый алу бәхетенә ирештек. Хореограф Марсель Нуриев эше аерым игътибарга лаек: ау кошларын сынау күренеше, Идегәйнең дошманнары белән көрәшен биюдә сурәтләү алымнары – искитмәле. Бу режиссер белән хореографның уртак иҗат эше булуы күренә. Хан хәнәшә Йәникә ирен котырткан мизансценада кыл кубызда ук белән уйнавы отышлы вә кызык. Ләкин спектакль өчен сайлап алынган текст фрагментлары, инсценировканың композициясе, Туфан Имаметдинов үзеннән керткән өлешләр, авторның Алтын Урда тарихын тирәнрәк аңлау өчен көч куймавы, төрки халыкларның эпос мирасы үзенчәлекләрен аңламавы турында сөйли. Режиссер «халык эпосын» куярга алынган, әмма нәтиҗәдә Идегәйнең гамәлләренә үз аңлатмасы килеп чыккан.

Ни кызганыч, милли мәгарифнең бетерелүе нәтиҗәсендә әкренләп үз тамырларыбызны оныту – бүген сәхнәдә менә шулай чагыла. Без «лачын» балаларының – Яңа төрки театр төзибез дип чыккан яшь иҗатчыларның канат җәеп очарга җыенуын күрергә теләдек, әмма аларның канат җәяргә көчләре җитмәде. Сәбәбе – рух җитмәү. Рух белем аркылы тәрбияләнә. 1944 елдагы карар Алтын Урданың рухи мирасын халыктан ярты гасырга бикләп куйды. Сүз иреге пәйда булгач, без бу белемнәрне яңадан кайтардык кебек, әмма ул бары тик галимнәргә генә килеп җиткән белем булды. Аны халыкта популярлаштыру турында оныттык. Без – матди яктан баедык, әмма рухи яктан бөлдек, зәгыйфьләндек. Татар халкының XX гасырда яшәү нәтиҗәсе – шушы. Ни кызганыч, Европа белемнәре белән агуланган без инде эпик сюжетны укырлык хәлдә түгел. Ә ул бит – Орхон-Енисей язмаларыннан башлап дастаннарга кадәр сакланган сюжет чылбыры.

Персонажлар системасын төзүнең үз кануннары бар. Мәсәлән, сәхнәдә күрсәтелгән Субра образы нәрсәгә кирәк? Ул – ханнан һәм Идегәйдән имтихан алучы образ. Тәхеткә кул сузган кеше ни дәрәҗәдә Алтын Урда тарихын, нәселенең тарихын белә, эчемлекне эчкәндә эпик геройның батыр булуы, туры сорауга җавап биргәндә – туры сүзле булуы ачыла. Бу эпизод – эпик геройны идеализацияләүнең төп моменты. Шуннан гына аксакал нәтиҗә ясап, Идегәйгә багышлап җыр җырлый. Дастан шулай итеп Идегәй образының каһарманлыгын ача, ни дәрәҗәдә ул Ил өчен җаваплылыкны үз кулына алганын күрсәтә. Эпик геройны тарихи кеше белән бутамагыз! Эпик геройның максаты – үч алу түгел. Ил турында кайгырту!.. Туфан Имаметдинов бер персонажны да режиссер буларак тулыканлы образ итеп үстерә һәм ача алмаган. Эпик герой Илне яклап чыгарга тиеш, ыруы сайлаган хатынга өйләнеп, ул үстерергә һәм «мин»леген җиңеп, туган иле һәм халкы турында кайгырып яшәргә тиеш. Бу кагыйдәләрне бозса, ул үлемгә дучар була. Эпик герой буларак Идегәй хаталана, шуның өчен финалда ул үлә.

Рус аудиториясен күздә тотып ясалган тәрҗемәдә дә хаталар бар. Нәтиҗәдә, татарга каршы контекст туган. Кызганыч... Текстның русча варианты совет чорындагы тарих укыту китапларында явыз татар образын сәхнәдә формалаштыра.

Спектакльнең эчтәлегенә игътибар итсәк, сәхнә өстендә булган текст ирексездән күзгә ташлана. Рәссам графика аркылы мәгънәне көчәйтә. Хәреф үлчәмнәре белән уйнап, дастан тәрҗемәсеннән алган өзекләр тамашачыда тискәре мәгънә тудыра.

Өйгә кайткач, текстларны янә карап чыктым. Шунда 1990 нчы елларда булган фаҗига миңа үз серләрен ачты. Н.Исәнбәт, автор хокукларын суд аркылы яклап чыкканда, үзенең «Казан утлары»на каршы гаризасында: *Я возражаю против того, чтобы журнал 1/ использует мое произведение без договора, на что он не имеет права (ст. 488 ГК РСФСР), 2/ нарушает право автора на неприкосновенность произведения (ст. 480 ГК РСФСР), насильственно навязывая а/ коллективное соавторство, б/ редактирование институтом, в/ комментарии и др.* дип язган иде.

1990 нчы елларда «Идегәй» дастанын бастырганда Н.Исәнбәтнең фәнни комментарийларын юк иткәннәр, шулай итеп текстка, аның тәрҗемәсенә каршылыклы, тискәре мәгънәләр кертелгән. Галим Алтын Урда концепциясе өчен журнал белән һәм китап нәшрияты белән судлашкан.

Үзегез чагыштырып карагыз!

С. Липкин беренче биттән үзенең тәрҗемәсендә дастанның җыелмасына керткән мәгънәләрне астыртын әйләндереп барган.

Борын үткән заманда
Болгар белән Сарайда,
Җаек белән Иделдә,
Алтын Урда, Ак Урда –
Данлы Кыпчак җирендә,
Татардан туган Нугай илендә
Туктамыш дигән хан булды;
Ил булганга – ил булды,
Яу булганга – яу булды,
Биләгәне кол булды,
Әйдәгәне мал булды.

В стародавние времена,
Там, где была нугаев страна,
А предком Нугая был Татар,
Там где стольный Сарай стоял,
Там, где вольный Идиль бежал,
Там, где город Булгар блистал,
Там, где текла Яика вода,
Там, где была Золотая Орда,
Ханствовал над страною татар
Хан по имени Токтамыш.
Кто был ему друг — того любил.
Кто был ему враг — того губил.
То, чем владел он, были стада.
То, что имел он, были рабы:
В муках текли их года.

Төгәл булмаган тәрҗемә аркасында явыз Туктамыш хан образы формалаша. Акцентлар үзгәрү аркасында, Болгар һәм Сарай образларын арткы планга күчереп, тәрҗемәче Нугай илен беренче планга чыгара. Бу адым текстның эчтәлегенә зыян китерә, ә спектакльдә рус тамашачысына тискәре мәгънәдәге мәгълүмат ирештерелә. Бу эш бүген кем файдасына эшләнә?

Ирексездән М.Госманов сүзләре искә төште:

«Нәкый Исәнбәтнең үзе белән алып киткән тагын бер зур үпкәсе бар. «Идегәй» дастанының текстын җыю, беренче мәртәбә бастырып чыгару. 1944 елгы мөдһиш карардан соң кыерсытылулар бер якта торсын. Үзгәртеп корулар башланып, дастан тексты яңадан басылган чакта, ишетүемә караганда, югарыдан: «Только без Исанбета!» – дигән, 1944 елгы карар кушканча әмер-фәрман төшә. Шуңа күрә 1988 елда яңадан чыккан басмада китапның контртитулында гел түрәләрдән җыелган формаль редколлегия исемлеге бар, нәширият редакторлары бар. Ә китапны төзүчеләре юк!..»



Хәзер генә аңладым, Н.Исәнбәт, тәрҗемәне тикшереп, мәгънә бозуга юл бирмәс иде, шуның өчен обком хәйләкәр юл белән (халык дастаны дип) бу эшне оештыра.

Бу астыртын татарофобия стратегиясе икенче мисалда фәнни комментарий аша оештырыла. Спектакль барышында экранга мондый сүзләр чыга:

Гай, татарин ты, гай, татарин ты!
От мангыта рожденный на свет
Нечистый, нагульный татарин ты!
Вчера твоя жизнь — быль.
Сегодня — пепел, пыль
Вчерашний бий сегодня умрет.

Әлбәттә, 26 гыйнвар көнне бу сүзләрне экраннан уку ил язмышына битараф булмаган кешеләрне тетрәндерде. Ә сәхнәдән бу сүзләр татарча яңгырады:

– Һай син татар, һай татар,
Мангыттан азган чал татар!
Син дә кичә бар булдың,
Син дә бүген юк булдың!
Син дә кичә би булдың,
Бүген килеп син дә бер
Үлем белән тиң булдың –
Токымыңны ораем!

Өйдә китаптагы комментарийларны карап чыктым. 1994 елда чыккан «Идегәй»дә шундый аңлатма китерелә: *«Туктамыш – монгол токымыннан, ә Котлыкыяны мангыт белән татар кушылмасы (чала татар) дип атый»*.

Н.Исәнбәтнең «Совет әдәбияты»нда басылган вариантта, галимнең комментариен ачкач, бары да үз урынына утырды.

«Котлыкыя би – тарихчыларның күпчелеге күрсәтүенчә, ак мангыт ыруыннан булган. Мангыт кабиләсенең бер тармагы Нугай мирза исемендәге башлыклары соңында – нугай дип аталып киткән. Кырымдагы һәм Әстерхан тирәсендә бу татарларда әле дә нугай исеме саклана. Туктамыш хан үзе монгол – чыңгыз нәселеннән булганлыктан, Идегәйнең атасы Котлыкыя бине татар дип хурлавы аңлашыла. Ләкин, ярлыкларында күренүенчә, Туктамыш үзе дә монголлыктан чыккан, татарлашкан кеше». (43 б.)

Әлбәттә, бу комментарий спектакльдә яңгырамады. Тәрҗемәче, Туфан тарафыннан ничек бирелгән, тамашачы шулай тыңлап утырды. Нәтиҗәдә, татарофобия контексты спектакльдә үстерелә башлады. Татарстан бу әсәрне сәхнәләштерүгә **3 млн сум акча** бүлеп биргән. Урысча караган тамашачының аңына совет чоры тарих китапларында булган хакыйкать урынына шулай итеп тискәре мәгънәләр сеңдерелде!

Төп образларга да режиссер деконструкция ясаган. Беренчедән, Туктамыш хан сәхнәдә Болгарны җимерүче итеп күрсәтелә. Норадын һәм Идегәй сюжет сызыгына спектакльдә урын табылмаган. Идегәйнең үз малаен тәрбияләүгә игътибар бирмәве аркасында, фаҗигага дучар булуы ачылмаган. Хатын-кыз сүзе белән Норадын этисенә кул күтәрә. Идегәйнең сукырлыгы дастанда символик мәгънәгә ия була. Куып җибәрүе бөтенләй юк, бу сюжет бит Идегәйнең илен сатып бәхет тапмавын күрсәтә. Ул үзе күтәргән ханнар барысы да аңа каршы чыккан.

Шаһ Тимер образына да режиссер тарафыннан үзгәртүләр кертелгән. Тинчурин сәхнәсендә, «Хуҗа Насретдин» комедиясен сәхнәләштереп, «Кара Пулат» операсын куеп, без аның явызлыгын тамашачыга ачып чыккан идек, ә бүген «Идегәй»дә без аны матур бабай итеп күрсәттек. Шаһ Тимер Идегәйгә булышу өчен генә килгән икән. Илне җимермәгән икән...

Сценарийда Бодыйби белән Идегәй диалогына игътибар итегез! Иң мөһим сүзләр сценарист тарафыннан юк ителгән: *«Бу җиһанның фетнәсе / Аксак Тимер дошманны / Сарайга алып китердең»*.

Т.Имаметдинов ата белән ул диалогын җимереп, Норадынның сүзен Идегәйгә тапшырып әйттерә, шуның өчен дастанның мәгънәсе һәм образның эчтәлеге нык үзгәртү кичерә. Чагыштырыйк:

Идегәй:
Кто я? Облако в небесах!
И пока я дождем не прольюсь,
В небесах я не растворюсь!
Я от матери черным рожден:
Будет мылом мыть меня мать,
– Не сумею белым я стать.
Т.Имаметдинов варианты

Тора килеп Норадын,
Идегәйгә янә әйтте:
– Кисәкчә чыккан болытмын,
Яумаенча таркалмам,
Анадан кара туганмын,
Сабынлап юсаң агармам!
(дастан варианты)

Финалда трагедия текстында, дастанда булмаган өлешләр кертелә һәм Идегәй образына зыян китерелә:

Идегәй. *Смертью меня не страши —*
За мой нет народа, который умрет.
Т. Имаметдинов варианты

Идегәй. *Үлем белән куркытма,*
Курка торган уем юк!
Идегәй, 1994, 242 б.

Кем тегерменә су коя соң бу үзгәртүләр? Ни өчен Т. Имаметдинов Идегәйне Печорин трафаретына утыртып куя?

Рәссам (А.Гайнуллина) костюмнар өстендә эшләмәгән. Шуның өчен күренешләр спектакльдә тискәре мәгънә тудыра. И.Гарифуллинның герое кыяфәте белән каһарманга охшамаган. Костюмы бу мәгънәгә хезмәт итми. А.Пискунов (Кадыйберди) белән мизансценада бу ачык күренә. Тамашачы алдында Идегәй бер мескен, ябык, бөкре, төшенкелеккә бирелгән, кечкенә буйлы малай булып күренә. Бу күренеш ирексездән дастандагы Идегәйнең әйткән сүзләрен искә төшерә: «Арыслан хәлдән тайса да, / Бер сарыклык көче бар!». Ут куючы рәссам (И.Шакиров) да дастандагы мәгънәләргә игътибарлы булмаган.

Артистларның уйнау дәрәҗәләре эчне пошырды. Бу да режиссерның корган сюжеты өчен сайлап алган текстларны аңлап җиткермәвеннән килә. Интонацияләр дөрес куелмаган, мәгънәви паузалар бөтенләй юк. Ирек Хафизовка рәхмәт, ул Туктамыш хан образын тудыруга зур тырышлык куя.

Әлбәттә, татарда яшь режиссерлар юк дәрәҗәсендә. Бу чынбарлык. Мәдәният министры И.Әюпова тел нечкәлекләрен, сүзнең эчке энергиясен аңламаган Т.Имаметдиновны Тинчурин театрының баш режиссеры итеп куйды. «Бизнес-онлайн» газетасына биргән бер интервьюда Камал театрының яңа бинасында бу режиссер тәрбияләгән иҗат көчләре хуҗа булачагын фаразлады. Әмма сүз кечкенә экспериментал сәхнә турында бармый (мәсәлән, «Моң» театры), монда татарның академик театры язмышы хәл ителә... Мине бу хәбәр вакытында тетрәндерде... «Үзгереш җил»е татар моңын җимерсә, Т.Имаметдиновның иҗат төркеме Тукай теленең учагы булган татар театрын җимерә...

2019 елда бу иҗат төркеме үзенең иҗади программасын игълан иткән иде: ««Как Дэрдменд 100 лет назад»: в Казани **«пустили кровь»** застоявшейся **татарской культуре»** (business-gazeta.ru)». Т.Имаметдинов бу иҗатчылар төркеменең татар мәдәниятен яңа караш нигезендә үзгәртәчәген игълан итте. Шул исәптән, бу төркем татар мәдәни кодларын җимерү процессын башлады. «Шәмаил», «16+», «Дәрдемәнд» спектакльләре турында инде язып чыктым. Бүген Тинчурин театры репертуарында булган Т.Имаметдинов спектакльләренә дә күз салыйк.

Татар халкы аңында шагыйрь М.Әгъләмов «Галәм-Әгъләм» дип мәңгелештерелсә, бүген без аның образын сәхнәдә таш арасына яшерергә батырчылык иттек. Граждан-шагыйрь урынына, өч хатын-кыз белән буталып, юкка чыккан ир образына алмаштырдык. Таш та метеорит формасында түгел, ә «Черный ирис» исемле Джорджия О'Киф рәсемен (1926) хәтерләтә. Белгечләр **кара ирис** чәчәгенең мәгънәсен хатын-кыз сизгерлеге һәм сексуальлеген символаштыра дип аңлата. «Ал яулык, зәңгәр шәл» өч пәрдәле операның эчке мәгънәсен мин инде театрда чыгыш ясап аңлаткан идем (Уңаймы «Умай», әллә... // Мәдәни җомга. – 2022. – №28. – 22 июль). Бу иҗади төркемнең иҗади программасын укысаң, алар бүген сәхнәдә, татар тамашачысының аңын матур музыка белән агулап, «Идегәй» спектаклендә татар мәдәнияте өчен каберлек төзи түгелме?!!!

Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА.

Мәдәни җомга
3 февраль
№4, 2023

Нур ӘХМӘДИЕВ

Сагындык малае ТАҖИ

«Атларым, колыннарым» повестеннан

Әллә аякларым тарткан, әллә очраклы рәвештә койманың рәшәткәләре купкан җиренә барып чыкканмын. Анда җиту белән туктап калмадым, ярык аша урман эченә атылдым һәм бер кечерәк аланда туктап, ямь-яшел үләненә аудым. Менә шунда буам ерылды, үкси-үкси күңелемне бушаттым. Бу минутта миннән дә бәхетсез, мөгаен, кем дә юктыр. Әнием ташлап киткән, әти шулай ук еракта, яраткан әбием җир астында. Ярты ятимлегемне онытгыручы бабам бар иде, ул да бүген янымда түгел. Лагерьда исә килеп җитмәс борын мыскыл итәргә торалар. Кайсысына зыяным тигән? Минем кай җирем аларныкыннан ким? Әллә кайтып китәргәме соң дигән уй инде ничәнче тапкыр күңелемә килде. Үзләренә булсын лагерьлары. Моңарчы ансыз тордым, моннан соң да үлмәмен.

Кошлар сайрый, чикерткәләр бер-берсе белән узышып сикерәнә. Кигәвеннәр безелди, селкенмичәрәк торсаң, ашап бетерергә торалар. Лагерьларына кире кайтасым да, чәйләрен эчәсем дә килми. Капланып яттым да уйга калдым. Ята торгач, йокымсырап киткәнмен, ахры, күземне ачып җибәргәндә, баш очымда кулына өч бөртек зәңгәр чәчәк тоткан кызны күреп, күзләремне уып алдым: төш күрәмме, саташаммы? Кайда мин, ни эшләп ятам бу чирәмдә?

– Син кем?

Кинәт соравымнан кыз дерт итеп сискәнеп китте. Ләкин аның куркуы секундның уннан бер өлеше кадәр генә дәвам итте. Ул елмаеп:

– Наилә, – дип җавап кайтарды. – Без сине бөтен лагерь белән эзләдек. Гөлзифа белән икебез таптык. Ул Роза апага әйтергә дип йөгерде, ә мин сине сакларга калдым...

И, ачуым килмәгәе, сакларга дип сөйләнгән була бит әле. Чәнчә бармак белән төртсәм аварга тора. Тукта, лагерь диде түгелме соң? Кинәт барысы да исемә төште: сулы табак та, малайларның тешләрен ыржайтып көлүләре дә, табактан чыгалмый ятучы Эдик та...

– Лагерьда калмыйм, китәм мин! – дип сикереп тордым.

Белмим, ни эшләр идем, шулвакыт йөгерешеп аланга бер төркем малайлар, кызлар белән пионервожатый апа килеп чыкты. Аның кулына тотынып йөгергән кыз:

– Әнә алар, әнә! Наилә белән без таптык аны, – дип аваз салды. Мактанчык! Зур эш кырган диярсең. Югалырга әнә түгел лә!

Вожатый апа янына килде. Аның ачулануын, шелтәләвен көткән идем, ә ул берни булмагандай:

– Кайтабызмы, Тажи акыллым? – дип кенә сорады, һәм кулын миңа сузды. Юк инде, кулга тотынып йөрергә кызлармыни мин!

Башымны аска төбәп, сүзсез генә аларга ияредем. Кызлар, малайлар чыр-чу килә, бер-берсен куышалар, әле тегe, әле бу үләнне табып, вожатый апага китереп күрсәтәләр. Бигрәк инде, кайберсе тилебәрәнне дә танымый икән.

– Роза Фатыйховна, бу нинди чәчәк?

– Роза Фатыйховна, мин мәтрүшкә таптым, иснәгез әле!

– Апа, мин елан күрдем.

– Елан ди сиңа, корыган ботак иде ул! Куркак!

– Син үзең куркак!

Роза Фатыйховна дүрт яктан сырып алган балаларның сорауларына җавап биреп өлгерә алмый. Кайбер сорауларга җавапны мин дә бирә алыр идем дә, дәшмим. Теләсә кайчан такылдарга яратмыйм. Безнең класстагы бар кешене туйдырып бетергән Шәпи Кәбире түгел ич мин!

Тик кенә барганда Наилә килеп кысылмасынмы!

– Роза Фатыйховна, Тажи лагерьдан кайтып китәм диде.

Роза апа миңа карамады да:

– Нишләп алай дисең, Наилә? Тажи зур инде, акылсыз малай түгел, шаяртгандыр гына, – дип мине яклады.

Ничектер уңайсыз булып китте.

Лагерьга җитәргә күп калмаган, быргы, барабан тавышлары ишетелә башлаган иде. Әллә күренә генәме дип торам, күзәмә утлап йөргән ат чалынды. Бөтен җире кара, бары тик сыртының ыңгырчак атландыра торган өлеше генә ак. Башында йөгәне дә бар. Тик атлаганда аксый сыман. Мөгаен, тезгене уралгандыр, бушатырга кирәк, җәфаланмасын малкай.

Янына бара гына башлаган идем, Роза апа:

– Тажи, якын килмә, тибәр! – дип кычкырды.

И Роза апа, күрәләтә аттан типтереп торырга мине юләр дип белдеңме?! Бу хәлдә калдырып китәргә ярамый, җан иясе бит ул. Мине ат күрмәгән шәһәр малае дип уйлый инде.

– Хәзер, апа, хәзер!

Малайлар, кызлар, кызыксынып, һәр хәрәкәтемне иләк аша үткәрәләр. Кулымны суза төшеп, атка якынлаштым. Әйткән идем аны тезгене аягына уралгандыр дип, хак икән. Башта исе китмәгән кебек күренсә дә, йөгәненнән эләктердем дигәндә генә, Кара алаша читкә сикерде.

– Бах, бах, бах!

Тавышыма алданыпмы, әллә икмәк бар дип уйладымы, ат башы белән кулыма табан сузылды. Миңа шул гына кирәк иде дә, күз ачып йомганчы ыргым ясап, тезгененнән эләктереп өлгердем. Кызлар «аһ!» итте. Яңагыннан, муеныннан сыйпаштыра торгач, алаша тынычланды, күзләрен челт-челт йомып тора башлады. Иркәләгәнне кем дә ярата шул. Хәзер инде һич шикләнмичә уралган тезгенне чишәргә мөмкин.

Роза Фатыйховна да, аны урап алган балалар да минем ат белән булышканны тын да алмыйча карап тордылар. Аю биетәләр диярсең.

Чишеп, тезгенне кулыма тоткан идем, Роза апа:

– Егет икәнсең, Тажи, булдырдың, – дип мактап куйды.

Их, Роза апа, никләр генә «егет икәнсең!» диден икән. Кара алашаның да назланып кешнәве, иркәләнеп иреннәре белән кулга төрткәләве, дистәләгән күзләрнең сокланып та, көнләшеп тә миңа текәлүе дөньямны онытгырды куйды. Кайсы шайтан котырткандыр, ялына ябыштым да мәче җитезлеге белән атның сыртына менеп кунакладым. Атка атлангач, ни эшләргә икәнен миңа өйрәтеп торасы юк, Роза апа дәшәргә өлгергәнче, чабып та киттем. Колак төбемдә җилләр генә сызгыра. Хәзер мин тагын авылым кочагындагы иркәле Тажига әверелдем. Әллә шушы атка атланудан файдаланып, Сагындыкка ук ычкыныйм микән? Кара алаша кирегә юлны тапмый калмас. Юк, ярамый, әнә ич Роза апа: «Тажи акылсыз малай түгел», – диде. Ул ни уйлар?

Кара алаша Йолдыз түгел-түгелен, алай да начар чаба димәс идем. Бигрәк тә юыртуы йомшак, хәтта ат сыртында баруыңны онытып җибәрәсең. Менә Үшәнгә атланып юыртып кара син! Башта урыныннан кузгата алмый җан ачуларың чыга, соңыннан, көч-хәл белән юырттыра башласаң, эчләрең төшеп бетә. Чытыр арбада катканактан чапкан сыман. Кара алашаны мин куаламыйм да, дәрткә бирелеп үзе чаба, күптәннән атлыгып, форсатны көтеп кенә торган диярсең. Күптән түгел генә күңелемдә уянган рәнҗү хисе юкка чыкты. Без хәзер дөньяда Кара алаша, кояш, җил, битне сыйпап-сыйпап калган агач яфраклары һәм сөлектәй гәүдәле шушы атка менгән Тажи гына калдык. Оч әйдә, оч, канатлы аткаем!

Үз иркенә куелган Кара алаша бераздан мине лагерьга алып кайтты һәм ашханә янындагы сарай кырыена килеп туктады. Арбага такталар кадаклап йөргән илле яшьләрдәге абзый, тирләгән битен җиңе белән сөртә-сөртә янибызга килде. Егетләрски сикереп төшеп, тезгенне абзыйга суздым.

– Сезнең атмы?

– Минеке. Иртәдән бирле эзләп, таба алмый кайткан идем. Шәһит абзаң булырмын мин. Лагерьда завхуз. Рәхмәт төшкән бала, кайлардан очратасы иттең?

– Ул атының сыртыннан сыйпап куйды. – Чит кешене бик якын җибәрми торган иде, ничекләр тоттырды ул сиңа?

– Мондый гына атларны күргән бар инде! – Эре чирттердем әле, төшеп калган малай түгел икәнлегемне белсен. – Минем бабай атлар карый, – дип өстәдем аннан бик тәкәббер күренмәс өчен. – Нәселлеләре дә бар.

Абзый кеше соравы белән аптыраштa калдырды:

– Алай-болай Сагындыктан түгелдер бит?

– Каян белдең? – Гаҗәпләнүемнән кычкырып җибәргәнмен.

Шаулашкан тавышлар ишетелде. Роза Фатыйховналар кайтып җиткән. Ул беркайда да туктап тормыйча, туп-туры яныма килде. Йөгергән уңайга:

– Егылмадыңмы? – дип сорады, үзе җавабымны да көтмичә, мине кочагына кысты. Сулышын еш-еш ала иде. Тәненең җылысы тәнемә таралды. Әбием үлгәннән бирле болай кочаклаучы юк иде. Әниле малайларны гел кочаклап торалардыр әле.

Роза апаның күз яшьләрен күргәч, горурлык тойгыларым кечерәеп, мескенәеп калды. Барысы да миңа текәлгән һәм шелтәлиләр кебек. Ни гаебем бар соң минем, әйтегез, дип кычкырасым килде. Шәһит абзый:

– Алай икән... – дип тамагын кырды.

Уңайсыз тынлык урнашты. Шулчак Роза апа мине үзеннән читкә этәреп:

– Юньсез, тыңлаусыз малай икәнсең, – дип шелтәләде. – Өстәвенә мактанчык та икәнсең. Егылсаң...



(Дәвамы киләсе санда).

Тау ягының бер сере

Кайбыч районы Иске Кырбаш (Түбән Кырбаш) – авылы XIV гасырның ахырында, XV гасыр башында ук күрше Хуҗа Хәсән һәм Мәлки авыллары белән бер үк чорда оешкан. Оештыручысы Хәсән белән Мәликнең бертуган энесе Кырганбаш (Корбанбаш) исемле егет булган, дигән риваять бүгенгә кадәр саклана.

В.Данилов Тау ягы керәшен яшьләре белән үзе ачкан музей янында.

Иске кырбашлыларның ата-бабалары хәзерге Чүпрәле районындагы Зур Чыңлы, Олы Задур һәм башка авылларыннан качып килгән. Бу хәл 1392 елларда Аксак Тимер Бөек Болгар дәүләтен җимерергә дип һөҗүм ясаган көннәрдә була. Аның һөҗүм юлындагы авылларны җимереп, яндырып, кешеләрен үтереп йөргән чагы. Шәһри Болгарны да юк иткән чор. Шушы явыздан качып килүчеләр Хуҗа Хәсән белән Мәлки авылларын үтеп, Ырым елгасын кичеп, Печмән (кискән урман җире, дигәнне аңлата) тавы астында, Гөбенә белән Ырым елгалары арасында бик матур табигатьле урында, Мәлки авылына елга аркылы капма-каршы итеп Иске Кырбаш авылы оештыра. Бу авылны Түбән Кырбаш дип тә әйтүчеләр бар. Урыслар аны Старый Курбаш – Нижний Курбаши дип тә язган.

Тарихта, архив документлары арасында урыс телендә Гөбенә елгасының аръягында, тау кашында урнашкан күрше Иске Буа авылын да Иске Кырбаш дип язылган фактлар җитәрлек. Сәбәбе нәрсәдә соң? Бәлки, Кырганбаш җитәкчелегендә качып килгән бер төркем кешеләр ике елганың (Гөбенә белән Ырым) сулары ташып, авылны басуыннан куркып, аннан ераграк китеп, Гөбенә елгасының аръягына чыгып, тау кашына урнашып, авылның исемен Кырбаш дип атагандыр?

Соңрак 1630-1650 елларда шушы авылга хәзерге Яшел Үзән районы, Норлат зонасыннан, Бува елгасы буеннан тагын икенче бер төркем кешеләр килеп, авылның икенче исемен Буа дип атаулары бик мөмкин. Күрше Әрә-Байморза авылы кешеләренең әби-бабалары да шул ук Норлат ягыннан, Әрә елгасы буеннан килүе тарихта билгеле бит.

Мәлки авылы белән Иске Кырбаш–Түбән Кырбаш авылы да район үзәге Олы Кайбычның көньяк-көнбатыш юнәлешендә 31 км ераклыкта оешкан. Россия дәүләте Борынгы Актлары Архивы (РГАДА) нигезендә 1722 елдагы беренче ревизия күрсәткәнчә Иске Кырбаш авылында 64 җан ир яшәгән (Ф. 350. оп. 2 КН. 2081. Л. 41 об-42 об.)

Ә 1748 елдагы икенче җанисәбе, шулай ук 1762 елдагы өченче җанисәбе нәтиҗәләре РГАДАның 350 фондында, 2 описендә, 2988 һәм 3005 делоларында саклана. 1781 елда Иске Кырбаш-Түбән Кырбаш авылында 48 җан ир яшәгән. Аларны чукындырылган чуашлар дип язганнар. Алда күрсәтелгән авыр елларда авыллларда кешеләр саны үрчемәгән, киресенчә, һаман кимегән генә. 1788 елда барлыгы 94 кеше, 1795 елда 90 кеше, 1834 елда 96 кеше яшәгән. 1840-1849 елларда гына кешеләр саны әкренләп арта башлаган. 1850 елда 194 кешегә җиткән, аларның 92 се ир, 102 се хатын-кыз булган.

Барысы да дәүләт крестьяннары исәбенә кергән. Шөгыльләре – җир эшкәртү, бөртекле культуралар һәм яшелчә үстерү. Шулай ук мал-туар тотканнар. 1926 елда авыл халкы 754 кешегә җиткән. Барысы да чукындырылган татарлар була. Иске Кырбаш-Түбән Кырбаш авылы 1703 елдан соң Хуҗа Хәсән волосте, Зөя (Свияжск) өязе, ә 1750-1800 елларда Хуҗа Хәсән волосте Чуел (Цивиль) өязе составында була. 1816 елның февраль аеннан Тобурдан волосте, 1850 елның 4 октябреннән Төмәр волосте, 1861 елдан Иске Тәрбит волосте Чуел өязе составына күчә. Беренче Бөтендөнья сугышы чорыннан башлап 1920 елга кадәр Иске Кырбаш авылы яңадан Төмәр волосте составына керә. Татарстан Республикасы оешканнан соң (1920 ел), Иске Кырбаш-Түбән Кырбаш күрше керәшен авыллары белән бергә, Төмәр волостеннан аерылып, Зөя (Свияжск) составына, ә 1925 елның 25 сентябреннән Татарстанның Мәлки волосте составына керә. 1927 елның 14 февраленнән – Ульянково районы, 1927 елның беренче августыннан – Кайбыч районы, 1944 елның 19 февраленнән Подберезье, 1956 елның 17 маеннан яңадан Кайбыч районы, 1962 елның беренче февраленнән – Буа районы, 1964 елның 4 мартыннан – Апас районы, ә 1991 елның 19 апреленнән кабат Кайбыч районы составында яши бирә.

1927 елда Мәлки авыл советы белән берләттән Иске Кырбаш авыл советы да оеша. Әмма бу ике авылның бердәм тоташ булуын исәпкә алып (аларны Ырым елга суы гына аерып тора) 1929 елда бу ике авыл советын берләштереп, Мәлки авыл советы гына дип атый башлыйлар. Иске Кырбашта–Түбән Кырбашта 1928 елда И.Сталин исемендәге колхоз оештыралар. 1959 елда Сталин исемендәге колхозны, Мәлки авылындагы Молотов исемендәге колхоз белән берләштереп, аларның исемнәрен алыштырып, «Восход» колхозы итеп атыйлар. Соңыннан шушы колхозга «Знамя» исемендәге колхозны (Байморза, Иске Буа, Яңа Буа авыллары) һәм «Разин» исемендәге колхозны (Иске Тәрбит, Соравыл (Янсуринское), Камыллы авыллары) һәм «Безнең юл» исемендәге колхозны да (Олы Тәрбит, Чүти авыллары) кушып, берләштереп оешкан яңа, зур колхозны «Гигант» колхозы дип атыйлар. 1965 елда Апас районы чорында, шушы «Гигант» исемендәге колхоздан Чүти авылы белән Олы Тәрбит авыллары, киресенчә, аерылып чыгып, «Йолдыз» исемендәге колхоз оештыралар. Менә шул ук вакытта «Гигант» исемендәге колхозны яңадан «Восход» колхозы итеп алыштыралар. Чөнки Апас районында шушы ук вакытта «Гигант» исемендәге ике колхоз була.

Иске Кырбашта-Түбән Кырбашта элек-электән үк он ясар өчен су тегермәне, ярма яра торган тегермән һәм шулай ук җил тегермәннәре эшләп торган, йон да теткәннәр. Авылда чиркәү-мәхәллә мәктәбе дә эшләгән. Үткән гасырның 30 нчы елларында Иске Кырбаш авылы һаман да үсә килгән, аның көньяк өлеше Гөбенә елгасы ярларына җитеп тоташа.

Үзләренең колхозы яхшы нәтиҗәле эшләп, халыкка файда китергән. Яшелчә һәм бөртекле культураларның да уңышлары ул заман өчен югары булган. Колхозда 2 ындыр табагы эшләп килгән. Анда уңышны атлар белән суктырганнар. Язгы чәчү чорында, печән өстендә һәм урыпҗыю вакытларында басуларда ашханәләр эшләп торган. Гөбенә һәм Ырым елгалары буенда яшелчә бакчалары булган. Кара Тамакта буа буып, яшелчәләргә су да сиптергәннәр. Гомумән, ул заманда ук сугару эшләрен дә гамәлгә кертергә тырышканнар. Сталин исемендәге колхозда сарык фермасы да булган. Колхозда шулай ук атлар да үрчеткәннәр, бал кортлары да булган.

Иске Кырбаш-Түбән Кырбашта элек-электән үк (1929 ел) изба-читальня, клуб, медпункт, авыл кибете эшләп килгән. Бу авылда атказанган, күренекле кешеләр дә күп. Мәсәлән, филология фәннәре докторы, профессор Илья Коновалов, күренекле журналист, Бөек Ватан сугышы ветераны Александр Малов, заманында (1962 елга кадәр) Северный Нурлат районында, район башкарма комитеты рәисе Павел Петряков, илебезгә даны таралган «Радиоприбор» заводы директоры Иван Шпаков, Татарстан Президенты Аппаратында идарә башлыгы Александр Волков, гомере буе бертуктаусыз колхоз рәисе булып эшләгән «Хезмәт Кызыл Байрагы» һәм Ленин орденнары белән бүләкләнгән Иван Аржанухин, Татарстанның халык артисты Лена Бичарина һ.б.

Иске Кырбаш-Түбән Кырбаш һәм Мәлки авылларында элеккеге мөселман зиратлары да бүгенге көнгә кадәр саклана. Тик Иске Кырбаш авылы турында күпләр белми дә, аның исеме өлкән буын кешеләренең паспортларында гына очрый.

В.В.ДАНИЛОВ,
төбәк тарихын өйрәнүче.

Сагынып искә алдык

С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры коллективы Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, М.Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе лауреаты Роберт Шәйхел улы Шәймәрдановны искә алу кичәсен уздырды. 60 яшьлек юбилее уңаеннан гыйнварда матур бенефис үтәсе иде, кызганычка каршы, тормыш бу планнарга катгый үзгәреш кертте.

Әйтерсең, Роберт Шәйхел улы һаман үзебезнең арада – театр фойесындагы фотокүргәзмәдән, кичә барышында экраннан мыек астыннан елмаеп карап тора. Шулай булмыйча мөмкин түгел, нинди зур эшләр башкарып китте ул фани дөньяда! 15 ел хәрабә хәлендә яткан театр бинасын төзекләндереп, 1999 елда Татарстанның беренче Президенты М.Ш.Шәймиевнең үзе катнашында тантаналы төстә аны ачу; Минзәлә театрына аңа нигез салучысы Сабир Өметбаев исемен бирдерү, театр каршындагы скверга аның бюстын куйдыру, Өметбаев исемендәге премия булдыру, Минзәлә шәһәренең яңа урамнарына артистларның исемнәрен бирдерү һәм башка бик күп изге гамәлләр – болар барысы да кичә дәвамында телдән төшмәде.

Театр директоры Илнур Гайниев: «Үләренә бер атна кала Роберт абый театрга килде. 23 гыйнвардагы юбилеен беләбез, көтәбез. Роберт абый бик тыйнак иде. «Юк, кирәкми, мин бит инде театрда эшләмим, юбилейны җыйнаграк кына уздырыйк», – диде. Мин әйтәм, юк, 28 ел гомер тикмәгә үткән вакыт түгел, күпме хезмәт, күпме көч куелган! Театрда күрешеп, рәхәтләнеп соңгы сөйләшү шушы булды... Роберт абый эшләгән эшләргә сокланып, аның татар театр сәнгате тарихына керткән зур өлешен тагын бер тапкыр тамашачыларның исенә төшерәсе килгән теләктә без...»

Роберт Шәйхел улын искә алу кичәсе Минзәләдә, икенче көнне аның туган ягы Мөслимдә булды. Бу чараларга Г.Камал исемендәге академия театры, Түбән Кама театры, Яр Чаллы театры директорлары һәм артистлары, Минзәлә, Мөслим районы хакимияте вәкилләре, балалары, туганнары, күпсанлы тамашачылар җыелды. Мөслимгә барышлый, туган авылы Татар Шуранында коллектив белән каберенә чардуган, чәчәкләр куелды.

Нурсибә АДИЕВА,
театрның әдәби бүлеге мөдире

● Бүгенге Люция ханым Җәлилова.

● Зәкия Садыйкова белән кызы Люция. 1940 еллар ахыры.

● Җәлил гашыйк булган Зәкия Садыйкова.

ҖӘЛИЛ КЫЗЫ ЛЮЦИЯ

Безнең буынны ничәмә-ничә еллар буе хакыйкатьтән яшереп яшәттеләр. 1970 елларда университетта укыган чагында да лекцияләрдә Җәлил шигырьләрен генә түгел, хәтта аның Беренче Май мәйданына куелган һәйкәленә тикле төрлечә тикшерәләр, әмма гаилә хәле турында сүз чыкса, Әминә һәм Чулпан исемнәре белән генә авызны томалыйлар иде. Тора-бара, яши-яши генә ишеткәли башладык, Җәлил яшьлегендә бер-бер артлы өч кызга гашыйк булырга, мәхәббәт газаплары кичерергә дә өлгергән икән әле...

● В.Имамов Люция ханымның иңнәренә ак шәл салган мизгел.

Без өч-дүрт дистә ел буена фәкать Әминә ханым һәм аның кызы Чулпан турында гына ишетеп яшәдек. Яшьрәк вакытта рәсемнәрен китап һәм альбом битләрендә күрә идек, еллар үткәч, үзләрен күреп тә сокландык. Әминә ханымның чынлыкта Сәйфуллина Нина Константиновна булуын да соңрак кына белдек. Ә бермәлне, Ижау каласының 12 нче мәктәбендәге Җәлил музеена баргач, анда эленгән фотолардан Мусаның Альберт исемле улы барлыгын, аның әнисе Рауза Хисаметдинованың 1930 еллар башында безнең шагыйребез белән мәхәббәтләре булуын да белдек. 1950 еллар тирәсендә Рауза ханым белән Альберт Ижау каласында да яшәп алган һәм музейның барлыкка килү сәбәбе дә менә шул икән.

Еллар үткәч, большевиклар партиясе корып куйган кара пәрдәнең тагын бер як чите ачылды. Утызынчы еллар уртасында Муса Җәлил белән Зәкия Садыйкова атлы яшь шагыйрә дә бер-берсенә чиксез гашыйк булган, мәхәббәт җимешләре булып җиһанга Люция атлы чибәр бала туган. Язмышларын берникадәр ачыклый башлаганда, Люция ханым Петербург каласына күчеп киткән иде инде. Һич яшереп тормыйм, аны күрәсем килүне белдереп, Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчеләренә әллә ничә ел элек үк мөрәҗәгать иттем, үтенечемне санга сукмадылар. Менә 2023 елның гыйнвар уртасында Петербург каласына сәяхәт ясау бәхете эләкте һәм, ниһаять, мин бер күрергә тилмергән Люция ханым каршымда утыра. Ул 1936 елның май аенда дөньяга килсә дә, хәтере яшь кызларныкыдай таза һәм сау, үзе дә бөтерчек кебек бөтерелә әле. Ул буйга бик кечкенә, аңа карагач, татар халкының «орчык кадәр буйлы», «кечкенә дә төш кенә» дигән гыйбарәләре тел очына килә. Ул барча тарихны да яшермичә сөйли.

– Минем әнием берничә тәүге шигырен туплаган да, аларны почта аша «Октябрь баласы» журналына салган, – дип хәтер сандыгына чума Люция ханым. – Берзаман җавап килгән. «Шигырьләрегез төзек, ләкин аларны күбрәк итеп туплап бирергә иде. Аннары шигырьләр янына куярга фотогыз да кирәк», – дигәннәр. Әни тагын яңа шигырьләр һәм рәсемен юллаган. Ә беркөнне, инде эш тәмамланып килгән чакта, моның каршына ап-ак күлмәк кигән Муса килеп баскан. Әнинең типографиядәге басу машинасын чистартып яткан чагы икән, терсәкләренә кадәр буяуга баткан. Муса әнигә карап торган-торган да «син бик кечкенә икән», дип әйтеп салган. Әни дә ялындырып тормаган: «Үзең дә әллә кем түгел», – дип турыдан ярган. Менә шуннан соң очраша башлаганнар. 1935 елның көзендә әни үзенең көмәнгә калуын аңлаган. Әмма үч иткәндәй, 1936 ел башында Мусаны Мәскәүгә чакыртып алганнар, алар анда беренче татар операсын тудырырга тырышып йөргән бугай. Ә әнине Галия Кайбицкая кебек Муса белән мөнәсәбәтен яхшы белгән артистлар: «Корсагың борыныңа җитеп килә бит инде, Мусаң янына Мәскәүгә сыптыр», – дип үгетли дә башлаган. Әни Мәскәүгә барган баруын, ләкин Әминә турында да ишетеп өлгергән, ахры. Әмма Муса әнине гаҗәпләндереп: «Әйдә, минем фатирга кайтабыз», – дип тәкъдим ясаган. «Ә Әминәне кая куясың?» – дип турыдан ярган әни. «Ул үз фатирларына кайтып китәр», – дип юаткан Муса. Минем әни Мусаның менә шушы мөнәсәбәтен кабул итә алмаган. Мәскәүгә Усман Әлмиев белән Фәхри Насретдиновның гастрольгә килгән вакыты икән. Минем әни дә Казанда алар оештырган түгәрәкләргә йөргән бит, аның матур итеп җырлавын да белгәннәр. Менә шул ике абзый әнине үзләре белән Урта Азиягә гастрольгә дәшкән. Башка чарасы юк бит, әни шуларга ияреп Ташкентка китеп барган, май аенда шунда мин туганмын...

Без Люция апаны ул яшәгән йортка терәлеп үк урнашкан ресторан залына дәшкән, ризык белән тәм-том китерергә дә заказ биргән идек. Люция апа ялындырып кына дигәндәй, кайнар чәйдән йә чәкчәктән авыз итеп ала да, янә ерак хатирәгә чума.

– Әни миңа 4-5 айлар чамасында Казанга әйләнеп кайткан. Мин буйга бик кечкенә булып туганмын бит, кешеләр дә саф һаваны, авыл сөтен киңәш иткәч, әни Идел аръягында, Югары Ослан ягындагы дачаларда бер йорт табып, фатирга кергән. Мусаның да Мәскәүдә эше тәмамланган, ул да кайтып төшкән. Кем ашадыр безнең кайда яшәвебез турында белешкән дә, бер кичтә паром белән Идел аша чыгып, безнең йорт янына да килеп җиткән. Әнидән: «Миңа кызымны, Люцияне күрсәт», – дип ялвара икән. Миңа алты ай вакытта әти мине кулларына алган. Аннан соң да берничә ел буе безнең янга килеп йөргән әле. Арада хатлар да йөргән. Миңа әни аларны инде мин үсеп җиткәч кенә күрсәтте. Гәрчә әни ул хатлар һәм әти белән ике арадагы мөнәсәбәт турында шигырьләр дә язган...

Люция ханым әнисе Зәкия Садыйкованың 1940 елда Татполитиздатта нәшер ителгән «Гөлкәй» атлы шигырьләр җыентыгын ачып салды. «Өч хат» исемле шигырь юлларына йотылдым. Муса Мәскәүгә китеп югалгач, Зәкия аңа көн саен диярлек хат юллаган булган, һаман җавап көткән. Ә беркөнне Мусадан шушындыйрак эчтәлекле хат килеп төшкән.

«Безнең сукмак бергә түгел, кызый,
Өйләнергә әле ашыкмыйм.
Бала өчен киңәш сорап язма,
Мин бит читтә, аңар катышмыйм.
Без дә бергә була алмагандай,
Юлыбыз да хәзер аерым.

● Җәлилнең улы Альберт белән кызы Люция 1960 елларда.

● Люция ханым Андре Тиммерманс һәм аның хатыны Мария Жан белән. 1966 ел.

Ана булгач, кинәт сулып киттең,
Тик бала дип кенә кайгырдың...»

Легендага әверелгән Мусаның мондый мөнәсәбәтен хакыйкать дип кабул итү авыр. Зәкия ханымның да күңеле кайткан, ахры, 1940 еллар үрендә партиянең өлкә комитетында эшләүче Галимҗан Шәфиев атлы бер хезмәткәр аңа тәкъдим ясаган: «Хатының вафат булды, ике сабый ятим калды, әйдә, кушылыйк; Люцияне дә үз баламдай сөеп үстерермен». Зәкия ханым ризалыгын биргән. Ләкин партия чиновнигы коры холыклы, салкын канлы булса гына өлкә комитетына кадәр үсеп җитә бит ул. Ошбу Шәфиев тә Зәкиянең төннәрен шигырь язып чыгуын сизеп ала да, иртә белән аларны ертып, мичкә ата икән. Аптыраган Зәкия Муса бүләк иткән машинкада басып, Шарль Перро әкиятләрен татарчага тәрҗемә итә башлаган, 1948 елда алар, «Кызыл калфак» атлы булып, нәшриятта да чыккан.

Муса да үзенең кайсыдыр борылышта кызу холыклырак адым ясап ташлавын аңлап алган, билгеле. Ике ут арасында калган шагыйрьнең Зәкия кияүгә чыкканнан соң аңа атап язылган бер хаты моны бик нигезле раслый.

«Зәкия!.. Люцияне бик күрәсем килә! Ул үсеп зур булыр... Минем шигырьләрем белән танышыр, үзендә миңа карата бик тирән якынлык сизәр. Ул мине йөрәгендә саклар. Ник сакламасын? Мин эти бит аңа!.. Мин бик теләр идем Люцияне үземә алырга! Син бир миңа Люцияне! Сездә болай да өч бала, сезгә авырдыр. Мин Люцияне синнән ким тәрбияләмәм. Аннан соң Зәйнәп (сеңелем) Казанга күчә бит! Ул инженер. Ирсез, баласыз. Ә бала бик ярата. Ул карар. Миңа да якын булыр... Тәкъдимемне кире каксагыз, миңа үлем белән бер... Хуш, акыллым! Теләсәң нишлә, ихтыяр синдә! Сәлам белән Муса.»

Зәкия, әлбәттә, кадерле Люциясеннән баш тартмаган. Бәлки, Мусага җавап та биреп тормагандыр...

Ике арада элемтә өзелгән булганга, сугыш вакытында да, соңыннан да Муса язмышы белән ачыктан-ачык кызыксынмаганнар. 1942 елда гына Татгосиздатта Мусаның «Тупчы анты» дип исемләнгән җыентыгы чыккан була бит, аны әсирлеккә төшкәндер, фашистлар кулындадыр, дип күз алдына да китерә алмаганнар. 1946 елда Зәкия ханымга Фатыйма Ильскаялар хәбәр җиткергән.

– Нигъмәт Терегулов атлы бер офицер Алишларга Абдулладан сәлам алып кайткан. Бәлки, Муса турында да берәр хәбәр бардыр. Бар, син, белеш.

Зәкия сораша башласа, Терегулов Язучылар берлеге рәисе Әхмәт Ерикәйгә ниндидер шигырьләр блокноты кертеп тапшырган да, аны шул көнне үк кичен кулга алганнар, хәзер кайдалыгын да белүче юк икән. Алишныкылар белән бергә сораша-сораша гына ачыклауга ирешкәннәр: кемнеңдер Берлин үзәгендәге Моабит төрмәсендә язылган шигырьләрен алып кайткан Нигъмәт Терегуловны Черек күл подвалында атып үтергәннәр икән...

Татарстанның Архив эше буенча дәүләт комитеты мәгълүматлары буенча, беренче дәфтәрне җәлилчеләр утырган Тегель төрмәсеннән 1944 елның февралендә Габбас Шәрипов исемле кеше алып чыга һәм Франциядә Ле-Пюи лагеренда Нигъмәт Терегуловка тапшыра. Габбас Шәрипов Җәлил-Кормаш төзегән яшерен оешмада катнаша, шуның өчен фашистлар аны төрмәгә яба.

Моабит төрмәсенең элекке әсире Нигъмәт Терегулов дәфтәрне каршылык хәрәкәтендә катнашкан француз партизаны Мария Дубизага сакларга бирә. Шигырьләр Марияның әнисе өендә бер ел саклана. Сугыш беткәч, Нигъмәт Терегулов ул дәфтәрне үз кулына ала, почта аша җибәрергә җөрьәт итми, Татарстан Язучылар берлегенә дә үзе илтеп тапшыра. Беренче «Моабит дәфтәре»н алып кайткан өчен үзен үлем көтеп торуын күзаллый алмый шул...

Ә Казанда Җәлил исемен кара болыт урап ала, аның «Хат ташучы» поэмасын дәреслекләрдән алып ташлыйлар, бераздан «Җәлил – хыянәтче» дигән кара ярлык та өстәлә. Аны телгә алу, әсәрләрен кычкырып кабатлау да дәһшәт белән яный. Җәлилнең якыннары 1950 еллар уртасына чаклы үз кабыкларына төренергә мәҗбүр була.

Аннары күк йөзендә кояш елмая башлый. 1953 елда Константин Симонов Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ндәге бер дистә шигырен Мәскәү газеталарында бастырып чыгара. Җәлил-Кормаш группасының батырлыгын ачыклау эшенә Юрий Корольков, Гази Кашшаф кебек әдипләр җигелә. Ниһаять, 1956 елда Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Алдагы елда Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»н Ленин премиясе белән дә бүләклиләр. Премияне тапшыру тантанасына Әминә ханым белән Чулпаннан тыш, совет офицеры Альберт Җәлилов белән Люция Җәлилованы да чакыралар. Җәлил балалары беренче тапкыр менә шул тантана вакытында таныша. 100 мең сум күләмендәге премияне өч балага һәм Мусаның законлы хатыны Әминә ханымга 25 шәр мең итеп бүлеп өләшәләр. Хөкүмәт һәм партия җитәкчеләреннән беркем дә, бер генә оешма да Альберт белән Люцияне нәкъ Чулпан шикелле үк Җәлил баласы дип танудан баш тартмый, өч бала да хөкүмәт тарафыннан тигез бәяләнә.

Премия тапшыру тантанасына Бельгиядән Җәлил белән Моабит төрмәсендә бер камерада утырган антифашист Андре Тиммермансны да чакырып китерәләр. 86 яшьлек Люция ханымның бүген ирләрчә өздереп бәя бирә алуы сокланырлык:

– Әгәр 1946 елда Тиммерманс Бельгиядәге совет илчелегенә этинең икенче «Моабит дәфтәре»н китереп тапшырмаган һәм аның хыялдагы, уйдырма копиясен АКШ илчелегенә тапшыру белән куркытмаган булса, Җәлил исеме һәм иҗаты совет иленә гомергә дә әйләнеп кайтмас иде. Ярый әле, Андре абый табылган, ул гына этине, Алишны һәм аларның көрәштәшләрен «хыянәтче» дигән кара таптан йолып кала алды...

Шунысы гаҗәп: тантана залына җыела башлагач та, Андре Тиммерманс иң беренче булып Люция ханымны, ул чагында 21 яшьлек кызны кочагына алган. «Әтиеңә бигрәк нык охшагансың, мин яңадан Мусаны күргән кебек булдым», – дип пышылдарга да онытмаган әле.

Люцияне 1957 елда ачылган һәм М.Җәлил исеме бирелгән опера һәм балет театрын ачу тантанасына да чакыралар. Залда Советлар Союзы гимны уйный башлагач, яшь кыз бала күз яшьләрен тыя алмыйча торып баса. Шулвакыт аны Хәлил Әбҗәлилов кочагына алып юатырга ашыга, Люция исә аның һаман ни өчен үзен якын итү сәбәпләрен төшенә алмый.

Тиммерманс белән Люция икенче мәртәбә 1966 елда, Җәлил тууның 60 еллыгын билгеләп үткән чагында очраша. Ул вакыт эчендә Тиммерманс Люция белән Альбертның читкә тибелүе турында да ишетеп өлгергән була инде. Люция аны озатырга дип аэропортка баргач, кызга карап тора-тора да, «Син бит миңа туган сеңелем кебек, әгәр авыр булса, әйдә, Бельгиягә», – дип эндәшә. Янда тәрҗемәче булып ияреп йөргән шымчы барлыгы турында да онытмалар, ә тегесе өч хәрефле оешмага кайтып хисап тотмый калмый. Болай да эт типкесендә йөргән Люциянең баш өстендә болытлар куерганнан-куера.

Ә югыйсә, илленче елларда барысы да әйбәт кенә ага кебек ләбаса. Сигезенче классны тәмамлауга ук, Люция Казан музыка училищесына кабул ителә. Анда дирижерлык бүлегендә укый башласа да, Җәлилне якын күргән Җәүдәт Фәйзи кебек композитор һәм Хәлил Әбҗәлилов кебек халык артисты, өстәвенә әле җырчылар кайгыртуы буенча, училище директоры Әүхәдиев Люцияне вокал бүлегенә дә кабул иттерә. Люция, нәкъ әнисе шикелле үк, матур итеп җырларга өйрәнә. Кызга зур сәхнә һәм консерватория юрыйлар. Ә ул тота да Мәскәүдәге кинематография институтына барып керә. Ике ел укый да, чирләп, түшәккә егыла. Савыккач, янә укуын дәвам итә, диплом эше итеп этисе турында документаль фильм әзерли. «Рожденный революцией» (аны Җәлил ачкан журнал шикелле үк «Октябрь баласы» дип тәрҗемә итү уңышлырак сыман) дип аталган әлеге фильмда Люция этисенең пионер һәм комсомол сафларында чыныгу еллары тасвирлый. Ләкин көтелмәгән җирдән «коточкыч бәла» эзләп табалар: «Син титрларга Җәлилова дигән фамилияңне куярга тиеш түгел, чөнки син Җәлилнең уйнаштан туган баласы; фамилияңне алыштырмасаң, фильм дөньяга чыгачак түгел!» Бактың исә, институтның ректорына Татарстан Язучылар берлегенең партоешма җитәкчесе Г.К. исеменнән хат килеп төшкән, ул да, Җәлил исеме белән «сәүдә» итеп йөргән өчен, Люцияне җаваплылыкка тартуны таләп итә икән. Казанга кайтса, чит данга борын сузуда гаепләп, аңа Җәлил турында берничә әсәр язган Ш.М. ябырыла. Ул да, күрәсең, Люция белән Альбертны читкә этеп, Чулпанны яклап чыгуны хаклы санагандыр.

(Дәвамы 14 нче биттә).

● Люция белән Альберт Җәлиловлар 1980 елларда.

● Люция апаның кызы Лилиан эш вакытында.

ҖӘЛИЛ КЫЗЫ ЛЮЦИЯ

(Дәвамы. Башы 12 нче биттә).

Ахыр чиктә, инде түземлеге коргаксыган Люция фамилиясен элек үги әтисе булган Шәфиев фамилиясенә алыштыра. Фильм чыга-чыгуын, әмма аның күбәйтелгән барча нөсхәсен дә Коммунистлар партиясе белән теләктәш булган Африка, Азия һәм Көньяк Америка илләре буенча гына тараталар. Люциягә 12 ел вакыт узганнан соң гына хәбәр итәләр: аның Җәлил турындагы «Октябрь баласы» патриотик фильмнар катнашкан 12 фестивальдә җиңү яулаган, ә аңа тиешле премияләрне «Мосфильм» хуҗалары үзара бүлешеп бетергән икән инде!..

Люция менә шулай итеп – үз хезмәтенең нәтиҗәсен белмәгәнгә, дөресрәге аннан яшергәнгә күрә, 12 ел буе диплом яклый алмый. Ул 12 ел дәвамында Казанның кайсы оешмаларына гына барып һәм ялварып карамый, япь-яшь, чибәрләрдән-чибәр кызны бер җирдә дә эшкә алмыйлар. Түзә алмагач, Люция Югары Совет рәисе С.Батыев янына да, партиянең өлкә комитеты секретаре М.Вәлиев янына да үтеп керә. Тегеләре мең төрле вәгъдәләр биреп, Люцияне тупса арьягына озата, әмма ялгыз кызга ярдәм итү өчен кыл да кыймылдатмый. Люция, аптырагач, балалар бакчаларында үзенә музыка буенча тәрбияче вазыйфасын да сорап карый, ләкин бу юлы да кызны тупса арьягына гына аткаралар. Әле ярый, кайбер елларда мәдәният институты ректоры ярдәм кулы суза, аны 1 октябрьдә санаулы сәгатьләр генә укытучы итеп эшкә ала да, 1 май көнне эштән азат итә.

– Кайбер елларда утырып сананым булды, – дип ачынып сөйли Люция ханым. – Бер айда 90 сум хезмәт хакы алсам, икенче айда 16 сум гына туры килгән икән. Ел дәвамына бүлеп санасаң, аена 50 тәңкә.

Ә Җәлилнең шигырьләре томтом булып һаман чыга тора, аларны әле дөньяның 115 теленә дә тәрҗемә итәләр бит. Тик каләм хаклары «баш гаилә»гә һәм тәрҗемәчеләр кесәсенә ага...

Атаклы режиссер С.Герасимов һәм аның хатыны, халык артисткасы Т.Макарова ярдәме белән, ниһаять, 1978 елда Люция кулына диплом алуга ирешә. Инде ике диплом күтәреп Казан киностудиясенә эш сорап барса да, «бездә сиңа яраклы эш юк» дип, барыбер кире генә борып чыгаралар. Йөз суын түгә-түгә, айлар буе йөри торгач, ниһаять, пропаганда буенча редактор итеп кабул итәләр. Сүз дә юк, Люциянең профессионал осталыгы да, квалификациясе дә акрын гына коргаксый. Шулай да, Камал театрының иң күренекле артистлары Ренат Тажетдинов, Ирек Баһманов, Шәүкәт Биктимеров катнашкан берничә спектакль һәм документаль фильмнар төшерергә өлгерә әле...

Ни кызганыч, сабый чактан бирле Җәлилнең билгесез һәм яшерен улы булып яшәү Альбертның да үзеген нык өзгәли, ул 90 нчы елларда мәңгелек дөньяга да китеп бара...

● Люция Җәлилова рояль артында. Басып торган ир – Фасыйл Әхмәтов. Арттагы ханымның исеме билгесез. 1950 еллар азагы.

Люция ханымның да Казаннан һәм татарларның икейөзлелегеннән күңеле кайткандыр, ул Наврозашвили атлы бер грузин егете белән кавыша. Аннан туган кызы Лилиан да Казанда калуны кирәк тапмый. Ул Ленинград каласына китеп, радиога эшкә урнаша. Лилианның уенын тамашачылар, мөгаен, «Улица разбитых фонарей» сериалында күргәндер...

Люция апа үзенең Мостафа авылында бер тапкыр да булмавы турында әйтеп салгач, без гаҗәпкә калдык.

– Әле 2014 елда гына Җәлил музеена яңарту үткәрделәр бит. Мостафа – Җәлилнең туган авылы, димәк, ул сезнеке дә! – дип карыйбыз, ә ул кире кага.

– Бер тапкыр да чакыручы булмады бит, ә үзем генә, кая барып керим?

Без соңгы тапкыр өч ай элек кенә, ноябрь башында шунда булып кайттык. Мостафада 13 укучы гына белем алып йөри, Җәлил авылы булган өчен генә тугызъеллык мәктәпне саклап калганнар. Люция апага музей турында, СССРның халык артисты дәрәҗәсенә ирешкән Хәлил Әбҗәлилов портретының «баш гаилә» фәрманы буенча музейдан чыгарылып, мәдәният йорты диварына эленүе, ә Хәлил аганың Муса белән туганнан туганнар булуы хакында сөйлибез. Люция апа аларның туганнар булуын ялгыш та ишетмәгән, хәтта хәйран калды...

Люция апа янына 17 ел буе бер генә татар әдибе дә килмәгән. Ләбиб Лерон белән мин фәкыйрегезне күргәч, чиксез гаҗәпләнде, ә ахырда безне чыгарып җибәрмичә, озак «газаплады».Люция апа белән кызы Лилианны кунакка чакырдык, Мостафа авылына алып барырга да вәгъдә иттек. Люция апа әтисе туган туфрактан йөргүгә дә, авыл халкы тарафыннан хөрмәт ителүгә дә лаек. Халыктан хакыйкатьне яшерү һәм геройларны ал буяулар белән генә бизәү бик күпләргә газап-хәсрәт сала. Без моңа Люция апа белән Альберт әфәнде мисалында да инандык. Бала кеше газиз әти-әнисенә хыянәт итә алмый, Люция апа өчен дә җир йөзендә иң кадерле кеше – Муса Җәлил, менә шунысы кыйммәт.

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

● Люция космонавт Герман Титовтан култамга ала. 1960 еллар.

● Люция апа 1966 елда төшергән «Октябрь баласы» фильмыннан бер кадр.

Артистларның җыр остазы

Кариевләрне җырлый торган театр, диләр. Чыннан да, анда һәр артист җырлый. Моңлый дан таралуга, музыкаль мирасыбызны сәхнәгә күтәрергә омтылган, «Галиябану», «Башмагым» һ.б. спектакльләребезгә яңа сулыш өргән баш режиссер Ренат Әюпов сәбәпче, әлбәттә. Артистларны җырлатучы мөгаллим исә – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Лилия Зәйнуллина.

Җыр мөгаллимнәре бүтән театрларыбызда да бар. Әмма Лилия ханым – Кариев театры өчен чын мәгънәдә зур табыш, чөнки ул Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында хор-дирижер, консерваториябезнең ялгыз вокал бүлекләрен тәмамлаган җырчы гына түгел, күренекле музыкантыбыз Ренат Гыйләҗев җитәкләгән «Сорнай» ансамбле мәктәбен үткән шәхес тә. Ике йөзләп халык җырын, дистәләгән йола күренешләрен халкыбызга яңадан кайтарган «Сорнае»быз бит ул! Онытылган татар музыка уен коралларын табып-торгызып, яңадан ясап, аларда уйнарга өйрәнеп, осталык дәресләре, сәхнәдәге чыгышлары аша думбра, саз, ятаганнарны популярлаштыру буенча бәһасез эш алып барган газиз коллективыбыз! Җыйнак кына булса да, «Сорнай» җыр, бию, музыка башкару сәнгатьләрен берләштерә. Җырлап биер өчен артистларыннан киң сулыш, көчле тавыш сорала. «Сорнай» илебезнең татарлар яшәгән төрле төбәкләрендә генә түгел, Германия, Финляндия, Болгария, Австрия, Франция, Бельгия, Италия һ.б. күп кенә илләрдә көй-моңнарыбызны тамашачыга ирештерде, бөтендөнья фольклор фестивальләрендә лауреат исеменә лаек булды, халыкара этномузыка симпозиумнарда катнашты. «Сорнай» белән бергә Л.Зәйнуллина да ярты дөньяны йөреп чыкты, борынгы музыка уен коралларында уйнарга өйрәнде, җырлап, биеп, зур мәктәп үтте.

Г.Кариев театрына ул, консерваториянең икенче курсында укыганда, педпрактикага гына килә. Ул вакытта әле театрның Кариев исеме дә, бинасы да юк, Островский урамындагы бер бинаның почмагында уйныйлар, шунда ук артистларның тулай торагы да урнаша. Әмма татар яшьләр театрының киләчәге яулыйсы үрләре хакына язмыш «Сорнай» җырчысы Лилияне труппа белән бәйли. Бүген бары тик Кариев театрында гына шулкадәр җырлы спектакльләр бар, бары анда гына яше-«карты» яратып, тәмен белеп, татар халык җырларын башкара, Кариев артистлары гына икешәр-өчәр сәгать дәвам иткән җыр концертлары оештырырга сәләтле. Л.Зәйнуллинаның мөгаллим буларак осталыгын беренче спектакльләрдән үк югары бәялиләр. Бөек Ватан сугышы каһарманнары турында «Кызлар-йолдызлар» спектакле белән Брест шәһәренә баргач, мәсәлән, артисткаларның унлап «акапелла» башкарылган җырын ишетеп, тамашачы, театр белгечләре махсус вокаль ансамбль җырлый дип алдана, соңыннан драма артистларының шулай оста җырлауларын аңлагач исә, шакката. Казанга әйләнеп кайткач, кызлар-йолдызлар Лилиябезгә зур уңыш белән узган иҗат сәфәрләре өчен рәхмәт белдереп, кул чаба. Татар авылларының җир йөзеннән юкка чыгуы, милли йолалар, тел онытылу турында әрнеп куелган «Микулай» спектаклендә артист кызларыбыз башкаруында керәшен җырларын тыңлагач та, «Бәрмәнчек» ансамбле җырчылары чыгыш ясый, дип алданучылар байтак булды. Декабрьдә генә «Һөнәр» яшь режиссура фестивале гөрләп үтте. Анда Болгарда ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан «Йосыф» спектакле дә күрсәтелгән иде. Гөнаһ шомлыгына, фестиваль грипп чире котырган вакытка туры килеп, труппаның бериш артистларына авырган килеш уйнарга туры килде. «Йосыф» спектаклендә исә күпләребез гомер ишетмәгән мөнәҗәтләр яңгырый. Әлеге дә баягы режиссер Ренат Әюпов аларны спектакль өчен махсус эзләп тапкан. Фестивальдә Мәскәү, Санкт-Петербургтан килгән театр тәнкыйтьчеләре һәр спектакльне энәсеннән җебенә кадәр тикшерә, бәя бирә. «Йосыф»ның бөтен уңай сыйфатларыннан аерып, артисткаларның җыр осталыгын югары бәяләүләре вокал мөгаллиме Л.Зәйнуллинаның зур эш нәтиҗәсен күрсәтә. Киеренке халәттә дә сынатмаска, ансамбльдә бер-берсен ишетергә, янәшәдәге артистның тын алуына кадәр тоярга өйрәткән икән, Лилия ханым чыннан да үз эшенең остасы дигән сүз.

Драма артистларын җырларга өйрәтү җиңел түгел. Бөтенесе Аллаһ биргән тавыш белән тумаган, консерватория дә тәмамламаган. Кемдер бала чактан җырларга курка, кемгәдер балалар бакчасында, мәктәптә җырлау сәләтенә кагылышлы авыр сүз әйткән булулары мөмкин. Һәр яңа роль – үзе сынау. Шуның өстенә җырларга да кирәк булса... Актер артык дулкынланырга мөмкин. Салкын тия. Чамадан тыш хисчән артист халкына, күңеле пыяла савыт кебек челпәрәмә килсен өчен, бер сүз җитә. Китек күңел белән җырлап кара! «Ничек килеп керүләреннән, күз карашларыннан күңел халәтләрен аңларга өйрәндем. Кайвакыт йөзенә бер карау җитә, әһә, бу бүген җырлый алмаячак, дим. Әмма бернигә дә карамыйча спектакльне уйнарга, җырларга кирәк. Шуңа күрә мөгаллим генә түгел мин, психолог һөнәренә дә өйрәндем», – ди Лилия ханым.

«Лилиябез кояш кебек, үзенә тартып тора, аның белән аралашып, үзеңә көч аласың, – дип сөйләде күренекле артистыбыз Фәнис Кәлимуллин. – Л.Зәйнуллинаның эше театрда гына бетми, ул тәүлегенә егерме дүрт сәгать безне кайгырта. Сакланырга, киенеп йөрергә, тавыш яраларына зыян китермәс өчен, тегене ашамаска, моны эчмәскә куша, көнбагыш чиртмәгез, ди, безгә җил дә тидерми. Лилиябез – сәхнәдә искиткеч артист та, тормышта милләтебезнең иң матур сыйфатларын үзендә туплаган, соклангыч зыялы шәхес тә». «Режиссерыбыз Ренат Әюпов безгә сәхнә сәнгатен ачса, җыр дөньясына Лилия Зәйнуллина алып керде, – дип сөйләде күренекле артистка Лилия Низамиева. – Без радиодан, телевизор экраннарыннан яңгыраган халык җырларын гына белсәк, «Сорнай» ансамблендә иҗат иткән артистка буларак Л.Зәйнуллина безгә гомер ишетмәгән халык җырларын өйрәтте, җыр мирасыбыз никадәр бай икән, дип көннән-көн ныграк гаҗәпләнәбез... Бөтен кеше дә җырлый белеп тумый. Лилия мине җыр сәләтемә ышанырга өйрәтте. Спектакль вакытында ул пәрдә артында торса, безгә тынычрак, җырлавы рәхәтрәк, ул көч өсти сыман».

Репертуарда профессиональ композиторларның җыр, музыкалары башкарылган спектакльләр дә байтак. Луиза Батыр-Болгари, Эльмир Низамов, Зөлфия Рәупова, Эльмира Галимова, Миләүшә Хәйруллина һ.б. моң ияләренең әсәрләрен дә сәхнә өчен бердәй оста әзерли мөгаллим.

Ничек барысына да өлгерәдер, Л.Зәйнуллина «Дорога звезд» иҗат мәктәбендә балаларга вокал серләрен дә ирештерә. Анда укыган кызлар, малайлар байтак дәрәҗәле бәйгеләрдә җиңү яулады. Шуның өстенә, «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә татар балалары өчен оештырылган «Апуш» театр студиясендәге сабыйларны җырларга өйрәтә. Җырлы рольләрдә үзе дә сәхнәгә чыга. «Җиде кыз», «Айрыз батыр» спектакльләрендә иҗат иткән образлары әле һаман да күзалдыннан китми...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Акмулланың яңа басмасы

Татар, башкорт, казах халыкларының уртак мәгърифәтче шагыйре Мифтахетдин Акмулланың (1839–1895) иҗат мирасын барлау, әсәрләрен чыгару, фәнни нигездә өйрәнү өлкәсендә шактый эшләр башкарылды.

Әлеге юнәлештә Октябрь түнтәрелешенә кадәр үк Габделбари Баттал (1880–1969), Ризаэтдин Фәхретдинов (1859–1936), Хәсән Гали (1878–1940), Дусмаил Качкынбаев (?–1917 елдан соң), Җамал Вәлиди, Габдулла Ураев (?–?) кебек танылган зыялылар шөгыльләнде. Совет чорында һәм хәзерге вакытта Сәкен Сәйфуллин (1894–1938), Сәйфи Кудаш (1894–1993), Мөхәммәт Гайнуллин (1903–1985), Бейсембай Кенежебаев (1904–1987), Фатих Кәрим (1909–1945), Кирәй Мәргән (Әхнәф Нури улы Кирәев, 1912–1984), Әхнәф Харисов (1914–1977), Бөркет Исхаков (Ысқақов) (1924–1991), Гайса Хөсәенов, Миркасыйм Госманов (1934–2010), Вафа Әхмәдиев (1937–1983), Вәлиҗан Калижанов, Рафис Әхмәтов (1945–2007), Әхәт Вилданов, Рәшит Шәкүров, Фәнис Янышев, Рәис Котошов, Миңнегали Нәдерголов, Рәмил Исламов, Әхәт Салихов һ.б. галим-язучылар тарафыннан дәвам иттерелә.

Акмулла әсәрләренең җыентыкларын типография ысулы белән нәшер итү шагыйрь үзе исән вакытта ук башлана. 1892 елда Казан Император университеты матбагасында тарихчы, мәгърифәтче Ш.Мәрҗанигә багышланган «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» дип аталган әсәре аерым китап итеп бастырыла. Кызганыч ки, әлеге басма тарихына карата аның үзендә бернинди дә мәгълүмат китерелми.

Шагыйрьнең «Акменла әфәнденең иншад итдегә мәнзуматилә башка бер кач мәншәдатыны вә кәндесенең тәрҗемәи халене мөштәмил мәҗмугадер» исемле икенче җыентыгы 1904 елда, Троицкидагы «Хезмәт» ширкәтенең матди ярдәме белән Казанда И.Н.Харитонов (1859–1954) басмаханәсендә дөнья күрә. Аны төзүче тарихчы Г.Баттал шагыйрьнең әсәрләре белән бергә аның тәрҗемәи хәле турында да кызыклы гына белешмә урнаштыра. Ул Акмулланың кайсы мәдрәсәләрдә белем-тәгълим алуы, Троицкида Зәйнулла ишан (Зәйнулла Рәсүли (1833–1917) белән аралашуы, иҗатының кыйммәтен ассызыклый.

Шулай да Г.Баттал төзегән җыентыкның тулы булмавына игътибар итеп, танылган дин эшлеклесе Р.Фәхретдин үзенең биобиблиографик характердагы фундаменталь «Асар» дигән хезмәтендә (Россия Фәннәр академиясе Уфа гыйльми үзәгендә саклана торган кульязма дүртенче җилд (7 ф., 1 тасв., 15 эш) болай яза: «Акмулланың шигырьләре вә нәвадире (кызыклы вакыйгалары – Р. И.) бик күп, монларны җыеп тәдкыйк итүгә озын вә иркен вакыт кирәк. Габделбари Баттал әфәнде тарафыннан җыелып бастырылган шигырьләре мең дә бер генә булыр».

1907 елда шул ук ширкәт нашириләгендә Казандагы Шәрәф матбагасында әдипнең «Мәшһүр шагыйрь Акменланың Шиһабетдин әл-Мәрҗанинең мәрсиясе вә башка шигырьләре» дип исемләнгән өченче җыентыгы нәшер ителә. Анда Р.Фәхретдиннең «Фазыйль Мәрҗанинең кыскача тәрҗемәи хале» дигән язмасы белән бергә Г.Батталның алдагы басмадагы белешмәсе кабат урын алган.

Совет чорында беренче тапкыр булларак, Акмулланың казах телендә латин графикасында «Ақмолла (Мифтахетдин Мұхамедиярұлы). Өлең жинағы» дигән җыентыгы Алматы шәһәрендә нәшер ителә. Аны танылган язучы С.Сәйфуллин төзи. Кереш мәкаләсендә шагыйрьнең әсәрләрен, аның китапларын (сүз мәгълүм басмалары турында булса кирәк. – Р.И.), башка мәгълүматны туплауда Башкортстанда яшәүче Вәли Хангилде улы һәм Исмәгыйль Урман улы дигән кешеләрнең ярдәм итүләрен белдерә. Әмма әлеге басмада Г.Кандалыйның (1797–1860) «Сәңа, жаным, дога иттем» дип башланган һәм традицион рәвештә «Сахибҗамал» дип йөртелә торган поэмасыннан эзлексез рәвештә алынган унике куплеты («Сахипҗамал атты қызға», «Сахипжамал деген қыз өзине келмей бир ауыл мөжигине кетуден қорқып айтқаны» дигән исемнәр астында) Акмуллага нисбәтле ялгыш урнаштырылган.

Акмулланың тормыш юлы һәм иҗат мирасын 1965 елдан башлап эзлекле рәвештә өйрәнүчеләрнең берсе булган тарихчы-галим М.Госманов шагыйрь әсәрләренең җыентыгын төзеп, 1981 елда Казанда бастыра.

Шагыйрь иҗатын шулай ук махсус өйрәнгән әдәбият галиме Ә.Вилданов тарафыннан төзелгән җыентыклар Уфада нәшер ителә (1981, 2006). Биредә Акмулла шигырьләренең рус теленә тәрҗемәләре дә бастырыла (1986, 2006).

Шагыйрьнең Казахстанда дөнья күргән икенче басмасы әдәбият галиме Б.Исхаков тарафыннан төзелеп, «Күңдер мен түңдер» исеме белән нәшер ителә.

Әдәбият галиме Ф. Яхин Акмулла әсәрләрен аерым китаплар итеп 2001, 2016 елларда Казанда бастырып чыгара.

Акмулланың башкорт һәм төрек телләрендәге җыентыгы Ә. Салихов, Г. Ибраһимов, Р. Исхаков, С. Азимоглы, М. Мәхмүтоглы, С. Мулазимоглы тарафыннан әзерләнеп, Әнкарада басыла (2007).

2020 елда Казахстанның Актүбә шәһәрендә Акмулла турында тикшеренүләр, шагыйрьнең әсәрләре тупланган «Дала даулпазы» дигән җыентык дөнья күрә.

Шулай итеп, хәзерге вакытка Акмулла



әсәрләренең татар, башкорт, казах, рус, башкорт, төрек телләрендә 14 басмасы барлыгы ачыклана.

Акмулланың тормыш юлы һәм иҗат мирасын өйрәнүнең үткәндәге бай тәҗрибәсе, хәзерге вакытка ирешелгән фән казанышлары, шигырьләренең кайбер аерым нөсхәләре һәм күчермәләре табыла торуы – шул нигездә шагыйрь әсәрләренең җентекле анализланган текстларын төзеп, фәнни яңа җыентыгын нәшер итү зарурлыгын барлыкка китерде. Әлеге мөһим мәсьәлә төрле елларда Р. Исламов, М. Нәдергулов тарафыннан күтәрелгән иде.

Үткән елның көз башларында «Рухият» хәйрия фонды Акмулланың безнең тарафтан әзерләнгән күләмле яңа басмасын нәшер итте. Ул «М.Акмулла: тормыш юлы һәм иҗаты» дип атала. Аның композицион корылышы шулай: I. М.Акмулланың шигырьләре. II. М.Акмулланың тормышы һәм иҗаты турында. Кушымта.

Җыентыкның кереше булган «М.Акмулланың тормышы һәм иҗат мирасы (Өйрәнелү тарихы һәм фәнни яңа басмасы)» дип исемләнгән махсус мәкаләдә шагыйрьнең тормышы һәм иҗатын өйрәнү юнәлешендә моңа кадәр башкарылган хезмәтләргә тирән аналитик күзәтү ясала. Электә ирешелгән казанышлар белән бергә соңгы берничә дистә ел эчендәге яңалыкларга, шагыйрь әсәрләренең тагын табылган күчермәләренә игътибар бирелә. Хәзерге әдәбиятта шагыйрь турында барлыкка килгән әсәрләр, рәсем сәнгатендә аның образларын чагылдыру мәсьәләләре күтәрелә. Әдипне өйрәнү юнәлешендә киләчәктә башкарыласы кайбер эшләргә юнәлешләр билгеләнә. Хосусан аларның кайберләре, безнең карашка, шулар: Акмулланың Троицк төрмәсенә ябылу һәм аны мәхбүслектән коткаруга бәйле рәсми документлар әлегә бөтенләй өйрәнелмәгән. Алар булырга тиеш. Шул вакыттан йөз ел элек Батырша (1710 яки 1715–1762) җитәкчелегендәге халык кузгалышы турында материаллар сакланган бит! Шагыйрьне явызларча үтергән угрылар да тотылган, аларга карата кузгатылган җинаять эше дә бар булырга кирәк. Акмулланың казах галимнәре тарафыннан җыйналган әсәрләре (алар Казахстан Фәннәр академиясендә саклана – Р.И.) фәнни нигездә өйрәнелүләрен көтә. Анда да яңа фактлар табылуы ихтимал.

Хәзерге вакытта дөнья күргән яңа тарихи һәм филологик характердагы чыганаклар шагыйрь әсәрләрендә телгә алынган һәм заманында үзе аралашкан шәхесләрне, төрле атамаларны, башка моментларны тулырак ачыкларга һәм киңрәк яктыртырга мөмкинлек бирә. Бу исә шагыйрь иҗатын тагын да этрафлырак, тирәнрәк һәм дөрес итеп аңларга ярдәм итә. Шуңа күрә астөшермә рәвешендә китерелгән аңлатма-шәрехләр мөмкин кадәр киң һәм тәфсилле башкару бурычы куелды. Файдаланылган чыганаклар нинди телдә булса, алынган мәгълүмат та шул телдә китерелде. Бу тәрҗемә итү барышында була торган кайбер аңлашылмаучанлыкка юл калдырмау максатыннан шулай эшләнде.

Җыентыкның беренче бүлегендә шагыйрьнең утыз биш әсәре тупланды. Алар арасындагы тугызының төрдәшләре дә урнаштырылды. Моңа мисал итеп «Гаҗәб: һәркем гъәни улса, аңа хөсне дидар әйләр...» дип башланган шигырьнең ике, «Даһа бер кач нәсыйхәтләре мөтәзаммән әбъяты» сериясеннән «Иң әүвәл кирәк нәрсә иман дигән...» дигән юл белән башланган шигырьнең хәтта биш төрдәшен күрсәтергә мөмкин. Нигез нөсхә дип алынган шигырьне алар белән чагыштыруны җиңеләйтү максатында текстлар бергә китерелде.

Бер үк шигырьдәге строфаларның аерымлыклары астөшермәләрдә чыганаклары белән күрсәтелеп барылды. Мәсәлән, Д.Качкынбаев дәфтәрендәге бер үрнәккә игътибарны юнәлтик:

Карасаң, Акмулланың диваны бу,
Диванында – шүлләгәнгә ширбәтле су;
Бәйтенең бере кәләр, бере сүгәр,
Тура сүз берәүгә – им, берәүгә – у.

Ә Х. Гали җыентыгында ул болай яңгырый:

Күрсәңез Акмулланың диваныны,
Диванында чүлләгәнгә ширбәтле су.
Күргән соң берәү үгәр, берәү сүгә,
Тугры сүз берәүгә – үй, берәүгә – у.

Россия Фәннәр академиясе Уфа федераль үзәге Тел, тарих һәм әдәбият институтының Г.Хөсәенов исемендәге кульязмалар фондында «Акмулланың әткәсенә язмыш мәктүбе» (Башкортстанның Бүздәк районы Канлы-Төркәй авылында табылган – Р. И.) һәм «Акмулланың әткәсенә язган хаты» (Үзбәкстанның Фәргәнә өлкәсендә күчерелгән – Р. И.) дигән бер үк тәңгәл текстлы шигырьләр саклана. Әмма чагыштырып тикшерүдән күренгәнчә, Фәргәнә нөсхәсендәге:

Бер атка бер вакытда торыр идек:
Без дә бер мәрданәмез – түгел хатын.
Абруйсыз калганы юк озынборын,
Алда шайдә хур булмас коры борын;
Ат да булыр, тун да булыр –
без булмабыз,
Әман булса, Сезгә кайтыр
туры айгырың, –

дигән юлларның Канлы-Төркәй нөсхәсендә күзәтелмәве ачыклана.

(Ахыры киләсе санда.)

Рәмил ИСЛАМОВ,
филология фәннәре докторы

Олпат каләм иясе

Күренекле прозаик Вакыйф Нуруллин (1935) – XX гасырның 60 нчы еллар башында татар әдәбиятына килгән, үзенә генә хас иҗат өслүбен тудырган, нигездә, повесть жанрында эшләгән өлкән буын әдипләреннән. Күп зыялыларыбыз кебек, ул Казан дәүләт университетының данлыклы татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаган. 1961–1977 елларда «Казан утлары» журналында башта әдәби хезмәткәр, аннары проза бүлеге мөдире булып эшләгән. 1977–1989 елларда Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире вазыйфасын башкарган. Бераз вакыт әдәби иҗат эше белән шөгыльләнгәч, 1993–1995 елларда «Казан» журналын оештыруда катнашып, анда хезмәт куйган. 1995–2008 елларда Татарстан Республикасы Милли музеенда әдәбият бүлеге мөдире булган.

Вакыйф Нуруллин 1963 елда беренче күләмле әсәрен – атаклы «Шинельсез солдатлар» повестен иҗат итә. Кыюсызлыгы аркасында ул аны беркая да тәкъдим итми, вакыты җиткәнне көтеп, берничә ел өстәл тартмасында саклап тота. 1968 елда повесть, ниһаять, «Казан утлары» журналында басыла, шул ук елда Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып та дөнья күрә. Бу әсәр укучылар тарафыннан да, әдәби тәнкыйть ягыннан да җылы кабул ителә. Бала чагы Бөек Ватан сугышы һәм аннан соңгы авыр елларга туры килгән каләм иясенең дебюты аның үз тормышыннан алына, үз башыннан узган, үз йөрәге аша үткән вакыйгаларга нигезләнә. Монда ул сугыш чоры авылының драматик тормышын, авыл кешеләренең тырышлыгын һәм батырлыгын, яшь буынның ватанына тугрылыклы булып, чыныгып үсүен тасвирлый.

«Шулай да, «Шинельсез солдатлар»ны укып чыккач та, прозабызга тормышның

үзеннән, халыкның, бигрәк тә авыл халкының, холык-фигылен, көнкүрешен һәм хезмәт героикасын яхшы үзләштергән, тойган, алай гына түгел, шуларның барысын яшьли үз башыннан кичергән, димәк, җитди әйтер сүзе булган үзенчәлекле прозаик килүен абайларга мөмкин иде инде», – дип яза Ринат Мөхәммәдиев. Әдәбият галиме Фоат Галимуллин исә «үсештәге иҗат» дип бәяли.

1969 елда В.Нуруллинның унике хикәясе тупланган «Төкле аягың белән» җыентыгы басылып чыга. Шуннан соң язучы тулаем повесть жанрына кереп китә һәм тормыштагы кеше характерларын үтә дә нечкә психологизм белән сурәтләүче чын профессионалга әверелә. Аның бер-бер артлы «Күпер чыкканда» (1968–1969), «Әгәр син булмасаң...» (1970–1973), «Яшьнәп үткән яшьлек» (1971–1975), «Аккан су юлын табар» (1976–1979), «Һәлакәт» (1979–1981), «Ике урам арасы» (1980–1984), «Җавап бир, кеше!» (1985–1987), «Сагынырсыз әле...» (1986–1991) әсәрләре языла.

Сугыштан соңгы авыл тормышын сурәтләгән «Күпер чыкканда» исемле икенче повесте да авторга зур уңыш алып килә. «Әгәр син булмасаң...» әсәре исә «Шинельсез солдатлар»ның дәвамы буларак иҗат ителә, чөнки беренче әсәр басылып чыкканнан соң, китап сөючеләр язучыга күпсанлы хатлар юллый, һәркемне төп каһарманның киләчәк тормышы кызыксындыра.

«Яшьнәп үткән яшьлек» документаль материалларга таянып иҗат ителгән повесть булса, «Аккан су юлын табар» әсәре герое шулай ук чынбарлыктан алынган. Соңгысында авыл тормышы һәм анда күмәк хуҗалык рәисенең урыны, кеше һәм табигать, авылның киләчәге булган яшьләр, рухи тәрбия һ. б. мәсьәләләр күтәрелә.

Сүздән сурәт ясаучы язучы-рәссам буларак, язучының каләме әсәрдән әсәргә шомара һәм камилләшә, иҗади колачы һәм сулышы киңәя. Мәхәббәт һәм хыянәт кебек мәңгелек темалар күтәрелгән «Һәлакәт» повесте, шулай ук фактик материалга нигезләнеп, мавыктыргыч сюжетка корылуы белән әһәмиятле.

Вакыйф Нуруллинның «Ике урам арасы», «Җавап бир, кеше!» әсәрләре дә әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан җылы каршы алына. «Сагынырсыз әле...» повесте исә совет чоры җитәкчесе образын гәүдәләндерә, аның туган-тумачалыкка, эшнелеккә, рухи бозыклыкка корылган тормышы ахыр чиктә төп каһарманның үзе өчен үкенечле тәмамлана. Аны укыгач, бүгенге көн күзлегеннән карап, күңелдә үзеннән-үзе «хәзер нәрсә үзгәрде соң?» дигән сорау туа.

«Аның һәр әсәрен бербөтен итеп туплаган көч – публицистика белән лиризм, документаль төгәллек белән сәнгатьчә гомумиләштерүнең бергә үрелүендә, автор шәхесенең эзлекле һәм максатчан булуында», – дип яза әдәбият галиме Мөдәррис Вәлиев.

Язучының Татарстан китап нәшриятында әле генә дөнья күргән яңа китабында («Әгәр син булмасаң...», 2022) аның дүрт повесте – «Шинельсез солдатлар», «Әгәр син булмасаң...», «Күпер чыкканда», «Сагынырсыз әле...» әсәрләре урын алган.

Вакыйф Нуруллин – бәхетле каләм иясе. Ул – утызга якын китап авторы. Әсәрләре рус, украин, таҗик, азәрбайҗан, казах, каракалпак телләренә тәрҗемә ителгән, чит телләрдә аерым басмалар булып та дөнья күргән.

Ленар ШӘЕХ,
филология фәннәре кандидаты.

Хатлар яздым утырып

Чигенүләрнең дә чиге була

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары 23 нче декабрьдә «Президент» исемен үзгәртүгә багышланган утырышны интернетта карап утырдым һәм анда ясалган урынлы, мәгънәле чыгышларны яратып тыңладым. 30 елдан бирле кулланылып килгән «Президент» атамасы югарыдагыларга нигә ошамый? Бу атама белән бәйле рәвештә кемгә дә булса зыяны тидеме яки «президент» булгач, үзенең вазыйфасын җиренә җиткереп башкара алмый башладымы? Алай дип әйтерлек урын юк. Путин үзе дә һәм Мәскәүләрдән килгән башка җитәкчеләр дә, Республикада ирешелгән уңайлыкларны күреп, мактап китәләр түгелме? Мактамаслык та түгел шул. Башкала булган өлкәләрне санамаганда, Татарстан кебек триллион сумга якын байлыгын озатып торган башка төбәк юк икәнен алар беләләр булса кирәк.

Татарстан җитәкчесенең атамасын республика үзе билгели дип, Путин шәхсән дә әйткән иде бер пресс-конференциясе барышында. Бу Конституциядә дә шулай язылган. Кызганыч, аның әйткән сүзләре үтәлми. Үзенә кирәк булганда, илбашы һәрбер халыкның үзбилгеләнү хокукына ия булуы турында халыкара законнарда да әйтелүен искә ала ул һәм иң мөһиме, халык фикерен искә алу кирәк дип әйтсә дә, аның сүзләре буш сүз булып кала. Әле шунысы да бар, Татарстан Президенты гарәп илләренә барып, аларның ил башлыклары белән очрашып, икътисадый яктан Росссиягә кирәкле эшләрне дә башкаручы бит. «Глава» атамасы бирелгән затны чит ил президентлары ничек кабул итәр икән?

Татарстан Дәүләт Советында, Республика җитәкчесенең атамасы «Глава – рәис» дип аталачагы билгеле булды. «Глава» сүзе булмаса ярамады микән? 8 депутат үз фикерләрен әйтеп чыгыш ясады. Аларның барысының да чыгышлары көчле аргументлар белән ныгытылган иде, аңлаешлы, кирәк сүзләрне ишетүләрен тыңлап, рәхмәт әйтеп утырдым. Инде бу кадәр кыерсытуларга күпме түзәргә була дигән кыяфәттә, ярсып әйтелгән сүзләр дә булды. Турыдан-туры «мин каршы» һәм «мин йөрәгем кушканча сайлыйм» дип әйтүчеләр бар иде. Бер илдә дә, ил җитәкчесенең «Глава – рәис» дип аталганын ишеткәнем булмады, – дигән сүзләр яңгырады. Конституциядә бирелгән федерализм бармы бездә, хәзерге болгавыр чорда, гөрләп эшләп торган республикага каршы мәҗбүриләп кертелгән законнарның кирәге бармы безгә? – дигән фикерләр ишетелде. Шушы кадәр мәсхәрәләрдән соң без ничек итеп халык күзенә күренә алыйк, батыррак булырга кирәк безгә, чигенүләрнең дә чиге булырга тиеш, дигән сүзләр дә ишетелде депутатларыбыз авызыннан.

Соңыннан ясаган чыгышында Президент Миңнехановның без үзебезнең хокукларыбызне саклап кала алмадык, дип уфтанып әйтеп куйды. Йомшаклык өчен орышырга яратсак та, бу юлы мин хөрмәтле депутатларыбызга рәхмәтле калдым.

Рәфкать ИБРАҺИМ.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белђн киңәшү зарур!

4 февраль (шимбә). ***Рәҗәб аеның 13 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 17.37 сәгатьтә калка, 9.11 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 8.48 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Ай календаре

2-4, 25, 26 февраль - кыяр, кәбестә, борыч,баклажан, яшел тәмләткеч үләннәр, томат, берьеллык чәчәкләр чәчү өчен иң уңышлы көннәр. 5, 19, 20, 21 февральдә үсемлекләр чәчү, утырту, күчереп утырту тыела.

5 февраль (якшәмбе). ***Рәҗәб аеның 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 16.14 сәгатьтә калка, 8.58 сәгатьтә бата. 21 сәгать 28 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 8.53 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Яшьлек эликсиры

Эликсирны пыяла яки эмальләнгән савытта ясарга кирәк. 8-9 л лы савытка 1л кефир, 1 әр стакан бодай, арыш, солы, арпа, карабодай оннары салып, агач кашык белән болгаталар, өстенә тулганчы су салалар һәм тастымал белән каплыйлар. 3 көн әчетәләр, әледән-әле агач кашык белән болгаткалап торалар. Бифидок барлыкка килә, аны, ашар алдыннан, теләсә күпме эчәргә ярый. Мондый эликсир эчне йомшарта, шлакларны чыгара. Бигрәк тә бөерләрне яхшы чистарта. Әгәр 8-10 л күп булса, нормасын киметеп, 3 литрлы банкага гына да ясарга була.

6 февраль (дүшәмбе). ***Рәҗәб аеның 15нче көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 17.34 сәгатьтә калка, 9.11 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 8.57 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Чөгендер һәм суган сихәте

Югары температураны төшерергә кирәк булганда, чи чөгендер телемен табан астына куеп, өстеннән оекбаш кию җитә. Ә томау интектергәндә, баш суганны урталай кисәләр, шуны каш арасына, борын төбенә ышкыйлар. Колакларга кечкенә суган кисәкләрен тыгып, 20 минут торалар. Башланып кына килгән томау шундый 1-2 процедурадан соң соң ук бетәргә мөмкин.

7 февраль (сишәмбе). ***Рәҗәб аеның 16 нчы көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 18.56 сәгатьтә калка, 9.20 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.01 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Нарат кайнатмасы

Мондый кайнатма әзерләү өчен май аенда җыелган наратның яшь ботаклары кирәк. Аларны иттарткычтан чыгарып, шулкадәр үк шикәр кушалар һәм кайнаталар. Салкын тия башлагач ук, нарат кайнатмасы кабып, кайнар чәй эчсәң, иң кыйбатлы дарудан да яхшырак булыша, чөнки әлеге ылыслы агачта иммунитетны ныгыта торган файдалы матдәләр бик күп.

8 февраль (чәршәмбе). ***Рәҗәб аеның 17 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 20.10 сәгатьтә калка, 9.29 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.05 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Атеросклерозга каршы

Суганны вак угычтан уып, согын сыгалар да, 1 стакан сокка шулкадәр үк бал кушып, яхшылап болгаталар. Көненә 3 тапкыр, ашарга 1 сәгать кала яки ашаганнан соң 2-3 сәгать үткәч, 1 әр аш кашыгы кабалар. Болай дәвалану атеросклероз, бигрәк тә баш мие тамырлары склерозы вакытында килешә.

9 февраль (пәнҗешәмбе). ***Рәҗәб аеның 18 нче көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 21.33 сәгатьтә калка, 9.33 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.09 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь.

Колмак шифасы

Кан тамырларының варикоз киңәюеннән колмак булыша. 1 аш кашыгы вакланган колмак күркәсен 1 стакан кайнар суда 15 минут пешерәләр дә, көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, 1 әр стакан эчәләр. Колмак бераз йоклаткыч үзлеккә дә ия, шунлыктан йоклар алдыннан 1 стакан эчәргә дә ярый.

10 февраль (җомга). ***Рәҗәб аеның 19 нчы көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 22.55 сәгатьтә калка, 9.38 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 9.14 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

Ябыктыра торган аш

3 литр су, 4 бәрәңге, 1 әр суган һәм кишер, 1 стакан карабодай кирәк. Кайнап торган суга шакмаклап туралган бәрәңге салалар, 10 минуттан соң карабодай, уылган кишер, вак кына туралган суган, тоз өстиләр, 20 минут пешерәләр. Атнасына бер тапкыр көн буена шул ашны гына ашап торалар. Чәй һәм су эчәргә ярый, башка бернәрсә дә ашамаска кирәк. Болай ябыгу организмга зыян китерми.

Этне өйгә кертмәгез

Хәзрәти Гайшә радыйаллаһу ганһә сөйләгәннәрдән:

Җәбраил галәйһис-сәлам Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына билгеле бер сәгатьтә килергә вәгъдә итә. Әйтелгән вакыт җитә, ләкин Җәбраил галәйһис-сәлам килми. Рәсүлуллаһ кулындагы таякны җиргә ташлый да: «Аллаһ та, Аның рәсүлләре дә вәгъдәсеннән тайпылмас!» – дип әйтә. Аннары тирә-ягына карана башлый һәм сәкесенең астында бер көчекне күреп ала! Шуннан соң Ул: «Әй, Гайшә! Бу көчек кайчан керде монда?» – дип аваз салды. Мин: «Аллаһ белән ант итәм, белмим», – дидем. Аның әмере белән көчекне алып чыгып киттеләр. Шундук Җәбраил галәйһис-сәлам дә килә.

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Миңа сүз бирдең, мин көттем, тик син килмәдең», – ди. Җәбраил галәйһис-сәлам: «Миңа өегездәге эт комачаулады. Без, фәрештәләр, эчендә эт һәм сурәт булган йортка кермибез», – дип җавап бирә (Мөслим, «Либас», 81; Бохари, «Бәдгуль-халк», 7; «Либас», 94; Ибне Мәҗә, «Либас», 44).

Бу хәдис-шәрифтә «эт» белән бергә искә алынган «сурәт» бары рәсемне генә күздә тотмый. Аңа җан ияләренең сыннары яки барельеф кебек кабартып ясалган сурәтләре дә керә. Рәсем исә бер шәүләнең проекциясе кебек, аның күләме юк. Шул ук вакытта «сурәт» сүзе һәртөрле җан иясенең рәсемен колачлаган төшенчә буларак каралган очракта да, бу хактагы тыюның, потларга табыну чорының якынлыгы сәбәпле, барлыкка килүен дә күзалларга мөмкин.

Икенче яктан караганда, хәзерге заманда рәсем һәм фотографияләрнең көндәлек тормышта кулланылыш мохите киңәюе һәм кайбер очракларда зарури ихтыяҗга әверелүе билгеле. Динамик структурага ия ислам дине заман дәвамында зарурият дәрәҗәсенә күтәрелгән мондый төр ихтыяҗлар өчен билгеле бер канун-кагыйдәләр чиге билгеләп, сурәт һәм фотографияләр куллануга рөхсәт бирә.

Сүз уңаеннан, шуны да искә алып үтик: югарыдагы хәдис-шәрифтә белдерелгәнчә, эчендә эт булган өйгә фәрештә кермәве дә мөһим хикмәткә ишарәли. Бөек ислам динебез өй эчендә эт асрауны тыя, чөнки этнең сулышы һәм селәгәе нәҗес санала. Этләрнең селәгәеннән, йоннарыннан һәм хәтта сулышларыннан төрле йогышлы авырулар килеп чыкканлыгы хәзерге заманда шик уятмый торган фәнни факт булып тора. Өстәвенә болар – фәннең бүгенге ирешелгән дәрәҗәсендә раслана ала торган хакыйкатьләр. Исламның бу мәсьәләдәге чик-үлчәмнәренең әле ачыкланмаган күпме хикмәте барлыгын һичкем белмәс.

Хәдис-шәрифтә әйтелгәнчә, өйгә очраклы рәвештә кергән бер көчек аркасында Җәбраил галәйһис-сәлам Пәйгамбәр Әфәндебез галәйһис-салату вәс-сәлам янына килә алмаган. Бернинди сәбәпсез, үз ихтыярлары белән эт асраган өйләрнең хәлен уйлап карагыз! Рәсүл Әкрәмнең Хәзрәти Гайшәгә: «Бу көчек кайчан керде монда?» – дип соравы һәм аның: «Валлаһи, белмим», – дип ант итеп җавап бирүе дә бер мөселманның өендә эт тотуы турында сүз дә булырга мөмкин түгеллеген күрсәтә. Бу вакыйга да бер сәбәпсез түгел, ә мөэминнәр өчен бер хөкемнең ачыклану хикмәтенә нигезләнеп чынга аша.

Песи – йортка ияләшкән хайван, аның өйдә яшәвенә карата ниндидер тыю юк, әммә өйдә эт асрау рөхсәт ителми. Ә аучылык, көтүчелек, йорт-җир, бакчаларны саклау өчен эт асрау тыелмый, ләкин анысы да йортка кертмичә генә. Чөнки бу очракта эт билгеле бер ихтыяҗны канәгатьләндерә.

Чыннан да, Җәнабел-Хак этне кешегә буйсындырган һәм аны бик күп хайваннардан аермалы буларак, хуҗага тугрылык сыйфатына ия җан иясе иткән. Өстәвенә, аңа бик күп заманча приборлар да ия булмаган искиткеч сәләтләр бирелгән. Әйтик, бүген наркотик эзләү яки хәрабәләр, җимерекләр астында калган кешеләрне табу өчен кулланылган этләр, йорт-җир, бакчаларны саклау хезмәтенә өстәмә рәвештә, кешеләрнең саулыгын-иминлеген саклау өлкәсендә дә гаҗәп әһәмиятле хезмәтләр башкара.

Бүген, аеруча Көнбатыш илләрендә, гаилә институты бик еш таркала һәм кешеләр ялгыз гомер кичерә башлый, шунлыктан алар, караклардан һәм башка күңелсез хәлләрдән саклану өчен, өйдә эт асрый. Өстәвенә, күп кенә Көнбатыш илләрендә өйдә асралган этләр мәҗбүри рәвештә иминиятләштерелергә тиеш. Этләрен ашату-эчертү чыгымнарына иминиятләштерү чыгымнары да өстәлә, ләкин кешеләр аларны түләүдә юмарт кыланып, һич авырсыну сиздерми, ә менә җәмгыятьтәге фәкыйрьләргә карата андый юмартлык күрсәтелми. Аларның бик күп мәшәкатьләрне һәм чыгымнарны күздә тотып, өйдә эт асравы вакыт узу белән, этнең дә, аның хуҗасының да холкын боза. Чөнки эткә артык игътибар күрсәтү аны гаиләнең бер әгъзасы дип кабул итү дәрәҗәсенә җитә. Мондый чиктән ашулар хәтта вакыт-вакыт үз балаңның да арткырак планга калуына килеп җитәргә мөмкин. Моның иң куркыныч нәтиҗәсе исә эгоистлыкның үсеп-нығып, балага күрсәтелергә тиешле мәхәббәтнең эткә юнәлтелүе аркасында бала тәрбияләү, бала үстерү теләгенең сүрелүеннән гыйбарәт. Хәзерге заманда күп кенә Көнбатыш дәүләтләрендә халык саны артасы урында кими бара. Өстәвенә, өйдә эт асрау – эткә карата да ниндидер игелек, аны яклау ысулы түгел, киресенчә, бер яктан караганда, ул үз яратылышына ят шартларда яшәргә мәҗбүр ителә.

Көнбатыш халкының мондый мөнәсәбәте никадәр куркыныч адашу һәм гаилә институтын җимерү дигән сүз. Ни кызганыч, соңгы вакытларда безнең җәмгыятебездә дә күзәтелә башлаган өйдә эт асрау гадәте Көнбатышка сукырларча иярүнең тискәре чагылышы.

Исламның өйдә эт асрау мәсьәләсендәге тыюы бу хайванга карата тискәре мөнәсәбәттә торуны таләп итми, ягъни этләрне асрамаска, ашатмаска яки аларга карата начар мөгамәләдә булырга дигән сүз түгел. Киресенчә, ислам мәрхәмәт хисен бөтен мәхлукларга җитәрлек рәвештә сеңдергәнгә күрә, башка мәхлуклар белән беррәттән, этләргә дә мәрхәмәтле мөнәсәбәт булдырырга куша.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Җәбраил галәйһис-сәләмнән: «Ягъкубның Йосыфны сагынып кайгыруы нинди дәрәҗәгә җиткән иде?» – дип сорый. Җәбраил галәйһис-сәләм: «Баласын югалткан җитмеш ананың барысының бергә сагыш-кайгысы кадәр дәрәҗәгә!» – дип җавап бирә. Шуннан соң Хәзрәти Пәйгамбәр: «Ул очракта моның савабы никадәр?» – дигән сорау бирә. Җәбраил галәйһис-сәләм: «Йөз шәһидлек савабы, чөнки ул Аллаһ турында бер мизгелгә генә дә начар уйлап карамады», – дип белдерә (Суюти, «әл-Дүррүл-Мәнсур»).

Димәк, кичергән кайгы-җәфалар, беренче карашка, тормышта сөенечкә, бәхеткә аркылы төшкән киртә булып тоелса да, чынлыкта алай түгел. Сабыр итү һәм Аллаһтан килгән сынау-бәлаләргә ризалык белдерү тиешлеген белүчеләр өчен андый авырлыклар тагын да зуррак сөенечләргә ирешү чарасы булып тора.

Бәясе төрле

Диванда бабай дини китап укып утыра. Оныгы Сабир бабасын бик ярата, аның янына килеп сырпаланып сорый:

– Бабай, әйт әле миңа, кешеләр кемне югарырак бәяли: күп сөйләүченеме, әллә аз сөйләүченеме?

Бабасы ипләп кенә китабын ябып, югарырак җиргә – шүрлеккә куя һәм оныгы Сабирга болай ди:

– Иртәдән кичкә кадәр бакалар сазлыкта бакылдый. Аларга берәү дә игътибар итми. Ә менә иртә таңнан кычкырган этәчне барысы да тыңлый. Аны ишетеп кешеләр юынып намаз укый, үз эшләрен башлап җибәрә. Әгәр әйтер сүзең юк икән, тын гына утыр...

Бәхет

Дөнья буйлап сәяхәт кылганда, Бәхет кемдер казыган тирән чокырга килеп төшә. Төрлечә маташып караса да, чыга алмый газапланa. Узган-барганнар, аның янына килеп, үз теләкләрен үтәвен сорый. Үтәлгәч исә, чокырдагыны коткарырга онытып китеп баралар.

Чокыр янына яшь егет килә. Бу хәлдән коткаруны сораган Бәхеттән берни сорамый, аны тартып чыгара һәм юлын дәвам итә. Ә Бәхет... Бәхет аның артыннан калмый...

Зур гөнаһ эшләгәнсең

Урамда Фасыйк исемле бер бала чыпчыкларга таш атып уйный иде. Инде күпме ыргыта, берсе дә егылып төшми, тидерә алмый. Алар йә өй кыегына, йә очып читтәгә куналар... Шунда ул юл кырыеннан баручы кечкенә кызны күрде. Чәчләрен ике толым итеп үргән, башында гади генә яулык, арзан ситсыдан тегелгән күлмәк кигән кулында бер бит язылган кәгазь һәм буш кәрзин...

Фасыйк таныш булмаган кызга якын килеп, кәгазьдәге зур хәрефләр белән язылганны укыды; анда «әнием авырып ята, ашарыбызга берни дә юк, Алалаһ хакы өчен бер телем икмәк бирә алмассызмы?», – дигән сүзләр язылган иде. Малай кызга карады һәм:

– Сиңа, хәерче кыз, ипи кирәкме, кәрзинеңне суз, – дип кесәсеннән чүпрәккә төрелгән ташларны кәрзингә куйды.

Яланаяклы кыз кәрзинен күтәреп, тузанлы юлдан китеп барды.

Фасыйк өенә кайтты, бабасы намаз укып утыра иде. Менә ул гыйбадәтен тәмамлады. Оныгы бабасы янына килеп үзе белән булган "кызыклы" вакыйганы сөйли башлады.

– Бүген мин бер кечкенә хәерче кызны оста итеп алдадым, – диде малай.

Бабасы аны тыңлап бетерде һәм оныгына:

– Улым, син зур гөнаһ эшләгәнсең. Беренчедән, кешене алдагансың. Икенчедән, син ул кызның авыру, ач әнисенә булышу өчен икмәк соравын белгәнсең. Өченчедән, син аны әле «хәерче» дип мыскыл иткәнсең, – диде.

Бабасы торып өстәл янына барды һәм түгәрәк икмәкне күкрәгенә терәп кисеп яртысын оныгына бирде һәм:

– Бар, тиз арада ул кызны тап, әнисенә ташлар күрсәткәнче, үзеңә фәрештәләр гөнаһ язып куйганчы, бу икмәкне бир, авыру әнисе терелсен, ач ятмасын, – дип чүпрәккә төрелгән ярты икмәкне оныгына сузды.

Фасыйк урамга йөгереп чыкты, тик кечкенә кыз гына күренмәде. Бабасының сөйләгәннәреннән соң, малай нинди ялгышлык эшләгәнен аңлады, аның күзләреннән яшьләр акты. Кызны эзләү уңышсыз тәмамланды...

Фасыйк тиз генә йоклап китә алмады, черем итеп алды да, күз алдына үзен җәзалар өчен килгән фәрештәләрнең кайнап торган тәмуг чокырына өстерәп барганнарын күрде. Сискәнеп, куркып уянды, күзенә йокы кермәде...

Икенче, өченче көнне дә Фасыйк ярты икмәкне тотып кызчыкны эзләде... Уңышсыз... Малай хәзер үзен калебендә авыр таш йөрткән кебек хис итә иде...

Бабасы вафат булганнан соң да малай һәр көнне үзе белән ярты ипине алып йөртте... Малайның тилереп башлаган эше аның җан тынычлыгын алды...

Кытыршы куллы кыз

Әти кешенең ике кызы үсә. Әмма ул өлкән кызын кечесенә карата күбрәк ярата. Өлкәненең бит алмалары алсурак, тиресе йомшак, тавышы матур, чәчләре бөдрә.

– Син шундый назлы, бакчадагы гөлчәчәк кебек, – ди аңа әтисе, кызына карап туя алмыйча.

Кече кызы гади генә үсә, матурлыгы да уртача, куллары да кытыршырак, йомшак түгел, үзен дә тыйнак кына тота. Өйдә дә ул бик күп эшли: керләр дә юа, аш та пешерә, башка хатын-кыз эшләрен дә башкара, чөнки биш-алты ел элек әниләре авырып вафат була.

Бакчада да кече кызы әтисенә булыша, түтәлләр казый, яшелчәләр утырта. Өлкән кызы горурланып, чәчәк иснәп йөри, эшләсә кулы катылана бит... Әтисенең яраткан шөгыле бар, ул ауга йөрергә ярата. Кыр үрдәкләре, куяннар алып кайта.

Беркөнне ауга киткән әтисе вакытында кайтмый. Өлкән кызы өйдә юк, кече кызы полициягә шылтырата, коткаручыларны аякка бастыра. Әтисен кичен табып, район хастаханәсенә салалар. Фаҗига уйламаганда килеп чыккан. Патрон куям дигәндә, мылтык аның кулында шартлаган. Кулы, бите, күзе җәрәхәтләнгән.

Шул көннән кече кызы әшеннән гариза язып, үз хисабына ике ай ял ала. Беренче көннән үк хастаханәдә саклап куна, әтисенә тиешле булышлыклар күрсәтә. Өлкән кызының «мөһимрәк» эше килеп чыга, «килә алмыйм» дип кенә хәбәр бирә.

Һәр көнне табибә яраларын эшкәртә, аннары яңадан бәйләп куя. Әтисе үзе генә ашый алмый, кулы кашык тотмый. Кече кызы өйдән пешереп килеп, көн саен әтисен ашата.

– Барысы да әйбәт булыр, әтием, – дип юата кызы, терелгәнче синең кулың һәм күзләрең мин булырмын, – ди.

Хәлләре яхшыра баргач, йөри ала башлагач, әтисен өйләренә кайтарырга рөхсәт бирәләр. Өендә дә барлык эшләрне кече кызы башкара. Әтисенең битен, кулларын эшкәртә.

Ниһаять, әтисенең күзләрен бәйләгән марляны алалар, ул якты дөньяны кабат күрә башлый. Әтисе кайвакыт өлкән кызыннан янында утырып торуын сорый, әмма кызының вакыты юк, бакчага хозурланырга чыга, үзенә башка шөгыль таба. Шактый савыкканнан соң, әтисе ике кызын да янына утырта. Аннары кече кызын кочаклап:

– Мине ташламаганың өчен рәхмәт, кызым. Синең кулларың шундый йомшак икәнлеген элегрәк белмәгән идем, – ди әтисе.

– Минем кулларым аныкына караганда йомшаграк бит, – ди өлкән кызы.

– Авырып яткан вакытта шуны аңладым: кулның йомшаклыгы тире йомшаклыгы белән түгел, ә йөрәкнең шәфкатьлелеге һәм мәрхәмәтлелеге белән билгеләнә икән, – ди әтисе.

Нияз БИШБАЛТА әзерләде.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

3 февраль – 17.00 Шәрык клубында – «Гөлҗамал» (Н.Исәнбәт). 19.00 – «Дон Жуан» (Ж.-Б. Мольер).
4 февраль – Зур залда – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин). Кече залда – «Киек каз юлы» (И.Мөхәммәтгалиев).
5 февраль – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).
7 февраль – «Томан» (Г.Сәгыйтова).
8 февраль – «Сөясеңме, сөймисеңме...» (Ф.Бүләков).
9 февраль – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
10 февраль – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

30 гыйнвар – 28 февраль – Ф.Шаляпин исемендәге XLI халыкара опера фестивале:
3 февраль – «Тоска» (Дж.Пуччини).
4 февраль – С.Сәйдәшев исемендәге дәүләт зур концерт залында – «Йөрәктә мәхәббәт һәм моң» дип исемләнгән камера музыкасы концерты.
6 февраль – «Пиковая дама» (П.Чайковский).
8 февраль – «Мадам Баттерфляй» (Дж.Пуччини).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

3 февраль – «Мәдинә» (И.Зәйниев).
4 февраль – «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов).
5 февраль – «Кияүләр» (Х.Вахит).
7 февраль – «Назлы кияү» (К.Тинчурин).
8 февраль – «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин).
9 февраль – «Идегәй».
10 февраль – «Хыялый» (С.Әбүзәров).

МӘК тамаша заллары чакыра

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

3 февраль – «Мио, минем Мио!» (А.Линдгрен).
4 февраль – «Арыну» (Т.Кулов, А.Әхмәдиев).
7 февраль – «12 адым».
8 февраль – «Яратып туялмадым» (А.Әхмәтгалиева).
9 февраль – «Гөлчәчәк».
10 февраль – «Йосыф» (Кол Гали).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

3 февраль – Премьера. «Аладдин».
4 февраль – зур залда – «Аладдин». Кече залда – «Кыш бабай бүләкләре» (Н.Абрамцева).
5 февраль – Фойеда – «Идет коза рогатая» (М.Протасова). Зур залда – «Приключения Чебурашки» (Э.Успенский әсәре, В.Фечин инсценировкасы).
7 февраль – Фойеда – «Добрый день!» (Н.Егорова). Зур залда – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь).
8 февраль – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әсәренә нигезләнеп куелган).
9 февраль – «Буратино» (А.Толстой).
10 февраль – 11.00 – «Буратино» (А.Толстой). 19.00 – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

3 февраль – «Мастер и Маргарита» спектакле.
4 февраль – Күренекле җырчы Лидия Әхмәтованың юбилей кичәсе.
9 февраль – Татарча солянка.
10 февраль – Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбленең осталык дәрес-концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

10 февраль – «La Primavera» Казан камера оркестры концерты.

Телне йотарлык тәмле

Хәзер нинди генә ризык юк! Ашарга пешерүчеләр һәм ашамлык җитештерүчеләр берсеннән-берсе уздырып төрле деликатес уйлап таба. Сербиядә исә дөньяда иң кыйбатлы сыр җитештерелә, аның килограммы 1200 доллар тора. Pule сыры Балкандагы экологик чиста болында үрчетелүче ишәк сөтеннән ясала. Ап-ак төстәге һәм бик тәмле сырның бер килосын ясауга 22 литр сөт китә. Җитештерүчесе әйтүенчә, сыр сәламәтлек өчен дә бик файдалы. Ул шулай ук ишәк сөтен шешәләргә тутырып та сата – борынгы риваятьләр буенча, гүзәллеге белән тарихка кергән Мисыр патшабикәсе Клеопатра нәкъ менә ишәк сөтендә коена торган була.

(“Die Presse”).

Чүлгә чумган шәһәр

Матмата – Тунисның көньягындагы бик үзенчәлекле шәһәр. Анда йортлар җир астындагы комлы токымнарны уеп ясалган. Түгәрәк кое-кратер төбеннән җир астындагы бүлмәләргә керепкитәсең. Атаклы кинорежиссер Джордж Лукас бу уникаль ландшафтны күреп таң калган һәм үзенең данлыклы “Йолдызлар сугышы” фильмындагы Татуин планетасын шунда төшергән. Лукас үз геройларына биредә яшәүчеләрнең традицион киемен – капюшонлы авыр йон җиләнне дә кидергән. Җир куышындагы “Sidi Driss” кунакханәсе баш герой Люк Скайуокерның йортына әйләнгән. Матматага махсус шул йортны карар өчен әллә кайлардан туристлар килә. Җирле халык сәяхәтчеләр хисабына көн күрә дә инде. Хәзер аларның күбесе Яңа Матматада, эссе бетон йортларда яшәп азаплана, чүлдә казылган уңайлы йортларын исә билгеле бер хакка туристларга күрсәтеп акча эшли. Биредә эсселек 45 градустан кимеми, шунлыктан җир астындагы йортлар яшәү өчен иң уңайлысы – аларда һәрвакыт бер төрле җылы һава саклана. Мондый мәгарә тораклары комлы токымнарда 400 ел чамасы элек чокып ясалган, алар 5 меңләп кешене сыйдыра алган. Бүлмәләр тирәнлеге 7 метрлы, диаметры 10 метрлы вертикаль коелар тирәсендә уелган.

(“Интересно.cc”).

Тиз арада бетмәячәк

Нефть ясалуга кагылышлы ике теория инде 130 ел буе мәгълүм булса да, галимнәр барыбер, әлеге файдалы казылма запаслары тагын 30-40 елдан соң бетәчәк, дип фаразлый иде. Беренче теория буенча нефть – яңартылмый торган органик ресурс, ул борынгы флора һәм фауна калдыклары катнашында ясала. Альтернатив теория исә аны табигатьтәге су әйләнеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән яңартыла торган ресурска саный. Россия Фәннәр академиясенең Нефть һәм газ проблемалары институты белгече Азарий Баренбаум фикеренчә, беренче теория бөтенләй дөрес түгел. Атмосферага эләккән углерод яңгыр сулары белән гидрокарбонат сыйфатында кабат җиргә төшә. Җир кабыгында углерод туплану белән бер үк вакытта мантиядән куәтле водород агымнары бүленеп чыга. Югары температура һәм басым астында химик реакцияләр бара, нәтиҗәдә газлар, шул исәптән метан һәм тамчылы нефть ясала. Һәм иң гаҗәбе шул, әлеге процесс миллионнарча түгел, бәлки берничә дистә ел эчендә генә бара. Галим фикеренең дөреслеген дәлилләгән мисалларның берсе – Татарстан. Биредә нефть табыла башлагач, аның запасы 709 миллион тонна, дип фаразлаганнар. Әмма бүген Татарстанда инде моннан дүрт тапкырга артыграк – 2,7 миллиард тонна кара алтын чыгарылган, һәм якын киләчәктә генә бетәргә җыенмый да әле... Әгәр нефть һәм газ чыннан да яңартыла торган ресурс булып чыкса, бу бер дә гаҗәп түгел. Алар – табигать табышмагы. Химик составлары билгеле, чыгару ысуллары даими камилләшә бара, әмма менә ясалу тарихы һаман билгесез. Тагын шунысы да игътибарга лаек: Россиядәге нефть запасы турында төгәл мәгълүмат юк. Газ запаслары билгеле, ә менә кара алтын күләме совет чорыннан бирле сер итеп саклана. Тагын бер фикер дә бар: янәсе, Җирдәге нефть күләме, паника тудырмас һәм бәяләрнең чамадан тыш кыйбатлануын булдырмас өчен, аңлы рәвештә арттырып күрсәтелә. Геологлар әлеге файдалы казылманың чынлыкта күпмегә җитәсен белми, ә сәясәтче һәм эшкуарлар әлеге саннарны үзләренә кирәкле максатларда йә арттырып, йә киметеп файдалана. Әмма шуны ышанып әйтергә була: безнең гасыр азагына кадәр нефть тә, газ да бетмәячәк әле.

(“Лента.ру”).





Леонардо кодексы

Бөек итальян рәссамы һәм мәгърифәтчесе Леонардо да Винчи турында белмәгән кеше юктыр ул бу җиһанда. Әлеге даһиның кайчандыр кулы тигән бөтен нәрсә легендага әйләнеп барган. Атаклы рәссамның “Лестер кодексы”, яки “Су, җир һәм күк җисемнәре турында трактаты” исә – дөньяда иң кыйбатлы китап. Чынлыкта гади генә дәфтәрне хәтерләткән әлеге кодекска Леонардо Миланда яшәгән чагында – 1506 елдан 1510 елга кадәр дөнья төзелеше турында язмаларын теркәп барган. Трактат 18 пергаменттан гыйбарәт, аларны бөкләгәч, 72 аерым бит килеп чыга. Леонардо китабында киләчәк буыннарга мөрәҗәгать итә, аларга әйләнә-тирә дөньяның төзелешен, табигать күренешләрен үзенчә аңлата. Тулаем алганда, даһи дөньяны бердәм тере организм итеп күзаллый, анда һава – җан, җир – тән, су исә кан ролен уйный. Уникаль көзгеле шрифт белән язылган китапны битләренә көзге терәп куеп кына укып була. Анда автор ясаган иллюстрацияләр бик күп. 1717 елда да Винчи язмаларын борынгы инглиз нәселе варислары – Лестерлар сатып ала, кодекс шулар исеме белән атала башлый. Соңрак китап нефть магнаты Арманд Хаммер кулына эләгә, 1994 елда исә ул Christie’s аукционында 30,8 миллион долларга планетаның иң бай кешеләреннән берсе Билл Гейтска сатыла. Шул вакыттан бирле яңа хуҗасы “Су, җир һәм күк җисемнәре турында трактатны” әледән-әле дөньяның иң зур музейларындагы күргәзмәләрдә күрсәтә.

(“The Guardian”).



Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

6 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 23.00 «КЛЮЧ К ЕГО СЕРДЦУ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ДИГӘН ЯЗМЫШ». 12+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
23.50 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ». 16+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.05, 22.05 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЭКСПРОПРИАТОР». 16+
11.30 «ГЮЛЬЧАТАЙ». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЗАМОК ИЗ ПЕСКА». 12+
15.00 «Земля людей». 12+
15.30 «История нравов». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ПРОБУЖДЕНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб. 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ. ЮБИЛЕЙНЫЙ СЕЗОН». 16+
23.25, 0.55 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Михаил Пришвин.
7.40 «Дуэлянтки».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.30 «СЕМЬЯ ЗАЦЕПИНЫХ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Творческий вечер Николая Сличенко».
12.20 Цвет времени. Микеланджело Буонарроти. «Страшный суд».
12.30, 22.10 «ЖИЗНЬ ВЕРДИ».
14.05 Линия жизни. Анна Якунина.
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
17.40 Шедевры симфонической музыки. П.И. Чайковский. Симфония №5.
18.35 «Секреты древних мегаполисов. Александрия».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Поднебесная Иакинфа Бичурина».
21.25 «Сати. Нескучная классика...»

«НТВ»

4.50 «ДЕМОНЫ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЧУЖАЯ СТАЯ. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ». 16+
22.00, 0.00 «ДУШЕГУБЫ». 16+

Сишәмбе

7 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 23.00 «КЛЮЧ К ЕГО СЕРДЦУ». 16+
11.00 «Азбука долголетия». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ДИГӘН ЯЗМЫШ». 12+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Ючлы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
15.15 «Төймә».
16.00 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Таяну ноктасы». 16+
19.30 Хоккей. «Нефтехимик» - «Ак Барс».
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ». 16+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЭКСПРОПРИАТОР». 16+
11.30 «ГЮЛЬЧАТАЙ 2». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЗАМОК ИЗ ПЕСКА». 12+
15.00 «Земля людей». 12+
15.30 «История нравов». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ПРОБУЖДЕНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб. 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ. ЮБИЛЕЙНЫЙ СЕЗОН». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.30 «Секреты древних мегаполисов. Александрия».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.30 «СЕМЬЯ ЗАЦЕПИНЫХ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Путь к роли. Игорь Костолевский, Николай Караченцов».
12.20 Цвет времени. Жан Этьен Лиотар. «Прекрасная шоколадница».
12.30, 22.10 «ЖИЗНЬ ВЕРДИ».
14.00 «Первые в мире».
14.20 Иностранное дело.
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Передвижники. Илья Репин».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
17.45 Шедевры симфонической музыки. Д. Шостакович. Симфония №5.
18.35 «Секреты древних мегаполисов. Афины».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.25 «Белая студия».

«НТВ»

4.55 «ОПЕРЕТТА КАПИТАНА КРУТОВА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЧУЖАЯ СТАЯ. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ». 16+
22.00, 0.00 «ДУШЕГУБЫ». 16+

Чәршәмбе

8 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 23.00 «КЛЮЧ К ЕГО СЕРДЦУ». 16+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ДИГӘН ЯЗМЫШ». 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.15 «Туган авылым». 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00, 0.40 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Спортивная среда». 6+
23.50 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
9.40 «Йөрәктән-йөрәккә». Илтани Илялова турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ». 16+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.00, 22.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.30 «Ючлы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЭКСПРОПРИАТОР». 16+
11.30 «ГЮЛЬЧАТАЙ 2». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЗАМОК ИЗ ПЕСКА». 12+
15.00 «Земля людей». 12+
15.30 «История нравов». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ПРОБУЖДЕНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб. 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ. ЮБИЛЕЙНЫЙ СЕЗОН». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.30 «Секреты древних мегаполисов. Афины».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.35 «ЕДИНСТВЕННЫЙ МУЖЧИНА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Встреча в концертной студии «Останкино» с экс-чемпионом мира по шахматам Михаилом Талем».
12.25 Цвет времени. Карандаш.
12.30, 22.10 «ЖИЗНЬ ВЕРДИ».
13.35 «За науку отвечает Келдыш!»
14.20 Иностранное дело.
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.40 Шедевры симфонической музыки. В.А. Моцарт. Концертная симфония для скрипки и альта.
18.35 «Секреты древних мегаполисов. Рим».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.25 Власть факта. «Христианство в Римской империи».
23.10 «Азербайджан. Баку. Дом Мухтарова».

«НТВ»

4.55 «ОПЕРЕТТА КАПИТАНА КРУТОВА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЧУЖАЯ СТАЯ. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ». 16+
22.00, 0.00 «ДУШЕГУБЫ». 16+

Пәнҗешәмбе

9 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00, 23.00 «КЛЮЧ К ЕГО СЕРДЦУ». 16+
11.00, 0.40 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ДИГӘН ЯЗМЫШ». 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Рыцари вечности». 16+
14.45 «Над полями, льдами и лесами...» 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 16+
18.00 «Ючлы». 16+
19.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Амур».
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 16+
0.15 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Мин кайтырмын сезгә яңадан». Фәнис Яруллин турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ». 16+
15.30 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ЭКСПРОПРИАТОР». 16+
11.30 «ГЮЛЬЧАТАЙ 2». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЗАМОК ИЗ ПЕСКА». 12+
15.00 «Земля людей». 12+
15.30 «История нравов». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «ЧУЖАЯ КРОВЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ПРОБУЖДЕНИЕ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб. 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ. ЮБИЛЕЙНЫЙ СЕЗОН». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.30 «Секреты древних мегаполисов. Рим».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.35 «ЕДИНСТВЕННЫЙ МУЖЧИНА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Слово Андроникова. «Тагильская находка».
12.30, 22.10 «ЖИЗНЬ ВЕРДИ».
13.35 100 лет со дня рождения Михаила Курилко-Рюмина. Эпизоды.
14.20 Иностранное дело.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Пряничный домик. «Отважный народ суровых гор».
15.45 «2 Верник 2».
17.50 Шедевры симфонической музыки. Р. Шуман. Симфония №1 «Весенняя».
18.35 «Секреты древних мегаполисов. Тикаль».
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Андрей Убогий. «Моя хирургия».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «31 июня». Всегда быть рядом не могут люди».
21.30 «Энигма. Альфонсо Айхон».
23.20 «Забытое ремесло».

«НТВ»
4.55 «ОПЕРЕТТА КАПИТАНА КРУТОВА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЧУЖАЯ СТАЯ. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ». 16+
22.00, 0.00 «ДУШЕГУБЫ». 16+
0.20 «Поздняков». 16+

Җомга

10 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «АЛМАШ». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 16+
18.00 «Туган җир». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ючлы». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «К ЧУДУ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 16+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30 «Казаннан казанга». 16+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20 «Йөрәктән - йөрәккә». Рәфкать Бикчәнтәев турында телеочерк. 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.05 «Туган җир». 12+
19.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+
21.25 Спектакль «Алдым-бирдем». 16+

«ЭФИР»
1.45 «Молодая наука». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУЖАЯ КРОВЬ». 16+
11.30 «ГЮЛЬЧАТАЙ 2». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ПОСЛЕДНЕЕ ИСПЫТАНИЕ». 16+
15.15 «Земля людей». 12+
15.45 «Прокуроры 5. Без срока давности. Эшелоны смерти». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Голос. Дети».
23.25 «КАНИКУЛЫ В АФРИКЕ». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+
23.55 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.30 «Секреты древних мегаполисов. Тикаль».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.50, 16.35 «А ПАРОХОДЫ ГУДЯТ И УХОДЯТ...»
10.15 «Котильонный принц».
11.10 «КАПИТАНСКАЯ ДОЧКА».
12.50 Открытая книга. Андрей Убогий. «Моя хирургия».
13.20 Линия жизни.
14.20 Иностранное дело.
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Альфонсо Айхон».
16.20 «Первые в мире».
17.40 Шедевры симфонической музыки. А. Дворжак. Симфония №7.
18.45 «Билет в Большой».
19.45 Искатели. «Загадка «Дома под рюмкой».
20.30 Линия жизни. Владимир Рецептер.
21.25 «ПИКОВАЯ ДАМА».
22.55 «2 Верник 2».

«НТВ»
4.55 «ОПЕРЕТТА КАПИТАНА КРУТОВА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МЕДВЕЖИЙ УГОЛ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ЧУЖАЯ СТАЯ. НЕВИДИМЫЙ ВРАГ». 16+
22.00 «ДУШЕГУБЫ». 16+

Шимбә

11 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Ялт-йолт». «Мунча ташы» эстрада театры тапшыруы. 16+
17.05 «Пар алма». Илназ Бах. 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит- шоу». 16+
23.00 «МАФИЯ. ИГРА НА ВЫЖИВАНИЕ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 23.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Илдар Кыямов турында телеочерк. 16+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Кайда сез, яшьлек еллары». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 6+
17.10 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Гомер чишмәм». Рәсим Низамов концерты. 6+
23.50 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ». 16+

«ЭФИР»
5.15 «Молодая наука». 12+
5.30 «БИНДЮЖНИК И КОРОЛЬ». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты». 6+
8.00, 14.50 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
8.15 «НОВАЯ ЖИЗНЬ МАШИ СОЛЁНОВОЙ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ВУНДЕРКИНДЫ». 12+
15.00 «Фортуна. Ловушка для счастливчика». 12+
15.45 «АНДРЕЙКА». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ЗА МЕЧТОЙ». 12+
22.35 «ИНДИЙСКОЕ ЛЕТО». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «ПроУют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 К 95-летию Вячеслава Тихонова. «Разговор по душам». 12+
13.15, 18.20 «СЕМНАДЦАТЬ МГНОВЕНИЙ ВЕСНЫ». 12+
19.00 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 К 100-летию отечественной гражданской авиации. Праздничный концерт в Кремле. 12+
23.40 «Дамир вашему дому». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00 «Доктор Мясников». 12+
13.05 «ВРЕМЯ ДОЧЕРЕЙ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «МОРЕ. СОЛНЦЕ. СКЛИФОСОВСКИЙ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.50 «ПИКОВАЯ ДАМА».
9.20 «Мы - грамотеи!»
10.00 «МОЛОДАЯ ГВАРДИЯ».
11.25 «Забытое ремесло».
11.40 «Передвижники. Илья Репин».
12.15 Черные дыры. Белые пятна.
12.55 «Эффект бабочки».
13.25 «Эйнштейны от природы».
14.15 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.15 «Усадьба Марфино. Советский Голливуд».
15.55 Спектакль «Спешите делать добро».
17.55 «Казань. Дом Зинаиды Ушковой».
18.25 85 лет Евгению Сидорову. Линия жизни.
19.25 «КРЕСТНЫЙ ОТЕЦ. КОДА: СМЕРТЬ МАЙКЛА КОРЛЕОНЕ».
22.00 «Агора».
23.00 «СТО ДНЕЙ ПОСЛЕ ДЕТСТВА».

«НТВ»
4.50 «СТАЖЁРЫ». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 Научное расследование Сергея Малозёмова. 12+
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.25 «Секрет на миллион». 16+
23.30 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

12 февраль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Сынатмый яшик!» Илсур Сафинның юбилей кичәсе. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан - ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Пар алма». Илназ Бах. 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Гомер - татлы мизгел». Раяз Фасихов концерты. 12+
15.00 «Әниемнең жылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ДЕСЯТЬ НЕГРИТЯТ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Башмагым». Музыкаль комедия. 12+
9.30, 15.20 «Йөрәктән-йөрәккә». Газинур Фарукшин турында телеочерк. 16+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп ейрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Ничек сезнең хәлләрегез?» Зәйнәб Фәрхетдинова концерты. 16+
16.20, 21.10 «Әниемнең жылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
22.00 Спектакль «Гаугалы гаилә». 16+

«ЭФИР»
5.15 «Молодая наука». 12+
5.30 «БИНДЮЖНИК И КОРОЛЬ». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты.». 6+
8.00 «Фортуна. Ловушка для счастливчика». 12+
8.45 «АНДРЕЙКА». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ЗА МЕЧТОЙ». 12+
14.45 «Энциклопедия загадок». 12+
15.15 «НОВАЯ ЖИЗНЬ МАШИ СОЛЁНОВОЙ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ВУНДЕРКИНДЫ». 12+
22.50 «ВСПОМНИ ВСЕ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10 «Вячеслав Тихонов. Разговор по душам». 12+
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.45 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.05 «ЭКИПАЖ». 12+
16.50 «Михаил Задорнов. От первого лица». 16+
19.00 «Три аккорда». 16+
21.00 «Время».
22.35 «КОНТЕЙНЕР». 16+
23.30 Подкаст.лаб. 16+

«РОССИЯ»
6.15 «ЛЮБОВЬ НЕ ПО ПРАВИЛАМ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
12.00 «Большие перемены».
13.05 «ВРЕМЯ ДОЧЕРЕЙ». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Сказка о золотом петушке».
7.15 «СТО ДНЕЙ ПОСЛЕ ДЕТСТВА».
8.50 Тайны старого чердака. «Гравюра».
9.20 Диалоги о животных.
10.00 «МОЛОДАЯ ГВАРДИЯ».
11.20 Невский ковчег. Теория невозможного. Василий Жуковский.
11.50 «Игра в бисер» «Александр Пушкин. «Сказка о царе Салтане».
12.30 «Сказка о царе Салтане».
13.25 «Геннадий Селюцкий. Рыцарь танца».
14.20 Габриэла Комлева, Татьяна Терехова, Реджепмырат Абдыев, Геннадий Селюцкий в балете Л. Минкуса «Баядерка».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Первые в мире».
17.25 «Пешком...»
17.55 «Матвей Блантер и его песни».
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «Последний герой уходящей эпохи».
20.55 «МИЧМАН ПАНИН».
22.30 «Великие имена. Монтсеррат Кабалье».
23.25 Спектакль «Старый сеньор и...»

«НТВ»
4.50 «СТАЖЁРЫ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве» с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Маска». 12+
23.30 «Звезды сошлись». 16+

Казанның вак караклары

2 июль көнне К.Ханнанов төш вакытларында телефонындагы СМС хәбәрләрне күреп аптырап кала. Чөнки үзенең «банк картасыннан унбер мәртәбә акча күчерелгән, «Пятерочка», шәхси эшмәкәр Мәмиев кибетләрендә исәп-хисап ясалуын ачыклый. Шуннан соң узган ике көндә башка картасыннан да шундый ук ысул белән сигез тапкыр акча шудыруларын күрә һәм банкларга хәбәр итеп карталарны ябып куя.

20 яшьлек егет карталарның угры кулына ни рәвешле эләгүен бик тиз аңлап ала. 1 июль кичендә Җиңү проспектындагы Саклык банкына кереп картасына 2 мең сум акча сала, шул мәлдә телефоны шалтырый, өч картаны банкомат өстенә куеп тора, сөйләшә-сөйләшә урамга чыгып китә. Онытып калдырылган карталарга хуҗа табылган, димәк.

Камил шул көнне үк «Горки» полиция бүлегенә гариза яза. Хәзерге заманда ачылмый торган җинаять булмый бу, билгеле. Оперативниклар СМС хәбәрләрдә күрсәтелгән сәүдә оешмаларын йөреп чыгалар, «Пятерочка»дагы видеокүзәтү җайланмасы язмасы вак каракны тоту өчен җитә кала. 1992 елгы Р. Сәлаховка гаебен танып тәүбә итәргә һәм ашыгыч рәвештә китерелгән матди зыянны кайтарырга туры килә.

Руслан моңа кадәр хөкемгә һәм административ җаваплылыкка тартылган кеше түгел. Әйтүенчә, мәктәптән соң көллияттә укып чыккан, вакытлы эшләргә йөргән, соңгы вакытта беркайда да эшләми, 83 яшьлек инвалид әбисенең опекуны санала, язылышмаган хатыны белән тулай торак бүлмәсендә тора. Рәсми кәгазьләрдә аның эчкече булуы турында мәгълүмат юк, әмма ул үзе 2019 елдан бирле наркологта исәптә торуы турында белдерә, димәк, карт әбисен тәрбия кылуына да ышанасы килми.

Р.Сәлахов банкка иптәшенә ияреп очраклы рәвештә генә килеп керә һәм банкомат өстендәге өч карта салынган визитницаны кесәсенә шудыра. Күктән төшкән бәхет итеп кабул итә ул моны. Шунда ук янындагы шәхси сәүдәгәр кибетенә керә. Мәгълүм булганча, бәя 1 мең тәңкәдән артмаса «пин-код»ның кирәге юк. Шул рәвешле биш тапкыр исәп-хисап ясап «Сбербанк» картасы белән түләп исерткеч эчемлекләр, азык-төлек күтәреп чыга, «Славица» лавкасыннан туңдырмалар да ала. 1 июльдә чит кеше картасыннан 4776 сум акча урлана.

Икенче көнне дә тукталып кала алмый Руслан. Иртә белән Саклык банкы картасындагы акчага җәмгысы 5418 сумлык ашамлык, эчемлекләр алып чыга. Хак булса, шуннан соң әлеге картаны ертып ташлый ул, әйтүенчә, анда акча бетте дип уйлый. Шуннан соң, башка банк картасы белән эш итәргә тотына, ашамлыклар кибетендә, карта хатынымныкы, «пин-код»ны белмим дип, ун тапкыр, «Пятерочка»да ике мәртәбә алыш-биреш ясагач, матди зыян 19728 сумга җитә. Ул тагын да арткан булыр иде дә, К.Ханнанов счетларын биккә куюу сәбәпле, угры ике кибеттән буш кул белән чыга.

Бушлай сыр тозакта гына була дигәндәй, күктән төшкән байлык Р. Сәлаховка зур мәшәкать чыгара. Октябрь аенда җинаять эше Идел буе район судына тапшырылды, 8 декабрьдә ул шартлы рәвештә 1 елга иреккеннән мәхрүм ителде.

* * *

Р.Сәлахов очраклы рәвештә кулга төшерелгән банк картасыннан чәлдерсә, Данил Моратхуҗин яңа танышкан Артем Галәвиев телефонындагы банк кушымтасына үтеп кереп электрон акча күчерү җаен таба.

Биектау районы егете Артем Казанда эшли, 72 яшьлек абзый белән аның фатирында яши. 7 августта «Знакомства» сайтында 25 яшьлек Данил белән таныша, җәйге көндә хуҗа бабай бакчасында булудан файдаланып, аны өенә чакыра, әйтүенчә, аракы эчеп сөйләшеп утырасы килә. Хәмер ярдәме белән тиз дуслаша алар. Ун көннән Данил тагын килә, бу юлы Максим атлы дусты белән пәйда була. Утыра торгач, кунак, эни авырый дигән булып, Саклык банкындагы счетына 5 мең сум акча күчертүгә дә ирешә. А. Галәвиев аларга такси чакыртып, аның бәясен дә үзе түли, ә акчаны телефонындагы банк кушымтасы ярдәмендә озата. Соңрак мәгълүм булганча, Д. Моратхуҗин парольне күреп һәм хәтерләп кала һәм әнисе белән сөйләшү өчен дигән булып, Артемның телефонын алып тора, шул арада аның кредит картасыннан 10 мең тәңкәне дусты картасына күчереп өлгерә.

А. Галәвиев бу хакта иртә белән белеп ала һәм моның Д. Моратхуҗин эше икәненә шикләнми. Чөнки акча ул телефонны алып торган вакытта күчерелгән була. Полициягә хәбәр итәргә ашыкмый ул, мәсьәләне тыныч юл белән хәл итәргә теләп Данилга шалтырата, анысы гаебен танымый, билгеле. Ләкин телефон буенча аралашуларын дәвам иттерә алар, дүрт көннән Моратхуҗин бер дустын иярттеп, тагын Галәвиев янына килеп чыга.

Ни хикмәт, 17 август вакыйгасы бу юлы да кабатлана, гәпләшеп утырганда, кунак тагын Артемның телефонын сорап торып, читкәрәк китә һәм шул ук ысул белән 10 мең сумны шудыра, ягъни үзе белән килгән дусты счетына күчерә. Артем бу хәлгә алдан ук әзер булганга ошый. Чөнки телефонына күз төшергәч үк тавыш куптара, ул гына да түгел, кесәсеннән «наручник» чыгарып бер ягын тегенең кулына, икенчесен үзенекенә эләктереп куя, ягъни угрыга качып китү мөмкинлеге калдырмый. Тиздән якындагы полиция бүлегенә ике хәбәр килә, Моратхуҗин богаулап әсирлеккә алдылар, Галәвиев банктагы акчамны урладылар дип шалтырата. Эшнең асылына төшенү өчен, оперативникларга күп вакыт кирәк булмый, әлбәттә.

Д. Моратхуҗинга гаебен танудан башка чара калмый. Акчаны ашыгыч рәвештә кайтарып бирсә дә, Моратхуҗинга каршы җинаять эше кузгатыла, билгеле.

Моңа кадәр полиция күзенә чалынганы булмаган егетнең ошбу акылсызлыгына гаҗәпләнергә туры килә. Мәктәпне яхшы билгеләргә, югары уку йортын кызыл дипломга тәмамлап, мәртәбәле институтта һинд теле укытучысы булып эшли торган, карап торырга үрнәк кеше бит ул, югыйсә. Күрәсең, тәрҗемәи хәленә «хөкем ителгән» дигән мөһер суктырасы килгән һәм максатына ирешкән ул. Шушы көннәрдә Идел буе район суды аны ел ярымга шартлы рәвештә иреккеннән мәхрүм итәргә дигән карар чыгарды.

* * *

1980 елгы Евгений Павлов, әлеге ике егеттән аермалы буларак, төрмә юлын таптаган угры. 18 яшендә чакта бер-бер артлы өч мәртәбә хөкемгә тартылып, барлыгын дүрт елга иреккеннән мәхрүм ителә, аннан соң шундый ук җинаятьләре өчен тагын дүрт елга Түбән Карамалы колониясенә озатыла, кеше талап ел ярымга Пановка колониясенә утыртыла. Амнистиягә әлегеп яисә шартлы рәвештә вакытыннан алданрак азат ителеп килә ул, шулай да 5 елдан артык гомерен япкынлыкта уздыра. Е. Павлов 2010 елда иреккә чыкканнан бирле суд каршында җавап тотмаган үзе, ә быел җәй телефон чәлдереп рисвай булды.

2007-2013 елларда наркоман буларак диспансерда исәптә торган, хәзер исә нәфесен хәмер эчеп баса. Башлыча эчү дигән зәхмәте аркасында хатыны, баласы белән аерылышып 73 яшьлек әнисе белән яши. Җәй көннәрендә карчык күбрәк бакчасында була, 14 июльдә Евгений таныш хатын-кызы фатирында сыйланып утыра. Соңрак анда Евгения исемле тагын бер гүзәл зат килеп керә. Тән уртасында хуҗабикә кунакларны озата, яңа танышкан кешеләр Павлов фатирына кайтып күңел ачып утыра.

Төнге сәгать 2 дә Евгения, балконда тәмәке көйрәтеп кергәч тә, өстәлдә калган телефоны юкка чыгуын күрә, ул гына да түгел, ишекне бикләп, хуҗа үзе дә чыгып киткән була. Шул рәвешле, Евгения, чыныкта, тоткынлыкка эләгә һәм Е. Павловны көндезгә 2 гә кадәр көтеп утыра. Ә ул исә югалган телефон турында сорагач җикеренә башлый, куркa калган ханымга табан ялтыратырга гына кала. Шулай да мәсьәләне тыныч юл белән хәл итәргә тырыша ул. Ләкин Павлов итәгенә ут капкач, ягъни хәбәр полициягә барып җиткәч кенә акылына килә.

Телефонны эләктереп чыккач та, Павлов такси йөртүче дустын чакырып китерә, аның белән «Победа» кибетенә килеп, шофер паспорты буенча аппаратны 9 мең сумга тапшыра. Соңрак таксистка да аңлатма язарга туры килә, билгеле. Урланган мөлкәтне ул биргән булып чыга бит. Ләкин аны җавапка тартырга нигез юк дип табыла. Е.Павлов гаебен таный, 19934 сум дип белдерелгән матди зыянны да озакка сузмыйча түли. Кибет мөдиренең әйтүенә караганда, урлап тапшырылган телефон 12 мең сумга сатып җибәрелгән була инде. Вак бурлык буенча кузгатылган тагын бер җинаять эше Идел буе район судына бирелә. Суд утырышында зарар күрүче Е.Павловка дәгъвам юк дип белдерә, шуңа күрә, якларның килешүе сәбәпле дигән билгеләмә белән вак угры җәзасыз калдырыла, ләкин ул барыбер хөкем ителгән зат булып санала.

* * *

31 яшендәге Алексей Шамилев тә наркотик кулланучы буларак исәпкә куелган кеше. Шул афәт белән бәйле җинаять кылган өчен, колониядә бер ел утырып, 2021 ел азагында гына кайта ул. Моңа кадәр дә вак-төяк әйберләр чәлдереп ике мәртәбә мәҗбүри эшләргә дә хөкем ителгәне, әлеге җиңел җәзаны да үтәмәгән өчен зинданда ятып чыкканы да бар аның. Соңгы вакытта рәсми рәвештә мебель ясаучы булып эшли. Күрәсең, урлау теләге тынгы бирми ир-атка, юкса, быел чит кеше велосипедын алып китеп үзенә мәшәкать чыгармас иде.

Очраклы әйберне чәлдерү түгел бу, чөнки кесәсенә тимер кискеч (кусачки) салып чыга ул өеннән. Күрше урамдагы йортның подъезды ачык икәнен, иң югары, димәк, тынычрак каттагы «сәпитләр» турында алдан ук белгәнгә охшаган. Кыскасы, 9 август иртәсендә чормага менү баскычына эләктереп бикләнгән ике велосипедның берсенең тросын югарыда әйтелгән корал белән өзә дә, угры лифтта түбәнгә төшә һәм шунда ук Р. Зорге урамындагы «Победа» кибетенә барып, урланган малны 3 мең тәңкә акчага әйләндерә. Алыш-бирешне паспортын биреп ясый, димәк, үзе турында тулы мәгълүмат калдыра анда.

Хуҗалар бу хакта кич белән эштән кайткач гына белеп ала, урынында калган икенче «Stels»-ны фатирларына кертеп куялар да, эзләмәсләр, таба алмаслар дип полициягә хәбәр итәргә ашыкмыйлар. Ике көннән соң гына хуҗабикә каракны җавапка тартуны сорап «Горки» полиция бүлегенә мөрәҗәгать итә, 7 ел элек алынган велосипедның бәясен 10 мең сум дип белдерә. «Победа» кибетендә оперативникларга велосипедның 3600 сумга сатылуы турында кәгазь күрсәтәләр. А.Шамилев 10 мең сум күләмендәге матди зыянны кайтарырга сүз бирә. Күрсәтмәләрендә 3 нче сыйныфта укучы кызының бердәнбер опекуны икәнен искәртә ул, чөнки аның хатыны 2022 елның февраль аенда үлеп китә. Әлбәттә, хөкемне берникадәр йомшартырга мөмкинлек бирә торган шарт бу.

Моның ише бурлыклар зур шәһәрләрдә бихисап күп. Алар белән шөгыльләнү өчен еш кына тынычрак төбәкләрдән, бигрәк тә, татар районнарыннан ярдәмгә хезмәткәрләр дә җибәрелә. Әлеге дүрт җинаять эшен дә Балтач эчке эшләр бүлегенең тикшерү төркеме җитәкчесе Р.Газимов һәм тикшерүче Е.Петрова тикшерә.

Наил ВАХИТОВ.

Киләчәк йолдызлары

Сәнгать өлкәсендә академик белемгә ныграк игътибар бирелсә, концерт сәхнәләрендә затлы җырлар, музыкаль әсәрләр ешрак яңгыраячак. Профессиональ музыкага ярдәм йөзеннән республикабызда төрле чаралар уза. Шуларның берсе – маэстро Рөстәм Абязов җитәкчелегендәге La Primavera Казан камера оркестры оештырган «Звезды из завтра» фестивале. Быел ул тугызынчы тапкыр үтте. Тугыз ел эчендә анда дүрт меңгә якын сәләтле бала катнашкан. Быел гына да 155 бала һәм яшүсмер фестивальдә чыгыш ясарга теләк белдергән. Шулардан иң сәләтлеләрен сайлап, С.Сәйдәшев исемендәге дәүләт зур концерт залында гала-концерт үткәрделәр. Анда Казан, Яшел Үзән, Балтач, Кукмара музыка һәм сәнгать мәктәпләрендә белем-күнекмә алучы балалар катнашты. Сайлау үткән нәниләр өчен La Primavera оркестры белән бер сәхнәдә чыгыш ясау – зур сынау да, гомер буе күңелләрендә кадерле истәлек булып сакланачак бүләк тә.

● **Маэстро Р.Абязов, «Piccolini» хоры җитәкчесе С.Семёнова һәм җырчы кызлар.**

2020 елдан бирле фестиваль республика күләмендә Президент Р.Миңнеханов һәм Татарстан Мәдәният министрлыгы ярдәме белән үтә.

Фестивальдә физик мөмкинлекләре чикле балалар да катнаша. Быел гала-концертта, мәсәлән, Казанның 13 нче музыка мәктәбеннән 17 яшьлек Анастасия Гребнева һәм Әмир Гомәровны ишетү бәхете эләкте. Әмирнең күзләре күрми. Ноталарны ул Брайль системасы буенча укый, ятлый. Уку авыр бирелсә дә, Ә.Гомәров танылган композиторларның озын музыкаль әсәрләрен башкара. Әмир «Звезды из завтра» фестиваленең гала-концертына өченче тапкыр үткән. Фортепианода уйнап кына калмый, үзе көйләр дә иҗат итә әле.

Быел фестивальдә «Звезды из послезавтра» исеме астында беренче тапкыр бик бәләкәй музыкантлар белән таныштырдылар. Әскәр Закировка нибары алты яшь. Ул әле музыка мәктәбенең әзерлек курсларына гына йөри. Шуңа да карамастан халыкара, Бөтенроссия бәйгеләрдә җиңү яулап өлгергән. Фестивальнең гала-концертында ул тальян гармунда татар халык җырларыннан тезмә башкарды. Гармуннан чак кына башы күренеп торган, урындыкка утыргач, аяклары идәнгә дә тимәгән Әскәрне бөтен концерт залы йотлыгып тыңлады. Мөгаллиме Евгений Кубышкинга рәхмәт. Сүз уңаеннан гала-концертта бу укытучының өч укучысы катнашты.

Нәниләр арасында виолончельчылар дуэты Даниил һәм Кирилл Приходцевлар да игътибарны җәлеп итте. Бу концертта әнә шулай гаиләләп, династияләп катнашалар. Малайларның әтиләре – үзе дә виолончель остасы, әниләре сокландырырлык итеп фортепианода уйный.

Нәни музыкантларның репертуарында татар җыры, музыкасы күп булуы күңелгә сары май булып ятты. Композитор Салих Сәйдәшевнең «Әдрән диңгез»ен бик оста итеп Казан музыка мәктәбеннән ир-балалар капелласы башкарды. Казаннан Сәйдә Абдуллинаның «Гармунчы булсын ярың» җыры да күңелгә хуш килде. Балтач сәнгать мәктәбеннән Зилә Хәмитова – хәзердән үк коеп куйган опера җырчысы. Ул Дж.Пуччининың «Джанни Скикки» операсыннан Лауретта ариясен башкарганда, бөтен зал тын да алмыйча тыңлады.

Музыка мөгаллимнәренең никадәр зур эш алып барганы шушы концертта ап-ачык күренде. Бер баланы өйрәтү дә җиңел түгел. Казанның 4 нче музыка мәктәбеннән Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Светлана Семенова «Piccolini» хорындагы алтмыштан артык баланы бер-берсенең тынын, сулыш алуын тоеп бердәй оста җырларга ничек өйрәтә алган?

Дирижер Р.Абязовның бу фестивале классик музыкага, академик белемгә игътибарны арттырып, музыка мөгаллимнәренә ярдәм булып кына калмый, безнең нәни йолдызларны зур сәхнәләргә чыгарырга да булыша. Лауреатлар, мәсәлән, «Синяя птица», «Лучше всех» проектларына, «Добрая волна» фестиваленә чакыру алган, «Новые имена» һәм Владимир Спиваковның хәйрия халыкара фондының стипендияләренә ия булган, республикабызның музыка көллиятләрендә укырга тәкъдим алган.

● **Әскәр Закиров.**

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

● **Кирилл һәм Даниил Приходцевлар.**

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шаих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012 ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань р/с 40702810600020010312 к/с 30101810000000000805 БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 3.02.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2603

16+